ТКН ТКИ



*Эльмира Шәрифуллина*

# УЙЛЫ ЕЛЛАР



Шигырьләр, поэмалар

*КАЗАН*
*ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ*
*2003*

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ш 95

**Шәрифуллина** Эльмира

Ш 95 Уйлы еллар: Шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.— 287 б.

Шагыйрәнең яңа китабында туган як, аның кешеләре, шәхес, җәмгыять, мәхәббәткә тугрылык хакындагы шигырьләре, җырлары, шулай ук Г.Тукай һәм К.Насыйрига багышланган поэмалары урын алган.

ISBN 5-298-01344-9

©Татарстан китап нәшрияты, 2003

I

*Синдә җыясы тәгамем,*
*Синдә эчәсе суым.*
*Син сәламәт булсаң гына,*
*Яңара минем буын.*



## *Туган җир*

И туган җир,
Газиз әнкәм җире,
Әткәм иле, бабам туфрагы!
Җилләр булып исеп,
Гөлләр булып үсеп
Кайтачакмын сиңа мин тагы.

И үскән җир,
Газиз әнкәм җире,
Әткәм иле, әбкәм бишеге!
Мөнәҗәтләр моңын,
Корьән Кәрим нурын
Каршы алыр күңел ишеге.

И торган җир,
Газиз әнкәм җире,
Әткәм иле, дуслар кочагы!
Тик син якын итсәң,
Битләремнән үпсәң,
Балкып яначакмын мин тагы...

## *Татарстан шуннан башлана*

Кояш чыга, инсан елмая,
Агач үсә, гөлләр тураят –
Татарстан шуннан башлана.

Яңгыр ява, ява сеңдереп,
Арыш, бодай килә өлгереп –
Татарстан шуннан башлана.

Иген уңа, пешә ашлыклар,
Дан-дәрәҗә ала башлыклар –
Татарстан шуннан башлана.

Сарай-йортлар... шаулый төзелеш,
Киң манзара, хикмәт, күренеш –
Татарстан шуннан башлана.

Егет-җилән җирдән май ала,
«Майлы» җирдә үсә яшь кала –
Татарстан шуннан башлана.

Монда тудың – яшә, ярат, сөй,
Аваз салса таңда нарасый –
Татарстан шуннан башлана!

## *Сакламмын исемеңне*

Кайнар икмәк – өстәлләрдә,
Җан җылысы – кулларда.
Нигә алай
Рәхәт икән
Тузан очкан юлларда?

Кайтам туган төбәгемә
Сабырсыз хисләр белән.
Ул мине хәйран калдыра
Могҗиза эшләр белән.

Һәр авылдашта яңалык,
Серен сөйли, бүлешә.
Әллә каян сәлам биреп,
Ике куллап күрешә.

Уртак анда кайгылар да,
Уртак шатлыклы хәбәр.
Саклармын яхшы атыңны
Кулымнан килгән кадәр.

## *Икмәгегез уңсын, мул булсын!*

Чишмә булып бәрдем күкрәгеңнән,
Туган авылым, туган төбәгем.
Уем гына кайтып-китеп йөри,
Синдә яши минем йөрәгем.

Синнән башка үксез бала бит мин,
Бер чирләшкә гүя чит җирдә.
Мәхәббәтсез, сыйсыз яшәгәндәй,
Сөю кадерен белмәс ят ирдә...

Пар бөркелә кара туфрагыңнан,
Тоеп язның иркен сулышын.
Тәпи баскан һәр сабыйга кадәр –
Киләчәгең, нәни булышчың!

Туган җирле булсын һәрбер йөрәк,
Күңеленә якты нур тулсын.
Читкә киткәннәрдән теләк сезгә:
Икмәгегез уңсын, мул булсын!

## Йокысыз төн санынча

Буразнадай җыерчыклар
Игенче маңгаенда.
Эз салына башлагандыр
Елның кайсы аенда?

Кышлар җитеп, кар аз төшсә,
Ужымнар өшер, дипме,
Аяз көннәр күпкә китте,
Аз булыр көшел, дипме?..

Көн тудымы – яңа борчу
Туган җир агаенда.
Йокысыз төннәр исәбе
Игенче маңгаенда.

## Авыл язы

Язгы көннең матурлыгы
Барлык җан иясендә.
Колынын дәшеп кешнәгән
Тимеркүк биясендә,

Ишегалларын тутырып
Ата каз биюендә,
Һәрбер хайван, кош-кортларның
Үзенчә сөюендә,

Җир тырнап һөҗүмгә күчкән
Нәселле үгезендә,
Язгы көннең матурлыгы
Туган йорт нигезендә!

# Нурчишмәм

Карап торам, хәйран калам,
Суларыңа тәңкә салам,
Тәңкәле су – сучишмәм.
Көмеш суда чагыла нур,
Көмеш суда агыла җыр –
Җырчишмәм син, җырчишмәм.

Салкын суын кулга алам
Тып-тып тамчың телгә тама –
Балчишмәм син, балчишмәм.
Тәннәргә сихәтең сеңә,
Җаннарга җылың йөгерә –
Җанчишмәм син, җанчишмәм.

Җирнең җәйге кочагында
Кызның моңсу курчагыдай
Чүгәлим, тик җир ишмәм.
Моңлансам да синең кебек,
Горур калам дәртең күреп,
Сүз тишсәм дә, сер чишмәм.

Көч-гайрәтең, күрче, нинди,
Миндә дә ут, ялкын көйри –
Туган чишмәм, җирчишмәм.
Тибеп, бәреп чыгасың ич,
Тынычлангач тонасың ич –
Сафчишмәм син, сафчишмәм.

Уйлап торам, хәйран калам,
Суларыңа тәңкә салам,
Тәңкәле су – сучишмәм.
Көмеш суда агыла җыр,
Көмеш суда чагыла нур –
Нурчишмәм син, нурчишмәм!

## Кыйблам бер генә

Дүрт ягым кыйбла икән...
Күз кая карый,
Тотып шул якка
Китимме икән?

Дүрт ягым кыйбла икән...
Җүләр җил булып
Дулый да дулый
Исимме икән?

Дүрт ягым кыйбла икән...
Тирән тамырлы
Сылу гөл булып
Үсимме икән?

Дүрт ягым кыйбла икән...
Ирек бирсәм дә
Искән җилләргә,
Туфрак булсам да
Үскән гөлләргә,
Кыйблам бер генә –
Туган илләрдә!

## Туган ягым

Яшен булып балкыйммы,
Сагыш булып саркыйммы?
Туган ягым күгендә
Йолдыз булып калкыйммы?

Сиңа кирәк булганга
Бәхетле мин дөньяда.
Синдә генә, авылым,
Һәр төн, һәрбер көн яңа.

Мәхәббәт эчкән җаным,
Тәнемә күчкән таңым –
Күздә нур булып кабын,
Телдә моң булып кагын.

Яңгыр булып кайтырмын,
Син сусаган көннәрдә.
Чәчәк булып балкырмын
Сабый салган эзләрдә.

## Мәгънә белә

Туган җирем – Ык буйлары,
Үскән җирем – кыр ягы.
Чәчләремне кырау саргач,
Әйләнеп кайттым тагы.

Әйләнеп кайттым – исәбем –
Табудыр югалтканны.
Кагыл-сугыл күп йөредем,
Көтәм бер юатканны.

Кемнәргә барып сарылыйм,
Кемнәргә серем сыяр?
Сабый җанлы саф көннәрнең
Кем килеп күңелен кыяр?

Түнә башлар, түнә башлар,
Түнә башлар уй уйлап.
Җилкән тартып хыялларга,
Очыйкчы галәм буйлап.

Булган – беткән, вакыт үткән,
Рәнҗемим, кирәк түгел.
Мәгънәне, канунны белә
Хәсрәтләр күргән күңел.

# *Симәгем*

Сим-Сим аңа ишек ачкан,
Сим-Сим аңа бишек аскан.
Кемсимәннең олы кызы
Менә шунда күзен ачкан...

Тылсым көче белән хастан:
Сим-Сим үзе ишек ачкан,
Симәк авылы бишек аскан...
Туган ягым – Мөслим ягы,
Ә дәүләтем – Татарстан!

Язмышыма серләр качкан:
Симәк авылы бишек аскан,
Шагыйрь булыр мин – мөслимәң
Шунда туып, күзен ачкан,
Язмышыма серләр качкан.

Менә шунда тәпи баскан
Мөхәммәтнең олы кызы.
Ул дөньяга килгән өйдә
Ут элдергән каен тузы,
Җылы биргән имән кузы.

Биеткәндер имән кузы
Самоварда чишмә суын.
Шуңадырмы, сөбханалла,
(Шөкер Ходаем-Аллага!)
Үз көчендә егәр-буын!

Симәгемнең җиләклеге,
Урманнары, әрәмәсе
Туендырган, сыендырган,
Ык елгасы коендырган
Гомер юлымда – һәммәсе.

Мәрхәмәтле туган җирем,
Игелекле атам кыры,
Рәхмәтеңнән ташлама син,
Сагыш сүзе саклама син.
Илһам алсын шагыйрь җыры,
Чәчәк атсын шигырь кыры.

Әткәемнең туган җире –
Минем төбәк, минем илем!
Кайчан кайтып егылсам да,
Үтешлиме сугылсам да,
Сыяр кебек сиңа серем.
Кендек каным тамган җирем,
Симәгем, син – туган илем!

## *Ел да кайтам янына*

Бергәләшеп җиләк җыйдык
Кояшлы аланнарда.
Борчуларым эленеп калды
Ямь-яшел баланнарда.

Тәлгәшләп җыйдык җиләкне
Кучтәнәчкә, бүләккә.
Синең янга кайтам ел да,
Җанга җылы кирәккә.

Сагышларым сазга бата,
Яшьләрем оча кибеп.
Әбекәем, син бит безнең
Шифалы һәм бәрәкәтле
Кояшлы яңгыр кебек!

## Жырларымда — туган ягым

Әй, жырым, сез, жыр-моңнарым,
Кайтыгыз авылыма.
Тургай булып таралыгыз
Алтын иген кырыма.

Әй, жырым, сез, моң-зарларым,
Бер сандугач булыгыз.
Чишмә буйларында үскән
Талчыбыкка куныгыз.

Әй, жырым, сез, жыр-моңнарым,
Дәрт һәм дәрман бирегез.
Туган ягым – сез ул, жырым,
Үзегезне күрегез!

## Тагын бер кат

Туган якларыңа алып кайттың,
Сөеп кенә, назлап сүз куштың.
Үзең эчми, миңа суздың шунда
Чишмә суын алган кушучың.

Серле сулыш белән кытыкланды
Салкын ширбәт эчкән ут ирен.
Тагын бер кат гашыйк булдым сиңа,
Беткән кебек булды бар чирем.

Гашыйк булдым туган якларыңа,
Урман-күлгә, жырчы чишмәгә.
Матур табигатьле төбәкләрдә
Назлы җаннар үсми тикмәгә...

# *Туган җирнең җылысы*

Авылыма кайтыр идем
Язгы җил кочагында.
Яңадан бер дөрләр идем
Туган як учагында.

Анда калды саф хисләрем,
Балачак аланнары.
Шау чәчәктән генә торган
Мәхәббәт яланнары.

Табанымны кытыклаган
Камыллы курпылары.
Чибәр кыздай бил бирмәгән
Уйнак тай-елкылары...

Бал исе сеңгән таңнарым,
Чәчәкле сәхнәләрем –
Сез яшьлектән бүгенемә
Җыр булып күчкәннәрем.

Иркәли җанны, юата
Туган җирнең җылысы.
Туган җирен җирсәп елый
Егет-кызның моңлысы.

# Зурмы дисәң...

Зурмы дисәң, зур түгелдер,
Уртача безнең авыл.
Ут чыккан, янган нигезләр,
Җимергән аны давыл.

Зәхмәтен дә, зәһәрен дә
Ил белән бергә күргән.
Ил белән яуларга кергән,
Ил белән бергә бөлгән.

Әмма туры юлдан барган,
Читләргә тайпылмаган.
Дошманның төрлесе килгән,
Алданып сатылмаган.

Иген иккән авылдашлар,
Мал-туар асыраган.
Мәхәллә-мәктәпле, диеп,
Тирә-яклар юл салган.

Үстергән Герой булырлык
Әзмәвер егетләрне.
Сәхнәгә, сәнгатькә биргән
Сүзе ук кебекләрне.

Күрер күзгә юк, зур түгел,
Уртача минем авыл.
Әмма кылган эш-гамәле
Тарихка кереп калыр.

# *Кайтыр юлым*

Зөбәергә[1] кайтыр юлым
Бормалы, үрелмәле.
Урам очларына бассаң,
Кырлары күренмәле.

Уйнаклап чапкан колыннар
Күптән йөгерек тай булган.
Безнең якта елга-сулар
Ни өчендер сай булган.

Сай булса да, аксакаллар
Сол[2] белгән дә җай белгән.
Яңгыры да, бураны да
Рәхмәте белән килгән.

Анда калды чаптарларым,
Алмачуар атларым.
Анда бар да таныш миңа,
Юк читләрем, ятларым.

Анда калды саф хисләрем,
Балачак аланнары.
Илаһи моң, хискә чумган
Мәхәббәт яланнары.

Уйларымны сөйли китсәм,
Чайпалып түгелмәле.
Зөбәергә кайтыр юлым
Бормалы, үр менмәле.

[1] Авыл исеме.
[2] Эшнең җаен, тәртибен белү.

## Тормыш гамьле булсын өчен

Җыр башласаң, тавышыңны
Дөрес итеп табу кирәк.
Сукмак ярсаң, үз юлыңны
Такыр итеп сабу кирәк.

Сүз башласаң, иптәшеңнән
Яхшы киңәш алу кирәк.
Тормыш ямьле булсын өчен,
Гамьле булу, яну кирәк.

## Зөбәерем — Зөбәер

Бала чакның әкиятле йөзе
Балкып тора буйга җиткәч тә.
Үсмер чакның моңлы елмаюы
Истә, өйдән чыгып киткәч тә.

Зөбәернең зәңгәр иртәсеннән
Әкият моңы килә ияреп.
Туган җирем, мең-мең рәхмәт сиңа,
Биреп җибәргәнсең тиярен.

Сагынып яшим, сагынып искә алам,
Сирәк кайтуыма карама.
Кыйблаларга карап чүгәлим дә
Дога кылам әби-бабама.

Зөбәернең зәңгәр иртәләре,
Зәңгәр койма төргән мәктәбем.
Бу җыр сезгә бер бүләгем булсын,
Истәлегем булсын, ядкәрем!

## Нинди исем кушыйм икән?

Нинди исем кушыйм икән
Быелгы җәйләремә?
Мәтрүшкәләр җыеп алдым
Кыш эчәр чәйләремә.

Кала иң садә хисләрем
Туган як тугаенда.
Гел кайтырга кирәк, диләр,
Шулайдыр, шулаен да...

Нишләтмәк кирәк күңелне –
Яна бит көйрәп-көйрәп.
Туган җирдән торган җиргә
Киләм сагыш-моң сөйрәп.

Торган җир – шәп,
Туган җирдә –
Гомеремнең татлысы!
Нинди исем кушыйм икән,
Җиткән җәйнең яртысы?..

## Карга боткасы

Дәгъвалашып язгы ташу киткәч,
Язгы кояш җылы нурын сипкәч,
Узу беләң апрель уртасы,
Пешә иде карга боткасы.

Җыеп безне – ыбыр-чыбырны,
Авылның иң өлкән карчыгы
Китәр иде.
Безне көтеп тора
Кыңгыр түбәтәйле таучыгы.

Табыннар мул хәзер –
Икмәк кенә
Түгел икән яшәү тоткасы.
Онытылмый түбәтәйле шул тау,
Шунда пешкән карга боткасы.

Ботка пешкәч, җыелып,
Түбәтәй тау[1]
Итәгенә килеп утыргач,
Күңелләрне кояш нуры белән,
Яшәү яме белән тутыргач,

Елмаер ла иде Нурлый әби,
Сыйпап яңа шыткан үләнне:
Әйтер иде:
«Дошманыңа хәтта
Күрсәтмәсен безнең күргәнне».

Ул чагында бала булганбыз шул,
Кызык булган безгә галәмәт...
Нурлый әби әйткән нурлы сүзләр –
Әманәт лә булган, әманәт.

Әманәтләр әйтер өчен генә
Пешергәндер, бәлки, ул аны.
Икмәк кискән саен хәтерлимен
Онытылып барган йоланы.

...Тормышлар мул хәзер,
Табыннар мул.
Ә нәрсә соң яшәү тоткасы?
Каян гына искә төштең әле,
Онытылган карга боткасы?!

---

[1] Тау исеме.

# *Каз өмәсе*

Каурый чәчәм су юлына,
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күрсәтеп,
Ярлар табып калыгыз.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан калган йола –
Татарның каз өмәсе.

Каз мамыгы яшь киленгә –
Түшәк, ястык, юрганга...
Дәртләнерсең, мамыктай кул
Иңнәреңә кунганда.

Юл аягы – каз коймагы,
Сыйлансаң – суык тимәс.
Каз йолка белмәгән кызны
Егет солтаны сөймәс.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы, төймәсе.
Борынгыдан калган гадәт –
Татарның каз өмәсе.

# *Йорт җиһазы*

Сәке – безнең өстәл иде,
Сәке – безнең карават.
Кирәк икән чәй эч шунда,
Кирәк икән кырын ят.

Сәке – безнең сандык иде,
Каз оясы сыярлык.
Сәке асты сарай иде,
Ярган утын куярлык.

Сәке түренә өелгән
Түшәк, ястык, мендәре.
Сәке – әби-бабаемның
Намаз укыр менбәре...

Йорт-җиремнең төп җиһазы –
Сәке булган элгәре.
Әйтерсең шунда төйнәлгән
Җир һәм Җиһан егәре!

## Әни төсе

Чиккән сөлге – яшьлек истәлегем:
Яз гөлләре, моңлы гөрләвек.
Чиккән сөлге – минем гомер юлым:
Кышкы буран, җәйге көлләвек.

Чиккән сөлге – яшел урман юлы,
Көзге сагыш, кышкы бозлавык.
Чиккән төсләремә карыймын да
Эндәшәлми торам беравык.

Чиккән сөлге – бүләк балаларга,
Күзләремнән күчкән нурларым.
Ничәмә төс, ничәмә җыр анда –
Һәр төсендә минем кулларым.

Чиккән сөлге – әниләре төсе,
Сагынганда искә алырлар.
Янып торган яз бизәге чиктем,
Гомер үтәр,
Гөлләр калырлар!

## Бәби мунчасы

Йолалары милләтемнең
Күчә килә кечегә.
Ак әбиләр игътибары
Яңа туган кешегә.

Бәби мунчасы ягалар
Баладан котылгачтын,
Кырык кыл өзелгән газап
Күпмедер онтылгачтын.

Буыннарны сылап, сөеп,
Сыйпап оеш каннарны.
Мунча кертәләр әбиләр
Җан тудырган җаннарны.

Мунча кертәләр әбиләр,
Укыйлар теләк-дога.
Шуңадырмы авыллардан
Рәхимле җаннар чыга.

## *Гомер бишегем*

Синдә сөенер таңнарым,
Синдә сөелер тиңем.
Син мине кайгыга салдың,
Бәхетле дә ит, илем!

Синдә җыясы тәгамем,
Синдә эчәсе суым.
Син сәламәт булсаң гына
Яңара минем буын.

Синдә туасы хисләрем,
Синдә кабыныр утым.
Синдәдер гомер бишегем,
Мәңгегә китәр «йорт»ым.

## Актаныш төбәгендә

Эшчән, хисчән кызлар үстергән,
Улларына һәрчак көч биргән.
Кояш йөзле килен-кызлары
Эретәдер күңел бозларын.

Түбәтәй тау, Бәтке елгасы,–
Шунда пешә карга боткасы.
Күңелләргә игелек иңдерә
Туган якның гадәт-йоласы.

Бәҗаналы, Олы Буләкле,–
Бөтнек исле, тәмле җиләкле.
Туган авылым, туган җиркәем,
Синең белән көчле илкәем!

Зөбәер – туган авылым –
Актаныш төбәгендә.
Шул авылның нуры яна,
Шул авылның нуры яна
Күпләрнең йөрәгендә!

## Әрәмә

Бала чакта аз чаптыкмы
Зөбәер кырларыннан?
Эссе көндә су эчкән чак
Тәгәрмәч юлларыннан.
Истә әле, һаман истә
Чыклы чирәм, чокырлар.
Җимешенә җибәрмәскә
Тарткалашса чытырман,
Шуып астан керә идек –

Безме аннан буш кайткан?
Әмәлен тапсаң, әрәмә
Бар байлыгын
Чиләгеңә бушата...

## *Аккошлар кайткан иде...*

Аккошлар кайткан иде бит
Зөбәер саласына.
Кал монда, китмә, дидекме
Шул аккош баласына?

Бал да каптырдың, туган җир,
Май да куйдың табынга.
Фәкыйрь дәверләр килгәндә,
Талон бирдең сабынга.

Яшь тә түктердең, туган җир,
Шатлык та бирдең, шөкер.
Туган җирдән торган җиргә
Салынды сиртмә күпер.

Минем өлеш – алтын-көмеш –
Тик синдә, туган җирем.
Тик синдә – бәрәкәт көче,
Тик синдә – сихәт җиле.

Синдәдер анам кабере,
Синдәдер йөрер юлым.
Тик синдә җырга әйләнә
Йөрәктән чыккан моңым!

Аккошлар кайткан иде бит
Зөбәер саласына.
Кал монда, китмә, диегез
Шул аккош баласына...

# Ташка язып китәм

Мин бер кеше!
Галәм киңлегендә
Тузан бөртеге күк, тулаем.
Ләкин минем газиз төбәгем бар,
Үз кояшым һәм дә үз аем!

Үз болыным,
Елга-күлләрем бар,
Кашка тавым, серле Бикколым.
Сезгә тагын шигырь багышладым,
Уңдырышлы булды бу елым.

Үз нигезем, йорт-бигем бар минем
Туган ягым, туган төбәктә.
Без – кендек, дип күкрәк суга берәү...
Бик кирәкле корал – көрәк тә!

Кулларымда көрәк уйнатамын,
Утыртамын, җыеп аламын.
Тәмле сүзем чәчеп гөл үстерәм,
Кыяктай сүз – кыеп саламын.

Туган ягым акка төренгәнме,
Күккә күмелгәнме – барыбер,
Минеке ул!
Гәрчә үз шагыйрен
Читкә тибәрсә дә кемедер...

Ул Мөслимдә туган.
Бу якларда –
Актанышта юк, дип, дәһеле –
Ялгышасыз.
Мин Зөбәер кызы,
Актанышның ак бер әһеле!

(Туган җирне сайлап алмасам да,
Кендек каным тамган Мөслимдә.
Әткәемнең газиз туфрагы ул,
Әҗерләре иңем өстендә...)

Минеке син!
Ташка язып китәм,
Анам җире – ак ил – Актаныш!
Үз кояшым итеп сиңа багам –
Җаным гүя сары көнбагыш!

## Әнкәем кебек

Серле кичемдә хыял эчендә
Уйнаклап чапкан ярсу колыным,
Кай якка гына чыгып китсәм дә,
Зөбәеремә борыла юлым.

Юкны бар итеп, әзне тәмле итеп,
Тик синдә генә тәгам җыямын.
Кайчан кайтсам да, ничә кайтсам да,
Назлы нигезем, сиңа сыямын.

Моңнар сарганда – иҗат хезмәтем,
Кайгы сарганда – бәет-бәяным.
Йончып-талчыгып хәлем китсә дә,
Караңгы сарса хәят-хәямым,

Туган яккаем көч бирер миңа,
Туган нигез ул – газиз әнкә күк.
Ташлап киткән дә якты йөз күрә,
Урыны түрдә, бер-бер түрә күк.

Серле кичемдә хыял эчендә
Уйнаклап чапкан ярсу колыным...
Кай якка гына чыгып китсәм дә,
Зөбәеремә борыла юлым!

# Читтә яшәүче татарлар җыры

Ерак илләрдән,
Торган җирләрдән
Кайтабыз сиңа, и гүзәл Казан!
Сагыну хисе,
Тартылу көче
Кузгата юлга, и гүзәл Казан!

Әллә язмышлар,
Әллә ялгышлар
Иленә илткән безне ятларның.
Әмма син Казан
Гел нурлы Казан,
Изге Ватаны һәммә татарның.

Ана телебез,
Тамыр җебебез
Безне бер итә, безне зур итә.
Зирәк кызларың,
Гаярь улларың
Дан-дәрәҗәңне еракка илтә.

Күңел күзебез,
Дога-сүзебез
Төбәлгән сиңа, и гүзәл Казан!
Кайтып күрешсәк,
Сәлам бирешсәк,
Көч-дәрт алабыз без синнән, Казан!

# Ай-кояшлы таш кала

«Казан каласы – таш кала,
Күп калага баш кала».
Бер генә кил, шул килүдән
Сагынуың башлана.

Оныталмассың анда күргән
Тарихи биналарны.
Алыштырыр истәлекләр
Иң матур киноларны.

Кызыл капка, Елантаулар –
Төрле еллар бизәге.
Данлыклы печән базары –
Булган шәһәр үзәге.

Музей, мәчет, һәйкәлләрне
Күреп хәйран калырсың.
Үзеннән-үзе җыр туар,
Кулга гармун алырсың.

Казаныбыз күп милләтле,
Чуаш та бар, урыс та.
Дуска татар киң күңелле,
Дошман килсә – кырыс та.

Казан каласы – таш кала,
Ай-кояшлы баш кала!
Бер генә кил,
Шул күрүдән
Мәхәббәтең башлана.

# Казаным

Мең яшьлек Казаным минем,
Мең дә берне күргәнем.
Син тарихи шәхесләрне
Үзең танып белгәнем.

Сөембикә – асылбикә,
Сиңа килеп хан булган.
Кол Шәрифләр иң шәрәфле
Сәетең булып торган.

Мең яшьлек Казаным минем,
Мең дә берне күргәнем.
Шөһрәтлегә насыйп булган
Синең тәхет-түрләрең.

Тукайларны, Такташларны
Колачыңа алгансың.
Сәйдәш, Сара, Яхиннарның
Җырын отып калгансың.

Хәтерлисең урамыңда
Җәлилләрнең йөргәнен.
Татар өчен җанын бирер
Худяковлар килгәнен.

Максим Горький бабабызның
Ничек ипи изгәнен...
Кунак-төшемгә һаман да
Ачык капка-түрләрең.

Мең яшьлек Казаным минем,
Мең дә берне күргәнем.
Киләчәк, һичшиксез, ачар
Тагын бик күп серләрең.

# Тыңлыйм моңлы азаның

Зур шәһәр син, чал кала,
Күп калага баш кала.
Хыянәт, сугыш кичергән,
Кан-яшь түккән таш кала.

Асылыңа кайтарасы
Килә сине, Казаным.
Алтын Айлар хозурыннан
Ишетелә азаның!

Белемгә, нурга коенган
Мәркәзебез, илебез.
Тугандашлар арасында
Мәгърифәтле йөзебез.

Сөембикә сарайларын,
Тукай юлларын күзлим.
Гөлләр эчендә чагыңнан
Чулпылар чыңын эзлим.

Асылыңа кайтарасы
Килә сине, Казаным.
Алтын Айлар хозурыннан
Тыңлыйм моңлы азаның!

## *Җанның олысы*

Күзәнәгем саен синең исем,
Йөрәгемдә кулың җылысы.
Җыйнак кына гәүдәң,
Чандыр буең –
Ә үзеңдә җанның олысы.
Искә төшкән саен игелегең,
Үксеп-үксеп килә елыйсы.
Чыгып йөгерәсе – белмим кая,
Давыл булып килә дулыйсы...
Миңа мәңге шулай язган микән
Авыр язмыш белән яшәргә?
Яраланган күңелемне, әнкәй,
Синең җылың гына яшәтә.

## *Тарихи калам*

Башкалам минем, таш калам Казан,
Дәшеп китерден үзеңә, Казан.
Серле зур калам, тарихи калам,
Гомер буена мин синдә калам.

Башкалам минем, таш калам Казан,
Рухи мәркәзем, гомер елъязмам.
Синнән моң алып, илһам-нур алып,
Ямьләнә кебек бүгенге заман.

Башкалам минем, таш калам Казан,
Мең яшең әнә капкаңны кага.
Күпме милләтләр, дус-тату яшәп,
Синдә бәхетен, тәхетен таба.

Мәгърур башкалам, шәһри Казаным,
Үсмер елларым, яшьлек юлларым.
Насыйп булсачы каршы алырга
Гомер азагын
Синдә, Казаным!

## *Башка чарам юк*

Йә, хуш, дустым,
Туган авылыма кайтамын,
Болай да мин монда яшьлегемнең
Уздырдым бит инде байтагын.
Яратуым, ахры, шул булгандыр,
Кич җиттеме, сине көттем мин.
Ләкин нишлим,
Бу якларда түгел,
Еракларда туып-үстем мин.
Менә хәзер чакыра шул тугайлар,
Туганнарым, авыру карт анам.
Сөйгән ярым диеп, монда калсам,
Каберенә бары кайталам.
Кичер, дустым, бүтән чарам юк –
Күрми калсам, башка анам юк...
Әгәр синнән җылы хәбәр алсам,
Мин дә өзелеп хатлар язармын.
Хатың аша үз янымда тоеп,
Күзләреңә сөеп карармын.

## Йөземне ак иткән кешем

Йөзлек белән туганмын мин
Туганда ук.
Җир йөзеннән куганда су,
Куганда ут,

Саклап калган шул йөзлегем,
Иткән ярдәм.
Йөземне ак саклар өчен
Япкан пәрдәм!

Йөзлек белән туганмын мин
Туганда ук.
Башымда – уй, җанымда – җыр,
Йөрәктә – ут.

Ярты юлда туктап калмам
Бер эштә дә.
Рәхмәт яусын әнкәемә,
Йөземне ак иткән кешем –
Фәрештәмә!

## Рәнҗетмик әнкәйләрне

Рәнҗетмик әнкәйләрне,
Талкынган күңелләрен.
Дорфа сүзләр әйтә-әйтә
Кыскартмыйк гомерләрен.

Дөнья болай да катлаулы,
Тормыш болай да авыр.
Фатихалы булып яшик,
Сызмасын үпкә-бавыр.

Рәнҗетмик әнкәйләрне,
Алар дигәнчә булсын.
Безнең ярдәм, җылы сүздән
Йөзләренә нур тулсын.

Гомерләр болай да кыска,
Язмыш болай да авыр.
Уралышып бергә яшик,
Сызмасын үпкә-бавыр.

## Бергә яшик

Иңнәремә кулың куйдың,
Күңелемә җылы тулды, әтием.
Гөрләп торган тавышларың
Баса борчу-сагышларым, әтием.

Имәндәй төз, таза чагың,
Син һәрвакыт безне сагын, әтием.
Куз бетмәсен учагыңда,
Наз бетмәсен кочагыңда, әтием.

Синең белән тормыш җиңел,
Синең белән шаттыр күңел, әтием.
Гомер буе бергә яшик,
Бергә дөрлик, бергә яшьник, әтием!

## Әтием, әткәй генәм

Күргәнем юк басу-кырда
Иманнең иелгәнен.
Син булганда, әнкәемнең
Бәхеткә тиенгәнен –
Сизеп тору рәхәт безгә,
Әтием, әткәй генәм.
Гомерегез бергә үтсен,
Бергә, тигезлек белән!

Сөюегез татлы булсын,
Тиңнәр сез әнкәй белән.
Сабак бирсен ялгышыгыз,
Алга дәшсен язмышыгыз,
Әтием, әткәй генәм.
Яратышу хисегезне
Күңелем белән сизәм.

Кызларыгыз үзе әни,
Улыгыз – әти, күрәм.
Сызланып үткән гомерләр,
Сизелеп сүнгән күңелләр –
Алар сезнеке түгелләр,
Әтием, әткәй генәм.
Без – уллар һәм кызларыгыз –
Бәхетле шуның белән!

## Әнкәй миләше

Юксынуым шундый көчле, әнкәй,
Сагынуым шундый сагышлы.
Җилле көнне миләш тәрәз какса,
Ишетәм күк синең тавышны.

Үз кулларың белән син утырткан,
Син яраткан агач – бу миләш.
Синең кебек нык та, шифалы да,
Синең кебек сылу, мәңге яшь.

Сүзең истә:
«Бала бишегенә –
Иң шәп сиртмә – миләш агачы.
Күз тигезмәс өчен сөйкемлегә –
Беләзек ул – миләш агачы.

Туң җимеше ис тиюне ала,
Көч-дәрт бирә миләш катыгы.
Тылсымлы бу агач,
Бәйле аңа
Тормышларның ибе, ватыгы...»

Җилле көнне миләш тәрәз кага,
Алып килә синең тавышны...
Гүя тылсым куеп киттең, әнкәй,
Яңартырга бәхет-сагышны.

# *Күзкәйләрең нурлы чәчәк булып...*

Гөлкәйләрең, әнкәй, ятим калды,
Кем су сибәр инде аларга?
Таллар белмәс инде, дигән идең,
Шаклар каттым карап талларга.

Табигатьтә бар да башын игән,
Бар да моңсу, бар да кайгылы.
Игеннәрнең уңган елы иде,
Бакча җимешенең мул елы.

«Кызым» дигән назлы пышылдавың
Дөнья матурлыгын күрсәткән.
Гөлләр чәчәк аткан көннәрдә,
Күзләребез гөлгә нур чәчкән.

Бар яшәүнең сере синдә булган,
Бар гөлләрнең нуры – күзеңдә.
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе дә
Булган икән «кызым» сүзеңдә.

...Киттең, әнкәй, безне калдырдың син,
«Кызым» диеп инде кем дәшәр?
Күзкәйләрең, нурлы чәчәк булып,
Көннәрдә, әнкәй, гел яшәр!

## Гөнаһсызга...

Тулгаклап бала тапкандай,
Тудырган җырларымны,
Газап белән иҗат иткән
«Улларым, кызларымны» –

Салкын җилдән саклар өчен
Булмаса да канатым,
Ирек бирмәмен аларның
Сатарга яман атын!

Гөнаһсызга рәнҗетелсә,
«Күңелләре» кителсә,
Йөрәгем чыдамас кебек,
Гомерләре киселсә...

## Кайчан гына

Әле кайчан гына яз башланган иде,
Шау чәчәктә иде гөлләрем.
Синең белән генә булган икән
Мәңге сагыначак көннәрем.

Әле кайчан гына яз башланган иде,
Кыш ташланган иде ташуга.
Ап-ак карлар качып китте бугай
Түзә алмый язгы шау-шуга.

Әле кайчан гына яз башланган иде,
Яшь кыз идем мин дә ул чакта.
Инде менә алтын көзгә кереп,
Оныгыма сөйлим шул хакта.

# *Алтын алмам, оныгым*

Алтын алмам, оныгым,
Бөркелеп чыга нурың.
Бигрәк сөйкемле күрсәтә
Бит очыңның чокыры.

Чәчеңдә сөт исләре,
Күзеңдә яз төсләре.
Оныклы әбиләрнең
Кырга сыймый хисләре.

Сөбханалла машалла,
Тулыплар пешкән алма.
Җәһәт атла, җитез бул,
Йөгер, әткәңнән калма.

Кояшның җылы нуры
Ай нурыннан яктырак.
Бу дөньяда берни юк
Онықлардан татлырак.

Алтын алмам, оныгым,
Бөркелеп чыга нурың!..

## Сабый көлгәндә

Сабый бала көлгән мәлдә
Сихәт, дәрман йөгерәдер
Җанга, тәнгә.

Сабый бала көлгән мәлдә
Гашыйк җаннар, мәҗнүн парлар
Назлы хәлдә.

Сабый бала көлгән мәлдә
Нигез, җирлек салынадыр
Мәгънә, мәнгә.

Сабый бала көлгән мәлдә
Бөтен дөнья әйләнәдер
Тоташ ямьгә!

## Без дә шулаймы икән?

Дуамал җил дулый-дулый
Куптара болытларны.
Каударланып, уҗымнардан
Себереп ала карны.

Кар-юргансыз яшел уҗым
Өши, туңа бит инде.
Ник гайрәт чәчәсең, җилкәй,
Кемгә ачуың килде?

Яхшы һәм явыз тартыша
Үчле җил кочагында.
...Без дә шундый ямьсез микән
Усалланган чагында?

## *Улым — уң кулым*

Зур үссен минем улым,
Сузып иң тәти кулын.
Мәми ала белсен ул,
Рәхмәт әйтә белсен ул.

Яңгыратып өй эчен,
Күрсәтеп ап-ак тешен,
Нурлар чәчеп көлсен ул,
Хуҗа булып йөрсен ул.

Белсен ярый торганны,
Ярамаган эшләрне.
Күрсен игелек кылып
Яшәгән дус-ишләрне.

Дөньяның һәр шатлыгын
Шатланып кабул итсен.
Белсен нәсел-нәсәбен,
Җиде буынга җитсен.

Зур үссен минем улым,
Дәвам иттерсен юлын.
Эштә дә, киңәштә дә
Булсын һәрчак
Уң кулым!

## *Уйлый күңелем...*

Уйлый ла күңелем төрлесен,
Уйларның күңеллесен.
Сайлыйдыр җаным яшәүнең
Ямь-яшел бөрелесен.
Бөредәге яшьлегемнең
Гөрләп чәчәк атуын,
Акыл утыртып хисләрнең
Бадәнемә кайтуын.

Тәнгә сихәт, җанга ләззәт –
Уйларның күңеллесе.
Яз башында – яшәү дәрте,
Талларның бөрелесе.

Уйлый ла күңелем төрлесен,
Уйларның авырларын.
Шул уй телгән әнкәйләрнең
Ах, йөрәк-бавырларын.
Үксегән үксез балалар,
Ташлар иңрәгән тагын.
Имәндәй ир-егетләрнең
Башын моң баскан чагын.
Сарыларга сабышканын
Сагынып уйлаулардан.
Ике күзе күрмәс булган
Инәлеп елаулардан.

Уйлый ла күңелем төрлесен:
Авырын, күңеллесен,
Киләчәген, күрәчәген,
Үткәнен, бүгенгесен.

Уйлый ла күңелем төрлесен,
Уйлар йөгерек бит ул.
Уйлы күңел – утлы күңел,
Замана кебек бит ул!

# *Мәхәббәт иле*

Безнең як чишмәле, таулы,
Хисләргә бай як.
Чакырам чыклы таңнарга,
Чык яланаяк.

Син – минем яшьлек яшенем,
Иң татлы хисем.
Уйласам гына да сине,
Уң була эшем.

Тәпи баскан көннән башлап
Бергә үстек без.
Читкә китеп, саф хисләрне
Ятим иттек без.

Сагынып кайттым авылның
Айлы кичләрен.
Хыялымда яңартырга
Сөю хисләрен.

Туган авыл, туган җир бу –
Сихәтле җиле.
Ул – безне хыялга чөйгән
Мәхәббәт иле.

Син – минем яшьлек яшенем,
Иң татлы хисем.
Җир читеннән дәшеп алды
Мәхәббәт көче!

## *Кояш үпкән*

Табигатьне Кояш үпкән:
Карлар ява ап-ак күктән.
Туй күлмәге кияр чагын,
Күкнең Җирне сөяр чагын
Күңел көткән,
Көткән күптән –
Табигатьне Кояш үпкән.

Табигатьне Кояш үпкән:
Мамык юрганынмы сүткән?..
Килен күрмәк, кияү кермәк,
Җирне-Күкне сергә төрмәк
Чагын көткән,
Көткән күптән –
Табигатьне Кояш үпкән.

Табигатьне Кояш үпкән:
Кар бизәкле күлмәк теккән.
Мәхәббәтле ак биләмә,
Ак чыбылдык – ак бирнәгә –
Үзәкләргә Сөю үткән,
Табигатьне Кояш үпкән.

Табигатьне Кояш үпкән:
Җир күпергән,
Күкме чүккән?..
Елтыр күзле, йомры тезле,
Ерганаклар – чишмә күзле
Туар аздан,
Туар күптән –
Табигатьне Кояш үпкән!

## *Боз сарган каен кебек*

Җиргә кадәр иелгәннәр
Боз яллы ак каеннар.
Җир йөзендә яшәүләрнең
Үз җае, үз пае бар.

Сыгылмалы ак каеннар
Иелеп котылганнар.
Әзмени соң бу дөньяда
Баш ими тотылганнар.

...Кылдан нечкә күңелләрне
Яраламыйк, кешеләр!
Каендагы калын боз күк
Җәзалар бит ишлеләр?

**II**

*Сөешеп яшәгән парларның*
*Көннәре кайгысыз үтсеннәр,*
*Күзләре яктылык сипсеннәр,*
*Елмайган иреннәр үпсеннәр.*



## *Елмайган иреннән үпсеннәр*

Күтәреп күңелем пәрдәсен
Җил түгел, син кердең, Сөюем.
Бу минем мәңгегә булсын дип,
Чын итеп, зур итеп сөюем.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр,
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Юлларга түшәлсен гөлбизәк.
Тизерәк кайт, минем Сөюем,
Калдым мин озатып, кул изәп.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Ихластан әйтелсен ярату.
Иң олы гөнаһ ул кемнеңдер,
Ялганлап, йөрәген канату.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Илһамы күзләргә күчсеннәр.
Мәхәббәт күтәрә, үстерә,
Парлылар сөелеп үссеннәр.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр.
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр!

## Якын яр

Агартты җирне, чистартты
Яңа яуган кар.
Ап-ак юлда син тап булдың
Якташ – якын яр.

Уртак икән хисләр, моңнар,
Уртак сүзләр дә.
Йөргән икән эзләребез
Басып эзләргә.

Күперләргә, күп серләргә
Яуды ап-ак кар.
Күңелләрне яңарттың син,
Якташ – якын яр.

## Көзге чәчәк

Чәчәкләрнең нәфис, затлылары
Корыганнар инде, кырау төшкән.
Сиңа шул да ярар диеп, ыслап,
Ямьсез тавыш килә әнәү төштән.

Миңа ярар...
Рәхмәт тәкъдиремә,
Язылганы шулдыр – соңгы чәчәк.
Гел чәчәксез үткән гомерләр бар...
Көзге чәчәк миңа көч бирәчәк!

## Таптык

Сөекле идек бер заман,
Сөйкемле идек без дә.
Гозерләнеп сорадылар
Туй ясыйк, диеп, көзгә.

Сөекле сыннар идек лә,
Кадерле җаннар идек.
Кемнәрнеңдер күзе төшкән
Бәхетле ярлар идек.

Сөйгәннәрне сөймәгәнгә
Каралды микән даным?
Санга сукмый киткән өчен
Каргалды микән җаным?

Кадерле идек бит без дә,
Кадерләрен белмәдек.
Үзебез сөйгән яр булсын дип,
Әллә кемне эзләдек,

Таптык...

## Яшә назга күмелеп

Күз тимәсен,
Кыз көймәсен
Уйнатсын уй дулкыны.
Җилкәнен тартсын,
Җилдерсен,
Йотмасын ут упкыны.

Күз тимәсен,
Кыз көймәсен

Чакырсын кайнар кочак.
Күзгә кергәч,
Кызыл түскә
Кучә дә куя усак.

Күз тимәсен,
Кыз күймәсен
Язмыш йөртә җилдереп.
Газиз балам,
Кыз туганым,
Яшә назга күмелеп!

## *Ачуланма, әнием!*

Бүген минем бәхетле көн,
Минем җырлыйсым килә,
Өермәдәй бөтерелеп,
Җилдәй уйныйсым килә.

Бүген минем хисем ташый,
Бүген миңа күңелле,
Бүген беренче хисләрем
Ялкын булып түгелде.

Ачуланма син, әнием,
Мин соңга калып кайттым.
Бүген бит мин гашыйк булдым,
Гашыйк булдым, яраттым.

Бүген мине Ул озатты,
Бит очларымнан үпте.
Беренче сөюем гүя
Мең төстә йолдыз чикте...

# Тудым сине яратырга

Синең яныңа ашыгам,
Җиләкле юллар үтәм.
Озакка китеп янымнан
Борчуга салма бүтән.

Синең яныңа ашыгам,
Сиңа серемне сөйлим.
Газизем, дип эндәшәсең, –
Назларым белән түлим.

Өметсез авыр уеңны
Сөюем белән юдым.
Җаныңа суык тулганда
Җылытыр өчен тудым.

Тудым сине яратырга,
Хан-солтаным итәргә.
Язсын тормыш йомгакларын
Икәү бергә сүтәргә.

Синең яныңа ашыгам,
Җиләкле юллар үтәм.
Яратам, дигән сүземне
Җаныңа киртеп китәм!

# *Гашыйк итте*

Керфек очларыңнан тама
Мәхәббәт тамчылары.
Шулар мине гашыйк итте,
Шулар мине гашыйк итте,
Шул хисләр камчылады.

Эрим күңелең назына,
Кайтам яшьлек языма.
Сөям, яратам сүзләре,
Сөям, яратам сүзләре
Күзләремә языла.

Сусаганбыз татлы хискә,
Сусаганбыз сөюгә.
Лаек безнең бу урату,
Лаек безнең бу ярату –
Дөньяда бер! диюгә.

Керфек очларыңнан тама
Мәхәббәт тамчылары.
Шулар мине гашыйк итте,
Шулар мине гашыйк итте,
Шул хисләр яучылады.

## Былбыл булыр өчен

Сайрый былбыл,
Сайрый былбыл,
Үзә генә үзәкне.
Йә, кайсыгыз былбыл җырын,
Былбыл юлын күзәтте?

Җыр-моңнарсыз тора алмыйм,
Җырга гашыйк хәзер мин.
Былбыл булып сайрар өчен,
Кош булырга әзермен!

## Ай сукмагы буйлап...

Су өстенә яткан ай сукмагы –
Асылмалы күпер-ныгытма.
Сөю назы тулган йөрәгемне
Юлларыңнан алып ыргытма.

Су өсләтеп, ай сукмагы буйлап,
Ал җилкәннәр тартып корабка,
Акчарлаклар булып мәхәббәтем
Оча сиңа,
Синең тарафка.

Су өсләтеп, ай сукмагы буйлап,
Колачларым җәеп җилләргә,
Очам, йөзәм,
Синең белән Миннән
Һәм Сөюдән торган илләргә.

## Сөю — сәгадәт

Күзләрең шундый серлеләр,
Күзләрең шундый моңлы.
Гашыйк булдым, дисәм, сиңа –
Соңладым микән, соңмы?

Гел елмаеп кына тора,
Карашың шундый якты.
Күз генә сирпеп карадым,
Йөземә ялкын капты.

Күзләрең шундый серлеләр,
Язарга җитми сүзем.
Сине күргән, очратканга
Ходаем бирсен түзем.

Сәгадәт ул олы сөю,
Бәяли белгәннәргә.
Бары тик бәхет китерә
Җаныдай күргәннәргә...

Күзләрең шундый серлеләр,
Күзләрең шундый якты.
Күзләреңә тап булды да
Җаным әҗерен тапты...

# Сүзсез буйсынган

Үткән көннәрдә, көткән төннәрдә
Тәрәз бозына язылган хатлар:
Мин – синеке, дип,
Син – минеке, дип.
Биргән вәгъдәләр, эчелгән антлар –

Бозылмас, диеп,
Юк, узмас, диеп,
Ямьле көннәрнең гамьле минуты,
Минем йөрәкне,
Синең йөрәкне
Җилкетмәс, диеп, чит йөрәк уты,

Ялгыштыкмыни?
Ябыштыкмыни
Батып барганда суда саламга?
Сусаганбыз шул,
Зарыкканбыз шул
Мәхәббәт дигән затлы тәгамгә...

Айлы төннәрдә,
Җилле көннәрдә
Сүтелгән толым, үтелгән юлым –
Серле кичеңә,
Сөю көченә
Сүзсез буйсынган мин – синең колың!

## *Көтелгән мәхәббәтем*

Мәдхияләр җырлыйсы бар
Бу алтын кулларыңа.
Гөлләр булып чәчеләсе
Йөрисе юлларыңа.

Күрелмәгән бәхетем син,
Көтелгән мәхәббәтем.
Иңләп йөрисе болыным,
Чәчәкле мәмләкәтем.

Җилләр булып тузгытырмын
Тыңлаусыз чәчләреңне.
Якты йолдыздай бизәрмен
Болытлы кичләреңне.

Күрелмәгән бәхетем син,
Көтелгән мәхәббәтем.
Иңләп йөрисе болыным,
Чәчәкле мәмләкәтем.

## *Җырлап йөрик*

Кимсетелгән күңелләргә
Кайгы уела инде.
Тама-тама бәгырьләргә
Моң-зар җыела инде.

Елап йөрмик әле һаман,
Җырлап йөрик әле без.
Бездә дә бит гашыйк булып
Елтыраган ике күз.

Көлеп йөрик,
Килеп йөрик
Бер-беребез янына.
Җылы сүздән,
Назлы күздән
Җанда илһам кабына.

Илһамланып,
Таңга калып
Яратыйк бу дөньяны!
Яшәтергә,
Яшәртергә
Килгәнбез ич без аны!

## Кайда син?

Чалт аяз зәңгәр күзеңнән
Илһам табар идем мин.
Бары тик сиңа багышлап
Шигырь язар идем мин.
Кайда соң син, кайда син?

Кемдер үтәлмәгән юлдан
Алга барыр идем мин.
Кара урманнар аркылы
Юллар ярыр идем мин.
Кайда соң син, кайда син?

Пыскып түгел, посып түгел,
Дәрләп янар идем мин.
Тик синең күзләр турында
Шигырь язар идем мин.
Кайда соң син, кайда син?

# Атылма, йолдызым

Янасың, йолдызым, җемелдәп,
Калкасың күңелем күгендә.
Син мине нурландыр, моңландыр,
Син мине иркәлә бүген дә.

Янасың, йолдызым, җемелдәп,
Сүнмә син, сүнмә, ян каршымда.
Мәхәббәт хисләрен үлчәми
Ник икән бер бизмән, аршын да?

Янасың, йолдызым, җемелдәп,
Кич буе, төн буе – без бергә.
Шул назың, шул язың өченгә
Мин риза утка да керергә.

Атылма, йолдызым, атылма,
Тап булгач язмышым юлына.
Челтерәп чыгар күк моң җырым,
Кагыл син күңелем кылына.

Янасың, йолдызым, янасың –
Нинди нур, нинди наз үзеңдә?!
Чак калган чаткысын сөюнең
Кабыздың моң тулы күземдә!

## *Әл дә син бар*

Табигатьнең хозуры син –
Ап-ак бәсем, кырпак карым.
Салкыннарда җылытырга
Әл дә син бар, сөйгән ярым.

Язгы таңның көмеш чыгын,
Шатлыкларның зурын, вагын
Күрсәтергә, кисәтергә
Әл дә син бар, сөйгән ярым.

Ямьле җәйнең җылысы син –
Юкә балым, җиләк кагым.
Әче-төче татытырга
Әл дә син бар, сөйгән ярым.

Көзге көннең муллыгы син –
Алтын төскә кергән чагың.
Илһамият илләрендә
Әл дә син бар, сөйгән ярым!

## *Соңгы табышың*

Вак хисләргә, үпкәләргә
Алмаштырма сөюне.
Башка мәшәкатьләр кötә
Безнең янып-көюне.

Йөрмә шатлыгым-кайгымны
Белмәмешкә сабышып.
Мин барыбер мәхәббәттә
Синең соңгы табышың.

Мәхәббәт ул олы дөнья,
Әмма ваклык сыймасын.
Көнче ут төртергә түгел,
Күз сирпергә кыймасын.

Йөрмә шатлыгым-кайгымны
Күрмәмешкә сабышып.
Мин барыбер мәхәббәттә
Синең соңгы табышың!

## Күзләремә карама

Карама син күзләремә томырылып.
Карашыңнан,
Күзләреңнең карасыннан
Өзелер дә төшәр йөрәк,
Умырылып.

Карама син күзләремә томырылып.
Карашыңнан
Тишелер дә җан пәрдәсе,
Кара көчләр керер бәреп,
Убырылып.

Карама син күзләремә томырылып.
Карашыңнан,
Күзләреңнең гайрәтеннән
Газиз җаным чыгар төсле
Суырылып.

Карама син күзләремә томырылып.
Карашыңнан
Сихерләнеп, көчсезләнеп,
Ирексездән сиңа атлыйм
Куырылып...

## Син барда

Ак карлар буранлый күңелдә,
Ак нурлар сибелгән күпергә.
Ашкындым шул юлга керергә,
Ашкындым сине бер күрергә.

Ашкындым, ашыктым, тизләдем,
Чакырып китерде сүзләрең.
Яктырды, елмайды йөзләрең,
Ут чәчте, нурланды күзләрең.

Ут чәчә...
Сөюең ут суза.
Ут суза, көн уза, төн сыза...
...Кышлары елак та, котсыз да,
Син барда яшим мин утсыз да!

## Балкыт тормыш күген

Ишетәсем килә сүзләреңне,
Бик күрәсем килә күзләреңне,
Болын гөле арасында калган
Миңа таба килгән эзләреңне.

Серле караш синдә тумышыңнан,
Керфегемә тигән сулышыңнан
Сискәнепләр куям, сөенечтән,
Мин канәгать синле тормышымнан.

Мин күкләргә эндәшәмен бүген:
Яшенлә син, балкыт тормыш күген.
Бергә табыйк, бергә тартып барыйк
Сөюләрнең саллы-сыйлы йөген.

## Сары яфрактай өзелеп

Тәмле телең – җан ашы,
Җырлачы бер, җанашым.
Иркәлә сүзең белән,
Мин шуны теләп килəм.

Көйдереп ал бәгырьне,
Син һәрвакыт кадерле,
Йөрәк гүя әҗерле,
Булма берүк җәберле!

Ирәеп, иркәләнеп,
Кинәнеп, кинәндереп
Сал сөю учагына,
Изерәт кочагыңда.

Җиңәлмәсен хыянәт,
Алалмасын кыямәт,
Сөендереп серең ач,
Куеныма кереп кач!

## Яңадан туу

Бу күзләрең нинди йолдыз эзли,
Нинди язмыш юрый сүзләрең? –
Мәхәббәтнең серле балкышында
Чагылып китә сылу йөзләрең.

Сөю сине кабат тудырган ич,
Тораташтай гәүдәң җанланган.
Баскан җирдә биеп таптанасың
Сөйгән ярың биргән фәрманнан.

## *Син минем белән серле*

Хыялларым белән кыяларга мендем,
Сөю хисләреннән исердем.
Синең белән җанны иркәләдем,
Синең белән ләззәт кичердем.

Дәрманыңа кушылып дөрлим әле,
Кызуыңа кушылып кабыныйм.
Син бары тик ярат кына мине,
Мин бары тик сиңа табыныйм.

Ярат кына, хыянәтсез ярат,
Яратышып гомер кичерик.
Гашыйк җаннар һәрчак көчле була –
Сөю белән таулар күчерик!

Синең белән генә бәхетле мин,
Синең белән генә мин түрле.
Минем белән син дә илһамлы бит,
Минем белән генә син серле!

## *Әллә төн матур?..*

Яратып килдең син,
Җан атып кердең син,
Караңгы төнне кыл
Урталай бүлдең син.

Серләшеп туймыйбыз,
Төне тын, безнеке.
Көнләшә гөлләрем:
«Кызый, син кемнеке?»

Кочакны тутырып
Бирдең, һай, ләззәтне,
Бүген мин кояшлы,
Бүген мин җәннәтле.

# Сәламеңне алдым

*Җыр*

Синең сәламеңне алдым,
Кочагым тулы шатлык.
Бергә йолдызларга очтык,
Ташулар булып актык.

Кушымта:

Мәхәббәт хисе күпләрнең
Сәлам хаттан башлана.
Өмет, өметләндер безне,
Өмет, безне ташлама!

Синең сәламеңне алдым,
Күзләрем тулы җиһан.
Каф тавы кадәрле булыр,
Шатлык хисемне җыйсам.

Кушымта.

Синең сәламеңне алдым,
Күңелем тулы илһам.
Җыр юллыймын,
Син дә шулай
Кабынып китәр булсаң.

Кушымта.

## Бердәнберем

Син – бар, син – бер, син – бердәнбер
Минем сөю офыгында.
Сине сөям, яратам мин,
Бу – җырым да, нотыгым да.

Син – бар, син – бер, син – бердәнбер
Мәхәббәтле халәтемдә.
Берне сөеп, берне көтү –
Табигатем, гадәтемдә.

Син – бар, син – бер, син – бердәнбер –
Тәһлил итеп укыйм шуны.
Аерырга вакыттыр ич
Күз яшеннән яңгыр суын?

Син – бар, син – бер, син – бердәнбер –
Көн дә телдә, хәрәкәттә.
Мәхәббәтнең олылыгы
Әйләнмәсен һәлакәткә!

## Сөю таңы

Керфекләремә кагылып
Кабына сөю таңы.
Аллы-гөлле балкышларга
Бизәлгән кояш ягы.

Иртәләремнең нурланып,
Җанга сер тулган чагы.
Киртә-пәрдәләрне үтеп
Килсен хәләле-хагы.

Килсен, керсен күңелемнең
Биксез тәрәзен ачып.
Озатырга язмасын һич
Күз яшьләренә манчып.

...Чәчләремнең карасына
Сибелгән картлык агы.
Бер картлыкта, бер яшьлектә
Җемелди сөю таңы.

## *Нурга мана*

Күз карашың таң нурыдай
Мәрхәмәтле, сөйкемле.
Бер кеше дә елмаялмый
Миңа синең шикелле.

Көләч йөзең бар нәрсәдән
Ягымлырак күренә.
Шул килүдән кереп калдың
Йөрәгемнең түренә.

Җырларың белән зурладың,
Моңнарыңа исердем.
Кемдер татый да алмаган
Сихри тойгы кичердем.

Күз карашың уйга салды,
Наз биләде җанымны.
Бер елмаеп карауларың
Нурга мана таңымны.

## Дөньямны ямьләндердең

Әй, син, сылу, ах, син, сылу,
Кашыңнан күзең кара.
Күңелемне алгысыттың,
Күрешмичә юк чара.

Әй, син, сылу, ах, син, сылу,
Тапкыр да син, җор да син.
Укып туймас серле китап,
Тәмамланмас җыр ла син.

Әй, син, сылу, ах, син, сылу,
Шаярма мәхәббәттә.
Син минеке булсаң гына
Мин синеке, әлбәттә.

Әфсен укыдыңмы әллә,
Башымны әйләндердең.
Юлымнан яздырдың, әмма
Дөньямны ямьләндердең...

## Йөрәгемдә ялкын бар

Вәгьдә бирмә, акча сузма,
Тәкъдим итмә алтыннар.
Сакла гына, якла гына –
Кагылмасын салкыннар.

Вәгьдә бирмә, акча сузма,
Тәкъдим итмә көмешләр.
Ярат кына, яңарт кына –
Алга китәр бар эшләр.

Вәгьдә бирмә, акча сузма,
Күчерәм, димә, таулар.
Гашыйк җаннар биеклекне
Сөюе белән яулар.

Вәгьдә бирмә, акча сузма,
Тәгъдим итмә алтыннар
Дөрлет кенә, үрләт кенә –
Йөрәгемдә ялкын бар!

## *Язгы ярсу*

Язгы сулар,
Көмеш сулар –
Әйтерсең күзгә.
Язгы сөю,
Саллы сөю –
Сабыйдай изге.
Язгы ташу,
Язгы ярсу –
Әйтерсең бездә.
Язгы сөю,
Назлы сөю –
Әйтерсең үзгә.
Язгы суда,
Бозлы суда
Кояш чагыла.
Йөрәккәем
Сабый чагын,
Язын сагына.

# Мәхәббәтем чәчәк атты

Үләндәге чык тамчысы,
Үләндәге чык тамчысы –
Таң кызының күз яшьләре.
Төн егете, ник елаттың?
Төн егете, ник агыздың
Таң кызының күз яшьләрен?
Сорау бирә сердәшләре –
Ник коела күз яшьләре?

Гөлдә энҗе бөртекләре,
Гөлдә энҗе бөртекләре –
Таң кызының күз яшьләре.
Төн – караңгы, уйлар – якты,
Төн – караңгы, уйлар – якты,
Хәйран калды сердәшләре –
Алар шатлык күз яшьләре,
Алар шатлык күз яшьләре.

Төн караңгы, уйлар якты,
Төн караңгы, уйлар якты –
Мәхәббәтем, сөю хисем
Таң гөлендә чәчәк атты.

## Җылы кулдан

Җилләр, җилләр
Көн дә исә,
Исә-исә
Җанны кисә,
Көн дә дулый,
Нидер юллый...

Уемны җил
Тузгытканчы,
Ертып-йолкып
Ыргытканчы,
Язып куйыйм
Җылы кулдан.

## Гөлнең җаны үлә микән?

Гөлләр дә төш күрә микән?
Язмышына күнә микән?
Берсе – кол, димәк, хезмәтче,
Икенчесе – түрә микән?

Гөлләр дә төш күрә микән?
Кайгыда яшь түгә микән?
«Яратамын, китмә!» диеп,
Гыйшкына тез чүгә микән?

Гөлләр дә төш күрә микән?
Яратканда үбә микән?
Күңелләре гел нәфисме,
Кайчак усал –
Сүгә микән?

Гөлләр дә төш күрә микән?
Төшендә таҗ үрә микән?
Күккә аша белә микән?
Гөлнең җаны үлә микән?

## *Суга сусатмас өчен*

Яз белән бергә килдең син,
Мин дә яз булып тудым.
Күңелем белән теләдем,
Сүзләрем белән кудым.

Ташуларда, юлны ялгап,
Күперләр булып яттым.
Ак таңнар булып аттым да
Ал кояш булып баттым.

Энҗе каштан, асылташтан,
Чыклар булып түгелдем.
Сиңа кушылган көнемнән
Сиртмә булып бөгелдем.

Салкын коега төшәсе
Килүдән түгел бер дә.
Саф суга сусатмас өчен
Синдәй ярларны җирдә.

## *Өлгергән миләш*

Әче дә генә миләш – тәлгәш-тәлгәш,
Суык тешләп, кайчан балланыр?
Очраша да көннәр аерыла –
Киләчәктә, бәлкем, ялганыр?

Котырып уңган миләш – тәлгәш-тәлгәш,
Миләш уңу, диләр, суыкка.
Уйларыма бәреп керәсең гел,
Чыгаралмыйм хәтта куып та.

Тәм йөгергән миләш – тәлгәш-тәлгәш,
Кышка кала, күзен җыймасаң.
Үкенечтә үтә икән гомер,
Хисең белдерергә кыймасаң.

Әче генә миләш – тәлгәш-тәлгәш,
Кырау төшәр, ә ул балланыр.
Очраша да юллар аерыла,
Киләчәктә, бәлкем, ялганыр...

## *Күтәп яшәү*

Йөгерәсең, йөгерәсең
Ап-ак томан эченнән.
Килеп кенә җиталмыйсың –
Ә мин авыр кичерәм.

Кочагымны җәеп торам,
Кулларымны арытма.
Күтәп яшәү көчле итә,
Егылалмыйм арып та.

Килеп җитсәң, күтәреп ал –
Үтәлсен бер теләгем.
Кочак җәеп сине көтәм,
Бардыр, ахры, кирәгең...

## *Кайтачакмын*

Мин бөредә әле,
Мин бөредә...
Җылы җитсә әгәр,
Кадер җитсә,
Чәчәк атачакмын
Кыш көне дә.

Мин бөредә әле,
Мин бөредә...
Әмер көтеп йөрим,
Үзем янам, көйрим,
Хәбәр булса синнән,
Таңнар кирәк, димим,
Әмма кичләрнең дә
Шәфәкълесен телим!

Мин бөредә әле,
Мин бөредә,
Ачылыр өчен назлы чәчәк булып,
Пешәр өчен алма кебек тулып,
Бер ым кирәк
Йә бер караш.
Көләр өчен,
Күңелемне
Шигырь итеп сөйләр өчен,
Гомер сукмагыннан барган юлдашымның
Күңеле яхшы булу кирәк,
Тугрылыгы кирәк!

Мин бөредә әле
Мин бөредә...
Җиргә җәйләр булып кайтачакмын,
Синең өчен чәчәк атачакмын,
Ташу көткән елга ярларына

Тере басма булып ятачакмын,
Сиңа нурын сипкән кояшларның
Иң соңгысы булып батачакмын,
Мин бөредә әле...

## *Бәхетле бул!*

Мәңге дә бәхил түгел,
Бәхетсез булсаң әгәр!
*Хәсән Туфан*

Төшләремә минем керәсең дә:
Бәхетле бул, бәгърем, диясең.
Ак мендәрне кочкан чәчләремне
Бөртегенә кадәр сөясең.

Ак мендәрне кара чәчем кочкан –
Бу фалны соң ничек юрыйсың?
Синең һаман үз туксаның туксан,
Бәхетлеме, диеп сорыйсың.

Чәчләремне сыйпап сөясең дә
Баш очыма төйнәп өясең.
«Баш түбәмә кайгы өймә, бәгърем,
Тарат, зинһар!» –
Килә диясем.

Бәхетле бул, бәгърем, диясең дә
Бармак янап үзең көләсең.
Әйтәсең кук: син бәхетсез булсаң –
Бәхил түгел, үзең беләсең...

...Син яраткан кара чәчкәйләрем
Бөртегенә кадәр агарган.
Ак башымда кара кайгым шул син,
Төшкә кергән саен яңарган...

## Хис көче

Кайгы да елата безне,
Шатлык та яшь түктерә.
Һәм ни сәер, бу халәткә
Бер сүз илтеп җиткерә.

Йөрәгең ярып саласың
Кайчакта шул сүз өчен.
Кайчак мәдхия тәэсирсез –
Үлчәп кара хис көчен...

## Моң калдырып киттең

Моң калдырып киттең тугайларда...
Елгаларда – минем күз яше.
Давылларда – сизгер эчке дөньям,
Ай нурлары – моңсу сердәшем.

Моң калдырып киттең тургайларда,
Тугайларда – хәтфә яшеллек.
Яшеллеккә ятып еладык та
Торып бастык, яшьне яшердек.

Моң калдырып киттең тугайларда,
Тургайларың сайрый, сагына.
Без омтылган сөю офыгында
Пар канатлы тургай кагына...

# Сагынамын

Үз илемдә
Үксез калып
Үтте гомер;
Үксезләрнең,
Әйтсәм әйтим,
Җаны – күмер.

Сөюемнең
Ак былбылы
Очты кулдан.
Пакь уйларым
Тәгәрәде
Шомлы юлдан.

Ни күп җирдә?
Күп ятимнәр,
Күптер толлар.
Мәхәббәтнең
Ямен тоймас
Рухи коллар.

Уем белән
Уклыларга
Сарыламын,–
Кабына моң,
Агыла җыр –
Сагынамын!.

# *Яшерә дә алмыйм*

Ачыла да алмыйм,
Ачына да алмыйм –
Нинди хис бу,
Нинди ярату?
Ул хисләрне сөйләү,
Ул моңнарны көйләү –
Мөмкин түгел әйтү,
Аңлату.

Ашкына да алмыйм,
Ашыга да алмыйм,
Сүнәм, ахры,
Калам көлләргә.
Гаҗәп булыр микән,
Сәбәп булыр микән,
Ләззәт булыр микән кемнәргә?

Табына да алмыйм,
Кабына да алмыйм –
Кипсә кибә икән чишмәсе.
Күңел күзем йомык,
Уйлар акмый торып
Җан уянмый,
Булмый иртәсе.

Яшерә дә алмыйм,
Яшәрә дә алмыйм,
Яңара да алмыйм язларда.
Моңлы җырым булып,
Чәчәк кырым булып
Кайтсаң икән, азга-азларга.

Нинди авыр халәт,
Кайда уй һәм сәләт –
Сәбәп чыганагы ни булыр?
Һай, бу тол язмышы,
Һай, бу тол ялгышы –
Шатлыктан да күзгә яшь тулыр...

## *Сыеныйм дисәм*

Язгы кичләрдә – күзләрең,
Көзләрдә – көлүләрең.
Җәйдә – кочагыңа алып,
Бергенәм, диюләрең.

Кыш белән кайта кинәнеп,
Керт тә керт йөрүләрең.
Яратам, дигән тылсымнан
Үсенеп китүләрең.

Күз алдыма киләсең дә
Башыма уй сибәсең.
Сыеныйм дисәм бер генә,
Дөрләп якты бирәсең дә
Шәм утыдай сүнәсең.

## *Ләззәтләргә төрә*

Beләсеңме, җанда синең исем,
Телдә – зурлау, назлау сүзләре.
Сизәсеңме, таңда сине эзли
Хәләлеңнең коңгырт күзләре.

Таң яктысын кушып шигырь яздым,
Йөрәгемә яздым исемеңне.
Уйламадым җанга ут кабар дип,
Ялкын төрер диеп, җисемемне.

Үз-үземнән кача алмыйм хәзер:
«Яратам» дип язам йөз кабат.
Ләззәтләргә төрә, тоткынлыкка сөрә,
Утка-суга сала шул халәт.

## *Табигатьнең җырлы чагы*

Язгы кояш туры карый күзгә,
Ихлас итеп карый, яратып.
Шул сафлыкны, озын кышлар буе,
Күңел көтә, көтә, җан атып.

Язгы кояш могҗизасы белән
Хисләр сүзгә, назга әйләнә.
Исәпләсәң, ярты никахлашу
Яз гөлләре белән бәйләнә.

Язгы көннәр, сихри, серле көннәр
Алгысыта, алга чакыра.
Табигатьнең җырлы чагы җитә,
Сабыр бул син, күңел, чак кына.

# Серле көзге

– Серле көзге, сихри көзге,
Күрмәдеңме минем көзне?
Җаваплачы, ишет сүзне,
Күңел нигә аннан бизде?

– Җәй кояшлы сары көзең.
(Син түгелме идең түзем?)
Тәмле сүзең – гүя йөзем –
Алалмадың ике күзең...

Серле көзең – сүнде күзең –
Моң куырды нурлы йөзең.
Сүзләреңнең бетте тозы,
Зиһенеңне басты бозым...

...Сөйләп көзге, сихри көзге
Үткәнемне шулай тезде.
Гомеремне сүтте, сөзде,
Яман белән эшне өзде...

– Җәй кояшлы сары көзем,
Аны көтеп еллар түздем.
Балкыт кабат, нурла йөзем,
Гашыйк булсын ике күзем!

## *Кабат терелдем*

Чакырдың,
Нәни баладай
Йөгердем сиңа.
Күзләрең: алдалыйм, диеп,
Төбәлде миңа.

Ялгышасың, юк, алдашмас,
Дип карулаштым.
Егылдым...
Тагы килдем дә –
Күкләргә аштым!..

Ике арада бәргәләнеп
Сындым, сүрелдем.
...Искә төшердем дә сине
Кабат терелдем.

## *Синең бүләк*

Син бүләк иткән шигырь бу,
Син бүләк иткән җырым.
Син минем аяк басмаган
Хәтфә чәчәкле кырым.

Син бүләк иткән дөнья бу,
Син тудырган киләчәк.
Тышта әле кар бетмәгән –
Минем җаным шау чәчәк.

Син бүләк иткән бәйрәм бу,
Син бүләк иткән давыл.
Син ямь өстәгән шәһәр бу,
Син иҗат иткән авыл...

## Үз иткәч

Сагындым, дип, юлларымны күп таптагач,
Яратам, дип, авызыңны һич япмагач,
Ышандым бит, әйе, ышандым.
Ялгыз җанга терәк булыр дип тә,
Залим затка киртә корыр дип тә
Ышандым шул, әйе, ышандым.

Синнән откан матур җырны көйләп,
Сөя диеп, серләремне сөйләп,
Бушандым шул, әйе, бушандым.
Кыенлыклар миннән китәр дип тә,
Яңа тормыш бүләк итәр дип тә
Иске эздән күчтем, кымшандым.

Кадерсезгә калды тойгыларым,
Башларымны баскан кайгыларның
Авырлыгы төште иңемә.
Мәхәббәткә язык көч һәм гайрәт,
Сөя белү – үзе олы сәнгать,
Үз иткәчтен, тимә тиңеңә!

## Бардыр инде

Хәтер нигә кала икән,
Синең хәтерсезлектән?
Аңлаган да кебек булам,
Килешкән сыман күптән.

Бер гомергә торыр көнем
Бәясез сүнә сыман.
Арабызда бер тарала,
Бер куера күк томан.

Синең белән тынычландым
Һәм тынгымны югалттым.
Хыялымда ничәмә кат
Ябык капкаңны кактым.

Һәр елтырык алтын түгел, –
Сүктеләр: әй, син тиле!
...Колач җәеп каршы алды
Бәхетсезлегем мине.

## Күгәрченнәр иңгә куна

Авыл турында уйласам,
Уем сиңа кагыла.
Чишмә суы тамчысында
Синең йөзең чагыла.

Бакчагыздагы һәр шомырт
Яна синең күз булып.
Күгәрченнәр телгә килә
Син булып, иңгә кунып.

Колагымда – җыр-көйләрең,
Телемдә – шигырьләрең. –
Белмәдем шул мәхәббәтнең
Соңарып килерләрен.

## *Тагын кабынам*

Кара кайгыларның охшашлыгы,
Хисле күңелләрнең йомшаклыгы
Якынайтты, ахры, җаннарны.
Авыр икән җую җир йөзеннән,
Авыр икән җую ил күзеннән
Газиз бала, хәләл ярларны.

Кайчагында барып яннарыңа,
Йолдыз булып моңсу таңнарыңа
Нур иңдермәк, сөймәк буламын.
Мин үзем дә ярты кеше бугай,
Мин үзем дә парын җуйган тургай,
Елмаям да тагын суламын.

Якынлыкны күңел сизгән кебек,
Бер-беребезне күптән белгән кебек
Сагынам ла сине, сагынам.
Шәмдәлдәге шәмнең гомередәй,
Учакларның кузлы күмередәй
Янып сүнәм, тагын кабынам.

## *Ни хикмәт бу?*

Күңелдә юктыр юксыну,
Күңелдә юктыр көтү.
Күңелдә юктыр киная,
Төртмә сүз белән өтү.

Күңелдә юктыр кайгыру,
Күңелдә юктыр шатлык.
Күңелдә юктыр кинәнү,
Олпатлык һәм дә ваклык.

Түзә-түзә җан үлгәнме,
Ни халәт бу, ни хикмәт?
Әллә үзе яшәү микән
Әрнүле газап чикмәк?

## *Җайсыз сүз*

Кочак тутырып бирермен дип,
Бар назымны килдем җыеп.
Ә син, иркәм, куенымнан
Чыктың-чаптың, бик тиз туеп.

«Мин барыбер яратам»,– дип,
Йөрәгемә яздым уеп.
Үч алырга сөюемнән,
«Хыянәт» сүзе керде сыеп.

«Нәфрәт» диеп яза күрмә –
Үз-үземне торам тыеп.
Җайсыз әйтелгән авыр сүз –
Иртәгәңне алыр кыеп...

## Хәрәкәтсез калды

Күзләреңнең төсе зәңгәр күктә калды,
Диңгезләрдә калды, күлләрдә.
Елмаюың алсу чәчәкләргә сеңгән
Ачык йөзең – назлы гөлләргә.

Пышылдавың гүя таң җиленә күчкән,
Йөрешләрең – туйра-талларга.
Моңсулыгың микән, борчылуың микән
Чагылып алды уйчан таңнарда.

Алар бар да ялгыз, җансыз калды,
Синсез калды күкләр, елгалар.
Ал чәчәкләр, гөлләр, хәтта җилләр
Хәрәкәтсез калды туйралар.

Хәрәкәтсез һәм хикмәтсез калды,
Очкын сүнде күкнең күзендә.
Җиһан ямьләр нур бөркелгән икән
Син булганда җирнең йөзенә.

## Куркам ярам яңарудан

Сөюемә шаһит иде
Бу таулар, бу агымсу.
Агымсулар акты-китте,
Таулар дәшми, ямансу.

Таулар – телсез.
Сулар дәшми,
Диңгезләр эзләп бара.
...Дулкынын тапса да куркам –
Ачылыр кабат яра...

## Үземне алдап яшим

Чалкан ятып карыйм һаваларга,
Йөрәк яраларын дәваларга
Синең сүзең җитми, бәгырем!
Тиле кебек йөрим су буенда,
Кавышкан чак уйда, гел уемда –
...Инде чәчәк төргән каберең!

Юк-бар белән мавыгу калаларда,
Шомлы хәбәр кайта далалардан,
Күзен йома кинәт кайберең.
Җәбер күргән саен башкалардан,
Золым тигән саен «яхшы»лардан,
Арта бара синең кадерең.

Яфрак булып уем өзелә дә,
Йөргән юлларыма тезелә,
Гомер иткән ирем, җанкисәк.
Өзелгәнне ялгап тормыш итү,
Кеше елатканнан бәхет көтү –
Үз-үзеңне алдау – буш исәп...

## Саксыз кыландың

Хисләр белән саксыз кыландың син,
Килде-китте белән юандың.
Нәни генә кыек сүз әйтелсә,
Сәбәп табылуга куандың –
Күтәрелеп җәнҗал чыгардың.

Гомер итәр өчен килмәгәнсең,
Күмер итәр өчен килгәнсең.

Мин ышанып йөрәгемне бирдем,
Мәкерле уй белән йөргәнсең –
Дошманыма кулың биргәнсең.

Хисләр белән саксыз кыландың син,
Юк нәрсәдән дөнья кубардың.
Кемнең кемлегенә карамыйча,
Сер сакламак атың тугардың –
Сөю белән саксыз кыландың...

## *Очалар җилләр иркенә*

Җилфер-җилфер яфраклар –
Җилләрнең кочагында.
Яшел килеш ташланалар
Мәхәббәт учагына.

Әй очалар, әй кочалар
Буйсынып, бөтерелеп.
Шәрә агач, хурлыгыннан,
Утыра бетеренеп:

Үстергәнем, көч биргәнем
Җиргә булды аш кына...
...Карурманда – сары яфрак –
Күз өстендә каш кына...

## *Сузган кулын кире алмаячак*

Тупаслыктан тузып, теткәләнеп,
Түбәнсенеп туңган күңелне
Эретерлек күз карашы кирәк,
Җылытырлык әйтер сүземне.

Хурланудан күзләр томаланып,
Тернәкләнә алмый йөргәндә –
Ярты юлда куркып калмаячак
Кеше кирәк, хәтта үлгәндә.

Кеше кирәк, җан җылысы булган,
Саф тойгысы булган, чын Кеше.
Ышанырга мөмкин,
Гомер иткән чакта
Исбатласа шуны һәр эше!

## *Күз көеге булып*

Йөгерә яңгыр, йөгерә
Тузанлы урамнардан.
Яңгыр кочагына качам
Уйдагы бураннардан.

Ут йоткан кайнар хисләрем
Чылансын чәчләрем күк.
Кайчан күзгә күренерсең,
Сөйлисе сүзләрем күп.

Сөйләр сүзләрем түгелсен
Тамчы булып, яшь булып.
Карсак, очсыз вәгъдәләрең
Агызыйм суга салып.

Күз көеге булып янә
Бәргәләнеп йөрмәсен.
Болыт булып килмәсен дә,
Яңгыр булып сеңмәсен.

Бозлы вәгъдә-болытыңнан
Афәт-михнәт акмасын.
Көяләнеп көйгән җанны
Телгәләп тәм тапма син!

## *Җиләкләр*

Алдану,
Тоташтан алдану –
Әрни соң йөрәгем,
Хурлана.
Шул ялган,
Шул яман эчендә
Өметем,
Өлешем урлана.

Янымда яшәгән ялганчы,
Юкса бит назымнан исерде,
Җаныма иң авыр вакытта
Тотты да кырыйга сикерде.

...Яшеннән каралып көйрәгән
Каен кук алданган мәхәббәт.
Буй-сыны димәгез гашыйкның,
Күңеле саф булсын, мәһабәт!

Җәйләрнең ахыры...
Кызарып
Кипшенеп сөрлеккән җиләкләр.
Берьяклы сөю дә нәкъ шулай,
Таптала җиләктәй теләкләр!

## Кемдер әйтте

Актарыла кар елгада
Бозларны куя өеп.
Кемдер әйтте:
Тик яз гына
Зур тормышның
Чын юлын башлый, диеп.

Каеннар кайта илемә
Яшел күлмәген киеп.
Кемдер әйтте:
Тик яз гына
Керсез бәхет
Бүләк итәлә, диеп.

Гөлләр, чәчәкләр кайталар,
Кояшка башын иеп.
Кемдер әйтте:
Тик яз гына
Саф мәхәббәт
Бүләк итәлә, диеп.

## Казан белән бер кыз сөйләшә

Ара ерак. Җанны якынайтып,
Чакырым баганасы гүләшә.
Парлап кунган кошлар гөрләшә,
Телефонда дуслар серләшә.

Үткәргечләр бәсле ак кына,
Җил тирбәтеп куя сак кына.
Энҗе карлар коела чак кына,
Үткәргечләр бәсле ак кына.

Гашыйк күңел сөя, хис кайный,
Минут ага, аны кем саный?
Сөю утларында кем янмый,
Гашыйк күңел сөя, хис кайный.

Баганада кошлар гөрләшә,
Телефонда дуслар серләшә,
Казан белән бер кыз сөйләшә.

## *Чынлап әйттеңме?*

Син чынлап әйттеңме, кадерлем,
Бирмимен сине, дип, җәбергә?
Син мине, ай-һай, нык зурладың,
Иң лаек кеше, дип, кадергә.

Син чынлап әйттеңме, кадерлем,
Яраткан кешем, дип, син генә?
Мин сине гомергә ташламам,
Син мине кадергә төр генә.

Син чынлап әйттеңме, кадерлем,
Син минем өченгә изге, дип?
Мин сине назыма төрермен,
Арала җәбердән, көзге ит!

## *Читкә сипмә!*

Учак яктык,
Сөю учагына
Сиптек хисне, күпме кирәк, әй!
Ә ул янды,
Ялкын күтәрелде,
Ялкын теле иде көрәктәй.

Янды учак,
Бөтерелеп янды –
Сокландырды күккә үрелеп.
Әллә гайбәт, әллә күз тиюдән
Пыскып калды кинәт, сүрелеп.

Ялкын булып, ялкын тетерәнде,
Көнчел күзгә ялкын биреште.
Шашып янар, сөяр йөрәккәем –
Сүнгән хисләр белән көреште.

Бирешмик без, дидем,
Бүлешмик без,
Мәхәббәтен кайнар йөрәкнең.
Бу учакны бергә кабызыйк, дип,
Үзең киңәш иттең,
Өйрәттең.

Хыялларга күмик шул учакны,
Үрләтик без аны тагын да.
Читкә сипмә инде сөюеңне
Ут эленгән учак барында!..

...Ни ясканып туа алмый калган
Мәхәббәтем ята карында...

# *Җан теләгән*

Язмыш көлә миннән,
Мин язмыштан көләм:
Көлә-көлә карурманга керәм,
Көлә-көлә су буенда йөрим,
Көлә-көлә ап-ак карны күрим.

Көлә язмыш,
Шундый көлә миннән;
Хурга калып янган утка керәм.

Упкыннарга атыласым килеп
Яргаланган ярның якасына киләм.

Көлә язмыш,
Һаман көлә миннән,
Көлә-көлә урын ала түрдән;
Мәсхәрәгә калдың, дия кебек, –
Сөю тәмен тоялмаган ирдән.

Көлә язмыш миннән...
Ә мин җавап бирәм:
Ни кирәген үзекәем беләм.
Җан теләгән елан ите ашар,
Үзем сөйдем,
Әҗеренә – түзәм!

# Гомер күзе

Көз көне чыккан кояшым,
Көз көне аткан таңым.
Бу минем гомер көземдә
Җилкенеп чапкан чагым.

Көз көне чыккан кояшым,
Көз көне алган җылым.
Бу минем назлы, нәзберек
Тылсымлы, синле елым!

Көз көне чыккан кояшым,
Көз көне иңгән нурым.
Бу минем көздә күкерәп,
Яшенләп туган җырым!

Көз көне чыккан кояшым,
Көз көне сызган юлым.
Бу минем былбыл телендә
Сулкылдар, сызлар кылым!

# *Ярат*

Балкыйдыр хыял-гомернең
Сиңа төбәлгән төше.
Йөрәгеңдә кояш мәллә,
Әй, игелекле кеше?

Бер сөйләшсәк, күңелемнең
Тарала болытлары.
Җирләр җимертеп эшләрмен,
Елмаеп эндәш бары.

Бәгырькәемне өшетте
Дөньяның бозы-кары.
Мин дә кайчандыр, кемнеңдер
Идем бит сөйгән яры.

Синдәдер бөтен өметем,
Тарат, болытны тарат.
Тик нур сибеп,
Тик елмаеп,
Ярат син мине, ярат!

# *Мәхәббәтнең җиде төсе — гомернең җиде киче*

## 1. Әрсез мәхәббәт

Җиде йозакта иде бит
Йөрәгем ишекләре.
Ачма син, кагылма, дидем,
Ул гүя ишетмәде.

Шакып-шакып бер төрле дә
Уңай сүз алалмагач,
Каерып керде йозакларны
«Түзәрлеге» калмагач.

## 2. Күзсенгән мәхәббәт

Тауны-ташларны актарып
Табылган мәхәббәтем,
Кемнәрдәдер нәфрәт булып
Кабынган мәхәббәтем. –

Ялганган мәхәббәтем син,
Ялгышкан мәхәббәтем.
Алданган мәхәббәтем син,
Адашкан мәхәббәтем.

Янма, дигән саен янып,
Дөрләгән мәхәббәтем,
Калма, дигән саен калып,
Кабынган мәхәббәтем.

Күз тигән мәхәббәтем син,
Күзсенгән мәхәббәтем.
Күпсенгән мәхәббәтем син,
Кимсенгән мәхәббәтем.

Тәннәремә салкын булып
Йөгергән мәхәббәтем,
Күзләремнән ялкын булып
Түгелгән мәхәббәтем.
Ялганган мәхәббәтем син,
Ялгышкан мәхәббәтем.
Алданган мәхәббәтем син,
Адашкан мәхәббәтем!

### 3. Үкенечле мәхәббәт

Җылы яңгыр көтмим хәзер табигатьтән,
Җылы тоймас итеп җанны ул имгәткән.
Күз алдында тотам ирне – ул, димәктән,
Пыран-заран килде дөньям ир сөймәктән.

Пыран-заран килеп очты пакь хисләрем,
Башым тотып ах орамын, мин нишләдем?
Танымаса танымасын – эндәшмәдем,
Аның кебек нульдән түбән,
Юк, төшмәдем.

### 4. Кадерсез мәхәббәт

Йөгерепләр кердем,
Йөгенепләр сөйдем,
Бәхетем – син, дидем,
Тәхетем – син, дидем.
Шашып сөйгән кичнең,
Ташып торган хиснең
Бер сүз белән сүнгән,
Бер сүз белән үлгән
Кара гәүдәсемен,
Күзәнәгем саен
Җан газабы сеңгән
Алла бәндәсемен...

Калды мәхәббәтем
Кеше көлкесенә,

Сөяр хисем йөри
Этләр типкесендә.

Гашыйк булган ярым
Яңгыратып данын,
Таплап агын-пагын,
Ташлап сөйгән ярын,
Алга китте тагын,
Сизеп кемдер барын.

Кем берәүләр күп ул
Дөнья йөзләрендә,
Күз яшьләре тула
Баскан эзләренә.

Баскан эзләр аккан,
Аһәң килә арттан:
Күз яшенә баткан,
Киенә алмас актан,
Сөенә алмас чактан,
Тынгы булмас Хактан,
Акыл йөрсә арттан...

## 5. Соңлаган мәхәббәт

Үлеп беткәч, гомер бирде Ходай,
Исән калсын әле, дигәндер.
Хастаханә ишекләрен шакып,
Эзләп табасыңны белгәндер.

Авыр атлап эчкә узып киттем,
Тимер ишек куйды шакылдап.
Бәгыремнең әрнеп торган җире
Таш идәнгә төште шапылдап.

Таш идәндә газап эзе калды,
Синең эзең калды йөрәктә.
Тәрәзәмә нигә җил җибәрдең,
Йөрәгеңә фатир кирәктә?

Бушандың да китеп бардың әнә...
Буш урынга килеп утырып,
Кабат-кабат үз-үземне сүктем:
Читләр килми бәхет тутырып.

Читләр килми,
Үз иткәннәр килә,
Дип тартышты үҗәт күңелем.
Беләсең бит аның тормыш юлын,
Аңарга да җиңел түгелен.

Беләсең бит бөтен дөньясының
Асты өскә килеп әйләнгән.
Читкә киткән,
Чит милләтне табып,
Ирексездән чәче бәйләнгән...

Ирексезләп ирле булганнарны
Гаепләми бүген берәү дә.
...Фатихасыз туган гаиләне
Тота алмый әмма терәү дә...

Тота алмый.
Син дә килеп әнә
Офыгыңда очып кабындың.
Керфегеңне авыр сагыш сыкты,
Минем күздә сорау кабынды.

Тәүге мәхәббәтем, дип елмайдың,
Күз нурларың белән кагылып.
Сәерсендем,
Мин бит сине
Бүген күреп, бүген таныдым.

Таныдым да
Әйттем: соңга калдың.
Баш чайкадың, куйдың уфылдап.

Сине тышка, мине эчкә куып,
Тимер ишек сүнде шыкылдап.

Керфегеңнән коеп яңгыр яуды,
Минем күздә яшен яшьнәде...
...Гүя шушы якты бер мизгелдә
Сихәт сәгатьләрен яшәдем!

**6. Сүзсез мәхәббәт**

Тыныч карашларың нинди татлы,
Нинди затлы сүзсез хисләрең.
Алар минем һичбер алтынга да
Алыштырып булмас кичләрем.

Безнең яшьтә капыл гашыйк булу
Әллә савап, әллә гөнаһы?
Сине күргәч туган халәтемне
Ничек аңлатыйм соң, Илаһым?!

**7. Татлы мәхәббәт**

Сабырлыкның чиге була:
Үбәм сине кочып-кочып.
Югалырга уйлама да
Син – минем таң,
Минем – офык.

Йөзеңдәге һәр дулкынны
Күз карашым ала тотып.
Рәхәт тойгы били җанны:
Син – минем таң,
Минем – офык.

Тәмле телең әйткән сүзне
Йөрәк түрем бара йотып.
Беркемгә дә бирәсем юк,
Син – минем таң,
Минем – офык!

### *III*

*Бер Аллага сыгына ялгыз кеше*
*Кыен килсә төрле тарафтан.*
*Бөек Акыл һәрбер җан иясен,*
*Так итмәгән,*
*Парлап яраткан.*



## *Без Җирдә кунак кына*

Һәр көнебез бәйрәм булсын,
Елмаеп торыйк, балкып.
Мәңгегә килмәдек Җиргә,
Су кебек ага вакыт.

Егылып елыйсы түгел,
Очасы килә ярсып.
Йөзләрдә кояш уйнасын,
Борчу китмәсен басып.

Мәңгелек түгел бирәү дә,
Без Җирдә кунак кына.
Сөбханалла! дип, шатланып,
Әйтелсен җыйнап кына.

Мәңгегә килмәдек Җиргә,
Су кебек ага вакыт.
Һәр көнебез бәйрәм булсын,
Елмаеп яшик, балкып!

## Бәйрәм

Бәйрәм бүген,
Язгы бәйрәм!
Гөл-чәчәкләр –
Бәйләм-бәйләм.
Тып-тып тама
Тамчы-сәйлән,
Гөрләвекләр –
Әйлән-бәйлән.

Бәйрәм бүген,
Язгы бәйрәм!
Озынайды
Көннәр хәйран.
Күңелләрдә
Шатлык-сәйран,
Хозурланган
Башлар вәйран.

Бәйрәм бүген,
Язгы бәйрәм!
Бүләк өчен –
Энҗе-мәрҗән.
Әниләрне
Котлый һәркем,
Кыз-кыркынны –
Егет-мәргән! –

Бәйрәм бүген,
Язгы бәйрәм!

## *Гаиләм минем*

Гаиләм – гомер юлым ул,
Сиңа сузылган кулым.
Гаиләм – малым-мөлкәтем,
Гаиләм – синле җырым.

Мин гаиләмдә бәхетле,
Мин гаиләмдә хисле.
Мин гаиләмдә кадерле,
Гаиләм белән көчле!
Гаиләм – гамьле йөрәгем,
Гаиләм – юанычым.
Гаиләм – якты киләчәк,
Сабый күтәргән учым!

Гаиләм – таяныр ноктам,
Гаиләм – якты учак.
Гаиләм – улым, кызларым,
Гаиләм – кайнар кочак.
Гаиләм – табынлы түрем,
Гаиләм – назлы серем.
Гаиләм – бөтен бер дөнья,
Гаиләм – туган телем!

Гаиләм – өметле иртә,
Гаиләм – сихри кичем.
Гаиләм – җилкәнле җилем,
Гаиләм – хыял-хисем.
Гаиләм – гомер юлым ул,
Сиңа сузылган кулым.
Гаиләм – малым-мөлкәтем,
Гаиләм – синле җырым.
Мин гаиләмдә бәхетле,
Мин гаиләмдә хисле.
Мин гаиләмдә кадерле,
Гаиләм белән көчле!

## Өеңдә көтсә ярату

Көтсә өеңдә ягымлы күзләр,
Каршы йөгерсә кадерле сүзләр –
Елмаер кояш кара төнеңдә,
Җылы тоелыр салкын көне дә.

Көтсә өеңдә ихлас ярату,
Мөмкиндер анда кайгың тарату.
Авыр уйларың качар, онтылыр,
Шундый бер көнең – мең алтын торыр.

Көтсә өеңдә тәрбия, терәк,
Син диеп типсә анда һәр йөрәк.
Бәрәкәт иңәр бердәм нигезгә,
Тәгәрәр дөньяң төздә, тигездә.

Көтсә өеңдә кадер вә хөрмәт,
Сиңа дип пешкән ләззәтле нигъмәт. –
Үрнәк алып бу тату тормыштан,
Тәрбия күрер бала тумыштан!

## Шатландырып яшәгез

Ак кар булып, ак нур ява,
Хур кызы кебек балам,
Ап-ак күлмәкләрен киеп,
Кияүгә китеп бара.

Шатландырып әниләрне,
Туган-тумачаларны,
Һәр нәрсәдән кыйммәт күреп
Яшәгез сөйгән ярны!

## *Гөлләр, гөлләр*

Гөлләр, гөлләр,
Гөрләп чәчәк аткан
Күзен күзен япкан сылулар,
Безнең менә
Сездән илһам алып,
Таңга калып карап торулар.

Гөлләр, гөлләр,
Шигъри күңелләрнең
Тажы мәллә сезнең гүзәллек?
Безнең хәлләр
Сез булганда әйбәт.
Сез югында?..
Ни дим? Түзәрлек.

Гөлләр, гөлләр,
Шатлыгымны сөйлим,
Саклагыз сез аны шиңмичә.
Яшик бергә,
Бергәләшеп яшик,
Көзнең салкыннарын сизмичә.

## *Эзләдем, табалмадым*

Тамчы-тамчы гөлләреңнән
Күзләрем алалмадым.
Эзләдем дөнья бетереп,
Эзләрең табалмадым...

Табалмадым, тамалмадым
Тамчы булып, чык булып.
Мөлдерәмә күңелкәем –
Түгелде тулып-тулып.

# *Күршеләрем*

Күршеләрем, күршеләрем,
Якты йөзле кешеләрем,
Һәммәсе үз ишеләрем,
Һәммәсе үз кешеләрем.

Күрше хакы – Алла хакы,
Хаклыйк без күрше хакын,
Күршелекнең олы хакын
Мактап җырласын акын.

Күршеләрем кешелекле,
Якты йөзле, күренекле,
Тәмле телле, игелекле,
Һәр барчасы зур белдекле.

Күрше-күлән, оланнарым,
Якыннарым, туганнарым,
Йомыш тотмый торганнарым,
Уртак гамәл кылганнарым...

Күрше хакы – Алла хакы,
Хаклыйк без күрше хакын.
Күршелекнең олы хакын
Мактап җырласын акын.

# Йолдызымны калдыр

Җил кагылган саен сискәнәмен,
Ай кабынган саен үкенәм.
Кояшымны алдың,
Йолдызымны калдыр,
Миһербанлы бул, дип үтенәм.

Шәфкать-назны, ахры, кем бирәүгә
Мыскал белән генә биргәннәр.
Гүя безнең яшәү рәвешен
Кара җепләр белән үргәннәр.

Авырткан җир гел сызлаучан була,
Нечкә күңел никтер тиз тула.
Болай да бит авыр безнең тормыш,
Ни шәригать илдә, ни йола.

Тыныч кына хәтта гүрләрендә
Ята алмый сыман үлгәннәр.
Ләхетемә вакытыннан алда
Гөрзи белән гүя кергәннәр...

Җил кагылган саен сискәнәмен,
Ай күренгән саен үкенәм.
Кояшымны алдың,
Йолдызымны калдыр,
Миһербанлы бул, дип үтенәм!

## *Мандолинам*

Мандолинам, мандолинам,
Синең моңда очам, йөзәм,
Синең белән утырып елыйм,
Синең белән назны сизәм.

Кылларыңны кузгатамын
Бик күңелсез көннәремдә.
Челтер-челтер җырлатамын
Илһамланган төннәремдә.

Мандолинам, моңлы дустым,
Юатучым, киңәшчем син.
Минем моңсу кичләремдә
Яшәү өчен көрәшчем син!

## *Имгәнгәннең име*

Безне дә бит хәсрәт табыштырды,
Кавыштырды авыр кайгыбыз.
Бу килештән бәхил дөньясына
Беребез – Кояш, беребез – Айлыбыз.

Ике кисек, ике өзелгән җеп
Тирән уйлар, моңнар тудырды.
Сагыш куенында сагыш эреде.
Кайгыларны кайгы «туйдырды».

Имгәнгәннең име – иминнәрдә,
Имгәнгәннең ибе – игелек.
...Яннарыңда ятим җаннар юкмы? –
Як-ягыңа күз сал иң элек!

## *Пар-пар булып очкан торналар*

Үз ишләрем эзлим кешелектән, –
Тол хатыннар – минем тиңнәрем.
Барчагызның кайгыларын җыйсам,
Күтәрәлер микән иңнәрем?

Кырык бердә ятим калган җаннар,
Ни хәл итеп сезгә булышыйм?
Терелтер лә идем ирегезне –
Дәва булса әгәр сулышым.

Кырык бердә,
Кырык биштә калган...
Сиксән биштә калды бәгъзебез.
Еласак та үкенеп еламыйбыз,
Ир кочагы күрде тәнебез.

Кимсенүдән сүнә нурлы күзләр,
Күпсенүне – авыр күтәрү.
Көне ярый, көне кеше белән,
Кыен кичне, төнне үткәрү.

Киңәшләшер һәм серләшер сүзләр
Хәл итеlә ялгыз баш белән.
Шуңа микән толлар еш ялгыша,
Җавап ала ашка – таш белән.

Шуңа микән толлар бакчасына
Күсәк төшә, салкын боз ява.
Шуңа микән толлар җилкәсенә
Кеше күтәрәлмәс йөк ава.

Шуңа микән нахак бәла белән
Кыерсыткач, җаны таплана.
Мәкерле сүз телә бәгырьләрне,
Сүз ярасы озак саклана.

Толлар елый,
Башын бәрә-бәрә,
Үз-үзенә урын табалмый.
Яшәсәче кеше
Бер-берсенә
Утлы инә булып кадалмый.

Эчтән сыза,
Эчтән елый алар –
Дөрес аңлашылмас кемгәдер.
Тол хатынны тол хатыннар талый –
Хурлыклары үзәк өзәдер...

Бер Аллага сыгына ялгыз кеше
Кыен килсә төрле тарафтан.
Бөек Акыл һәрбер җан иясен
Так итмәгән,
Парлап яраткан.

Җирдә түгел,
Күктә матур була
Пар-пар булып очкан торналар.
...Толлар җаны,
Хыял ирке белән,
Күк катына барып торгалар...

## *Изге нәрсә бармы бу дөньяда?*

Калкынып,
Кайгымны җитәкләп,
Юл алдым иркәем янына.
Бер килсәм, ап-актан кабере,
Бер килсәм, чат чәчәк ябына.

Кайгыга җигелеп, җиңелеп
Тез чүктем сабыем алдына:
– Мәрхүмәм, кабереӊ кайда соӊ? –
Күз салдым кыйбла ягына.

Җилләрдән җитез бу уйларым
Сагаеп, саегып калдылар.
Ә җилләр сызгырып, ыжгырып
Йөрәккә шом-шөбһә салдылар:

– Куптарып чардуган-коймасын,
Урлады сәрхушләр, явызлар.
Эзләмә!
Эзен һич тапмассыӊ,
Сабыр бул, яшеӊне агызма...

Йә Аллам!
Кемнәргә сыеныйм?
Уйларым дөньяны буйлады.
Егылып иркәем янына,
Тәгәри-тәгәри еладым:

Сиӊа әйтәм...
Кызыбыз кабере... –
Уйларым башыма сыймады.
– Ни изге бу җирдә? Әйтегез?! –
Мәрхүмәм гүяки сорады...

Кайгымны җитәкләп йөгердем,
Югалыйм кайларга?
Авылга!
Коткарды нигезем,
Җанымның
Карасын юды да явымда...

...Үткәрдем монысын да хурлыкның –
Кара кан йотарга өйрәнгән.
Ни гаҗәп?!
Ни газап – дөньясы
Көчсезне сытарга көйләнгән.

...Исәннәр ярамны күрмәсен,
Уйларым таш булып күмелде...
Әрнүле күз яшем җиремә
Гөл булып шытарга түгелде!..

## *Кыен түгел*

Хатын-кызны алдау кыен түгел,
Кыен түгел көлү, җәберләү.
Хатын-кызны санга санау кыен,
Кемнәргәдер кыен кадерләү.

Кемнәргәдер кыен зур сүз әйтү,
Уңышларын күрү, үстерү.
Ә кемгәдер җайлы, әмер биреп,
Өмет-хыялларын кистерү.

Хатын-кызны җиңү кыен түгел,
Кыен түгел сүгү, тиргәшү.
Тик бизәми һичбер ир-егетне
Әни-кызлар белән терәшү...

## Хак әйтә

Аксакал, асылда, хак әйтә:
Ип белгән ирләрме иренгән?
Тарихка күз салыйк, күзәтик,
Мохтаҗлар – мокытлык иленнән.

Ялкауның язмышы – явымлы,
Юлына шайтаннар төкергән.
Яңгырның яшенле кылычы
Үшәннең сыртында сикергән.

Аксакал, асылда, хак әйтә:
Батырның байрагы югары.
Асылны яр иткән хатынның
Канаты сынганы юк әле!

## Йолдыз сүзе

Балкыйм галәм кочагында,
Янам бер йолдыз булып.
Янасың син дә, Айкаем,
Түм-түгәрәк сер булып.

Син яшәгән күктә яшим,
Күпләрнең берсе булып.
Бер үсәсең, бер шиңәсең,
Калтырыйсың күк туңып.

Мин бер йолдыз гына бары
Үз урыным, үз турым.
Еллар, гасырлар үтсә дә,
Үз биләмәм, үз кырым.

Син бердәнбер бу галәмдә
Һәм озын барыр юлың.
Тик үзгәреп тора йөзең,
Җылытмый салкын нурың...

# Илһам көче

Урман. Болын. Юлда юлчы
Чумган уй хозурына.
Сокландыра һәр үсемлек,
Карамый вак, зурына.

Яшел хәтфә үлән әнә
Келәмнән зиннәтлерәк.
Тәгәрә дә күккә кара,
Тагын ни хикмәт кирәк?

Күбекләнгән каурый болыт
Шыбырдый баш очында.
Күктән сикереп кояш төшәр
Чык суы ал учыңа.

Хәл җыярга тукта бераз
Каен күләгәсенә.
Җиләс, җылы һавасыннан
Җанга наз, сихәт сеңә.

Буйсындыра, уйландыра
Гүзәллеге, хозуры.
Бу – илаһи илһам көче,
Бар микән вагы, зуры?

# Шагыйрь буласың килсә

Сиңа киңәшем бар, дускай,
Шагыйрь буласың килсә.
Теләгеңә ирешерсең –
Юллар чатында калганда,
Ихтыяр көчең җиңсә.

Сиңа киңәшем бар, дускай,
Шагыйрь буласың килсә.
Теләгеңә ирешерсең –
Дөрләп кабынган хисеңә
Эреми йөрәк түзсә.

Сиңа киңәшем бар, дускай,
Шагыйрь буласың килсә.
Теләгеңә ирешерсең –
Хыянәтьнең, җинаятьнең
Юлын
Бер сүзең бүлсә.

Сиңа киңәшем бар, дускай,
Шагыйрь буласың килсә.
Теләгеңә ирешерсең –
Бәгырьдәге ташны тишеп
Телеңдә гөлләр үссә.

Сиңа киңәшем бар, дускай,
Шагыйрь буласың килсә.
Теләгеңә ирешерсең –
Шагыйрь булырсың,
Күңелең
Савап, гөнаһны белсә!

# Нурлы бала

Кулларыңа каләм алдың,
Әй, нурлы бала.
Сурәт сыздың, шигырь яздың,
Син – нурлы бала!
Шигырьләрең җырга күчәр
Әй, нурлы бала.
Иңнәреңә канат үсәр –
Син – нурлы бала!

Пумаланда сары төсләр –
Кояш төсләре.
Каләмеңдә зәңгәр кичләр –
Диңгез өсләре.
Аллы-гөлле бизәк төргән
Урман-болынны.
Таң җилләре куа чыккан
Җитез колынны.

Язган шигырь, җырларыңда
Әнкәң назлары.
Сурәтләрдә туган якның
Көзе, язлары.
Иҗат дәртең сүрелмәсен,
Уйлы, уйнак бул.
Балачагың бакчасында
Җырлы йомгак бул!

Кулларыңа каләм алдың
Әй, нурлы бала.
Сурәт сыздың, шигырь яздың
Син – нурлы бала!
Шигырьләрең җырга күчте
Әй, нурлы бала.
Иңнәреңә канат үсте
Син – нурлы бала!

# *Вәгъдә — иман*

Балачак елларының иң олы
мөгаллимнәре – әбиләребезгә
багышлыйм.

Туганым бар кечкенә,
Туганына өч кенә,
Ел дисезме?
Ай гына,
Туды әле май гына,
Шушы елның маенда,
Сут сикергәч каенда.

Шул нәп-нәни сеңлемне
Карыйбыз һәммәбез дә:
Әти белән әни дә,
Бабай белән әби дә,
Билгеле инде, мин дә –
Утырган чакта өйдә.

Әни мине шелтәли:
«Салынды бер көйгә,– ди.–
Су буена төшеп китсә,
Кайта белми өйгә»,– ди.

Беркөн кайткан чагымда,
Әбиемнең кулына
Килеп капкан чагында,
Менә мондый хәл булды.

«Улым,– диде әбием,–
Тиз әйләнеп керермен,
Утыр сеңлең янында,
Тик чыкма бер яры да.

Әгәр дә мәгәр ялгыз
Калдырсаң нәниләрне,
Әйтик, менә сеңлеңдәй
Бик сылу бәбиләрне –
Җен килә дә ала, ди,
Безнең бәби урынына
Үзенекен сала, ди.
Аналарга җәфа булып,
Җенле бәби кала, ди.
Аннан гомер буе чирләп,
Изалый шул бала», ди.

Әбиемнең сүзләре
Аптыратты.
Кит инде,
Үз сеңлемне күрәләтә
Җенгә бирмәм бит инде?

Ярар, дидем, тыңладым,
Тыңламыйча булмады.
Тик әбием, беләсезме,
Үз сүзендә тормады.
Тиз дип, чыгып киткән иде,
«Тиз»е һич тиз булмады.

Әбиемне көтә-көтә
Әллә ярты көн җитте.
Сабакташлар, урамдашлар
Безнең турыдан үтте.
Беләм инде, бөтенесе
Су коеныргa китте.

Ә мин менә берүзем –
Ишектә ике күзем,
Капкада ике күзем,
Урамда ике күзем.

Бер көн көткәндәй булдым,
Бер ай көткәндәй булдым,
Бер ел көткәндәй булдым,
Һәм болай дип, хәл кылдым:

Көпә-көндез, мин әйтәм,
Җеннәр йөрмәс бит инде.
Безнең бикле ишектән
Җеннәр кермәс бит инде?
Беләк буе баланы
Урлыйм, димәс бит инде?

Тоттым да болай иттем:
Бикләдем, чыгып киттем.

...Кичен кайтсам –
Ә-әй, малай!
(Озак тормадым алай.)
Кер әле, кер, дип, давай,
Урамда көтә бабай.

Әтием дә борчулы,
Әни хәтта елаган,
Үзе ләм-мим эндәшми,
Сеңлемне төреп алган.

Әби пошаманга төшкән,
Әйтерсең телсез калган...

Куркындым инде, малай,
Кызган чаклары самай.

Бабай карый әбигә,
Әти карый әбигә,
Әни карый әбигә,
Барысы карый әбигә.

Мин киткәч, әллә, чынлап та,
Җен килгәнме бәбигә?
Әллә шуңа ачуланып,
Карыйлармы әбигә?..

«Күп елаган, ярсыган,
Биләүләре чишелгән,
Җәй булса да өшегән,
Дөп-дөп тибә йөрәге,
Алыштырып куйган кебек,
Куркыткандыр өрәге», –
Бу – бабамның сүзләре.

Шунда серне төшендем,
Бишеккә күз төшердем.
Өнемме соң,
Төшемме?
Сеңлемме соң,
Үземе?
Әбиемнең, бабаемның
«Ай-кояшлы йөзе»ме?
Әтиемнең, әниемнең
«Шомырт кара күзе»ме?
Юк, ул, чынлап та, ямьсез,
Бәби, чынлап та, хәлсез.

«Нигә ташлап чыгып киттең,
Мине көтмәдең, мәнсез?
Куркып коты очкан сеңлең
Җен кебек булган әнә.
Күпме көч куярга кирәк,
Терелтү өчен янә», –
Дип сүксен иде әбием,
Йә кыйнап алсын иде.
Яңак төбемә бер бирсен,
Ут чыгып калсын иде...

Әби алай итмәде,
Гаебемне әйтмәде.
Әтиләр алдында сүгеп,
Тетмәмне дә тетмәде.

Ыгы-зыгы басылгач,
Икәүдән-икәү калгач,
Иплəп кенә сөйләде,
Хәтта тәүфыйк теләде.
Басып торып тыңладым,
Тыңладым да еладым.
Ул мине кайгыртып йөргән,
Мин аны утка салдым.

«Исеңдәме, велосипед
Сораган идең, улым.
Карасам, сатып яталар,
Шуңарга чират тордым, –
Ди әбием,–
Озакладым,
Чират җир буе иде.
Тик сеңлең...
чирләшкә
Булып калмаса инде?..»

...Их, шул чакта җир ярылса,
Кереплəр китәр идем.
Кабаттан эш кушсалармы,
Тәп-тәгәл үтәр идем.

Вәсыять әйтәм,
Берегез дә минем хәлгә
Берүкләр, юлыкмагыз.
Вәгъдә – иман, дигән сүзне
Гомергә онытмагыз!

# *Үксез итмәгез!*

Әти, әткәем, гомер юлына
Ияртеп безне син алып чыктың.
Алып чыктың да ташлап калдырдың,
Бәхетсез иттең, аяктан ектың.

Үзегез теләп үксез итмәгез,
Ятим итмәгез безне, әтиләр!
Елап-ялварып сорыйбыз сездән,
Мордар китмәгез, исән әтиләр!

Кемгә ышаныйк хәзер тормышта,
Безне үзегез әтисез иткәч.
Ирәеп кенә йөрер урында
Елап, кимсенеп көнебез үткәч.

Йөрәктә – әрну, күңелдә – үпкә,
Кабер янында башны исәк тә.
Тәннәр күшеккән, җаннар өшегән,
Әтисез калган тунны кисәк тә...

Үзегез теләп үксез итмәгез,
Үксез итмәгез безне, әтиләр!
Юк, хакыгыз юк, безне калдырып
Мордар китәргә, исән әтиләр!

# *Очрашу*

«Әниле» ятимнәр исеменнән

## 1

Гариза язып килмәдек
Бу якты дөньягызга.
Табу нигә кирәк иде,
Кертмәгәч оягызга?

Сыйдырмагач күңелегез,
Торагыгыз, өегез.
Нигә кирәк булды, йә әйт,
Безгә җан өрүегез?

Хәтта авыз иттермәгәч
Җылы күкрәк сөтегез,
Бер мәртәбә күрсәтмәгәч
Чыраегыз, битегез,

Ник тудырдыгыз дөньяга
Дөм ятим итәр өчен?
Урманнарга, вокзалларга
Ыргытып китәр өчен?

Уйларыгыз – азып-тузып,
Ләззәтләнеп йөрмәктә.
Шәп хуҗаның эте өйдә,
Этләре дә хөрмәттә.

Хайваннар да балаларын
Яламыйча ташламый.
Баласы күз яше белән
Туган җирен ашламый.

Кем килеп уллыкка алыр,
Кем алып кызы итәр?
«Әни» сүзен, һай, безнең дә
Әйтәсе килә бик тә.

Ерткычлардан мәрхәмәтсез
Баласыннан баш тарткан.
Шөкер әле җиде ят бар,
Кадер хисен яңарткан.

## 2

Кышкы суык.
Мәктәп бинасында,
Гөл-чәчәкле, якты бүлмәдә
Шигърият белән очрашу
Шагыйранә биек менбәрдә.

Әле шигырь,
Әле җыр агыла,
Кагыла-кагыла һәрбер балага,
Кереп тула нәни йөрәкләргә,
Сыялмас моң иркен далага...

Өнсез калган берәү:
Аерылып,
Каерылып җырга текәлгән.
Мин күзәтәм,
Димәк, моңның
Вазифасы бүген үтәлгән.

Кара,
Ничек йотылып тыңлый белә,
Суырылып шигырь сеңдерә.
...Әмма дөнья кемгә кояш элә,
Ә кемгәдер шәмен сүндерә...

Сискәндереп, күршем хәбәр бирә,
Күзем төшкән кызны күрсәтеп:
Чүп-чар савытыннан табылган ул,
Әйтеп куйыйм әле искәртеп.

Тудырганы нинди кавемнәндер,
Табып алган татар хатыны.
Шаярта да кайчак:
Урам себергәндә тапкан алтыным...

Мин кабаттан кызга текәләмен,
Очкынланып яна ике күз...
Йөрәгемне кысам учларыма:
Яшь чыгарма, шагыйрь, чыда, түз!

Их син дөнья,
Буялгансың йонга,
Дип әйтәсе килә, көрсенеп.
Гөл-чәчәкләр,
Җыр-моң арасыннан
Әче язмыш чыга бүселеп!..

Кышкы суык.
Мәктәп бинасында,
Гаҗәп җылы, якты бүлмәдә,
Гүя Үлем – Яшәү арасында
Очрашу иде бу мәлдә...

## Бәет һәм гаеп

Ачыкламый гына фаҗигасен
Сөйләмәгез алып гаепкә.
Мәсхәрәгә каршы торалмаган
Саф күңелләр керә бәеткә.

Инсаф тәрбиясе алган бала
Кичерәлми намусы тапланса.
Алкын суга сала ак гәүдәсен,
Мәхәббәте, җаны тапталса.

Бәетләргә керер изге җанга
Йога алмас гайбәт карасы.
Җир белән Күк аермасы булыр
Бәет белән гайбәт арасы.

## Бурыч

Ап-ак дөнья,
Яшел бизәк...
Кар түбәле тау – яшьлектә
Була сөзәк.

Кыш та кирәк,
Җәй дә кирәк:
Картлыгыңда яшел калу, –
Ай-һай, сирәк.

Зәмһәрир кыш,
Яшел ылыс.
Ел әйләнә гүзәл булу –
Синең бурыч!

## *Кичә һәм бүген*

Бу җир, имеш, аның «Берлеге»,
Туган якта фәкать кендеге...
Мал үрчетте,
Ялан тутырып,
Әйтерсең лә колхоз терлеге –
Кара көйде хәтфә киңлекләр,
Чәчәк атты: мин!
Мин... минлекләр...

Үз йортына борып агымын,
Ике кулсыз итеп авылын,
Биләп алды шифа чишмәсен,
Ишәрдәйнең ишеп ишмәсен,
Кырырдайның кырды «киштәсе»н.

Тайчанмыйча язык-хәрәмнән,
Оялмыйча һичбер адәмнән,
Өйде, җыйды, кисте, тешләде,
Ә бер көнне...
Әллә нишләде:
Шиңгән кикрик,
Төшкән иңсәсе,
Бушап калганмы әллә кесәсе?
Кайтып килә иптәш сайлаудан,
Ахры,
Эш чыкмаган «өсне» җайлаудан...

## *Юлга чыккач*

Юлның иң авырын үткәндә,
Менәлми син газап чиккәндә,
Алар бит көч-куәт бирделәр,
Менгерү хәстәрен күрделәр:
Эз салып, чытырман кистеләр,
Сазлыкта тал булып үстеләр...

Түбәсе күренгәч кыяның
(Артык зур иде шул хыялың),
Шөһрәтне бүлешмәс өченме,
(Әллә соң күптәнге үчеңме?)
Юк сүздән каныңны кыздырдың,
Сәфәрдәш дусларың туздырдың.

Юлларның авыры үтелгәч,
Тиздән зур хәзинә көтелгәч,
Берүзем яулыйм, дип, түбәсен,
(Каныңда мин-минлек, күрәсең.)
Ургылдың, ыргылдың, очындың,
Кыядан йөзтүбән ычкындың.

## *Изгелек кыл*

Гамьсезлеге өчен бер юньсезне
Оялтасың килсә әгәр –
Яхшылык ит.
Кызарсын ул
Чәч бөртекләренә кадәр.

Кем дә булса бер мөртәтне
Җиңү тиеш икән сиңа –
Изгелек кыл.
Ул үзе үк
Хурланыплар үләр шуңа.

# Ялгыз каен

Исән чакта яшәү биргән Җирең
Җәсәдеңнән гүя туена...
Кайда егылып, кайчан җан бирсәң дә,
Урын җәя йомшак куенына.

Басу уртасында ялгыз каен,
Кар көртләре төргән дүрт яктан.
Шыксыз җилләр үзәгенә үтә,
Тирә-юне бушлык, ак япан.

Мәңгелеккә күчкән адәмине
Тамырлары алган кочаклап.
Шул тамырлар үлем фаҗигасен
Сөйләтәдер кебек ип саклап.

Ачылмыйча калган хакыйкатьне,
Әйтелмичә калган сүзләрен,
Үтәлмичә калган вәгъдәләрен,
Үзе белән киткән серләрен.

Сөйләшәдер, аңлашадыр алар,
Их, телләрен белеп тыңласаң.
Бу дөньяның могҗизасы чиксез,
Һәр нокта сер – әгәр уйласаң.

...Җир алмаган җансыз гәүдәләр бар:
Кайсы – суда, кайсы көл була.
Бакыйлыкка күчкән газиз җаннар
Хатирәдә һәрчак гөл була...

Җан чыкканда чәчрәп каны чыга,
Бәхилләшү ансыз булалмый, –
Дип әйткәне истә өлкәннәрнең, –
Әҗәлләрдән беркем узалмый...

Басу уртасында ялгыз каен,
Кар көртләре төргән дүрт яктан.
Ак каенкай сергә, уйга чумган,
Яктысына кереп таң аткан...

## *Явыз күз*

Ялгыз башым ямьсез күзгә
Барып сыена.
Явыз күз минем кайгыдан
Госел коена.

Газиз башым салкын күздә
Калды ялгызы.
Минем язмышымны күзли
Күктән Ай кызы.

Ялгыз башым усал күзне
Әрли, каһәрли.
Аның саен арта бара
Күзнең зәһәре.

Явыз күз сынар өченгә
Бирсә дә сагыш,
Кайгылардан туплый алмас
Хәзинә, табыш.

## Ялгышканмын

Җирдән йөгереп барырмын,
Суларда йөзәрмен, дип,
Ялгызлыктан гына качыйм,
Барсына түзәрмен, дип

Ялгышканмын икән.
Язмыш:
Туктале, дигән икән.
Туганда ук, уч төбемә
Кайгы юл үргән икән.

Хыял төялгән корабым
Китте су төпләренә.
...Бәхет кошым канга баткан –
Инде ау этләрендә...

## Безнең караш

Вәгъдәләр биргән идек,
Вәгъдә үти белмәүчедән
Кычкырып көлгән идек.

Намус – зур! дигән идек...
Намусын югалтканнарны
Гаеплэп йөргән идек.

Инде җаннар вакланды –
Вәгъдәләрне үтәмәдек,
Намусыбыз тапланды...

# *Килми*

Язгы ташудай болганып
Гөрлисем килми минем.
Кеше күзендә чүп булып
Йөрисем килми минем.

Тели белми теләк теләп
Имлисем килми минем.
Бәхетемне тумас борын
Җирлисем килми минем.

Бәндәләрне белер-белмәс
Димлисем килми минем.
Агулы күз карашыннан
Чирлисем килми минем.

«Көйсез кияү»не туктаусыз
Көйлисем килми минем.
Өзми-куймый бер үк сүзне
Сөйлисем килми минем.

Төбенә җигелеп йөкне
Тартса да ялгыз иңем.
Юкны бушка аударучы
Түгелдер минем тиңем.

## Сүнде минем Кояш

Шатлыкларым юкка чыга бара,
Кайгы арасында адашып.
Кара болыт акты баш очымнан,
Карлы яңгыр яуды кайнашып.

Явыз болыт йотты йолдызымны,
Уртак айны хәтта каплады.
Шул сүнүдән сүнде минем Кояш,
Шул батудан таңым атмады...

## Бизәү өчен

Тормыш бизәү өчен ни кирәксә,
Җанны бизәү өчен шул кирәк:
Агымсулар, шау чәчәкле болын,
Шагыйранә кичләр, кайнар хисләр
Һәм сүнмичә янган яшь йөрәк.

Иман кирәк тормыш бизәү өчен,
Кирәк дуслар, юллар табарга.
Хыял кирәк күккә ашар өчен,
Дәрья суларыдай ташар өчен,
Ләйсән булып җиргә яварга.

Өмет кирәк җанны җылытырга,
Илне, күкне, өйне бизәргә.
Кошлар булып күккә очар өчен,
Күкрәгеңә җирне кочар өчен,
Төшенкелек кылын өзәргә! –
Шулар кирәк тормыш бизәргә!

## *Исәнлеккә, саулыкка...*

Бокал тотып сәламәтлек теләү –
Гайре сәер, гайре кызганыч.
Сәрхушләрдән кемнең рәхәт күреп,
Тапканы бар әле юаныч?

Хөрмәт итәм, диеп, якын дустың
Хәмер куйса табын түренә –
Якын түгел ул дус,
Якынайта бары
Барыр юлың кара гүреңә.

## *Нәтиҗә*

Ачның хәлен тук белми,
Туклар көлә, ач – көлми.
Җиделе лампа кыйммәтен
Кем белә – уты сүнми?

Нәтиҗәне ясар өчен,
Ерак барасы килми:
Кайсыбызның кадере бар,
Үлеп кабергә керми...

# Давыл алдыннан

Афәтле җил – ярсу була,
Тирә-юньне шом били.
Һавада карга көтүе
Кая качарга белми.

Агачлар билдән бөгелә,
Тынычсыз җанвар җаны.
Куптара җирне, күтәрә
Кара тузан томаны.

Күтәрелә караңгылык,
Каплый Җирне,
Дөньяны.
Гарасат үтүен көтә,
Шым кала: фил, куяны...

Давыллый,
дулый,
сызгыра,
Болытларны болгата.
Табигатьнең усал мәле
Кешедә мән уята.

Курку туа:
Нинди якын
Яшәү – үлем арасы.
Кисәтә күк:
Күркәм итеп
Яшә,
Адәм баласы!

## *Исеме нинди булса да*

Тудырдым,
Исем эзләдек –
Йолдызлар арасыннан.
Җете булсын, диеп, күзе
Зәңгәр күк карашыннан,
Раушания диеп куштык
Баш балам-багалмама.
Җайсызрак сүз әйтсәң дә,
Ике бите аллана.

Тудырдым,
Исем эзләдек –
Тагын бер җан иямә.
Диңгезче кызы лабаса,
Диңгез төсе – иягә.
Чәчүргечкә тасма алдым,
Дулкынлансын толымы.
Исемедәй нәфис булсын,
Фирүзә җилдәй – җылы.

Тудырдым,
Исем эзләдек –
Чәчәкләр арасыннан.
Төпчек кызым төпле булсын,
Китеп туган ягыннан
Ашкынмасын йолдызларга,
Ашкынмасын диңгезгә,
Җирдә калсын гомергә.
Матур булып чәчәк атсын
Резидәдәй тиң гөлгә...

Тудырдым,
Исем эзләдек:
Күктән, Судан һәм Җирдән.
Аты кем генә булса да,
Көч алсын Туган илдән!

## *Татар теле мөгаллиме*

Яратканга Туган телне,
Ана телен яратканга,
Гыйлем эстәү – чын татарча
Булсын, диеп, җан атканда

Кемнәр генә сүзләмәде,
«Кыйнамады» кемнәр генә?
Туган тел, дип сөйләнделәр,
Калды ләкин телдә генә.

Татар теле – Туган телем –
Бәхетсез тел булып йөрде.
Калдык-постык сәгатьләргә
Иң пүчтәк фән булып керде.

«Тара-бара», имеш, аны
Укыта ала һәрбер тинтәк –
Шул кадерсез мөнәсәбәт
Сеңдерелде җайлап, иплэп.

Саташты күп йомры башлар,
Голәмәсе, дин, хадиме.
Көрәштең син берьялгызың,
Татар теле мөгаллиме.

Сөю, әрнү газабыннан
Тамырларың шытым бирде.
Шәкертләрең бил турайтып
Басты бүген,
Күзең күрде!

Әнә шулай:
Сабыр холык,
Тыйнак акыл белән, димме?
Саклап Телне, сакла – безне,
Татар теле мөгаллиме!

## IV

*Күңел уйныйм,*
*Булыр микән*
*Чик-чамасы уенның?*
*Әй, замана,*
*Язмышымда*
*Ут уйнатып туендың...*



## *Матурлыкның бер өлгесе булып...*

Йөгереп барып офык ачар идем,
Йөгерепләр җитәр җир булса.
Чумырып алып суын түгәр идем,
Кайгыларым әгәр күл булса.

Болытларга очып менәр идем,
Сикереп төшәр идем җирләргә.
Йөрәгемдә сөю уты янса –
Мин бирешмәс идем чирләргә.

Матурлыкның бер өлгесе булып,
Җир йөзенә туган кыз идем.
Сөям, диеп сихерләндем генә,
Йөрәгемә утлы куз өйдем.

Кан ургылып чыкты күкрәгемнән,
Таң сызылып чыкты күземнән...
Башкаемда нинди уйлар барын
Укып кара, тойсаң, сүземнән.

# Яңгыр җыры

Яңгыр җыры, яңгыр моңы
Язын да, көзләрен дә.
Яңгырлы көн истәлеге
Калды шул күзләремдә.

Керфегемдә тамчы-тамчы
Җемелди шатлык яше.
Күз яшьләре дә елмая –
Бар да мәхәббәт эше.

Яңгыр җыры, яңгыр моңы
Иртән дә, кичләрен дә.
Лычма су булган чакларым
Яңгырда – исләремдә.

Исләремдә яңгыр моңы,
Күңелдә, колакларда.
Мәхәббәтле еллар калды
Яңгырда – еракларда.

# *Ят кулына бирмә*

Минем халәт – күзгә урман кебек,
Кышка кереп барган сәгате.
Күшектереп үзәкләргә үтү –
Көзге яңгырларның гадәте.

Минем халәт – шыксыз көн шикелле
Эңгер-меңгер төргән, караңгы.
Савыктырыр диеп, өметләнеп,
Ят кулына бирмә яраңны.

Минем халәт – кырку суык сыман
Куырып алып, җанны өшетә.
...Гомеркәем тоткын булып калды,
Ул керүгә килеп ишектән...

## *Төрле якка сибелдең*

Син бер пары, мин бер зары –
Боз түшәлгән упкынның.
Кояш нуры үтәлмәгән,
Көн җылысы җитәлмәгән
Тутыгып тынган кылның.

Син бер зары, мин бер кары –
Сөйкемсез, җепшек кышның.
Эземә басып йөрүең,
Килүең синең, күрүем –
Сихәтен алды ушның.

Син бер кары, мин бер чары –
Таланган күңелләрнең.
Ярлар күрде хисләремнең
Чәбәләнеп тә чайпалып,
Як-якка түгелгәнен.

Син бер яры, мин бер зары –
Көрт каплаган Иделнең.
Толлар өмете булып та,
Кияү егете булып та
Як-якларга сибелдең...

# Сак белән Сок кебек

Сак белән Сок булып,
Салкында бер туңып,
Бер кызып, бер сынып яшибез.
Мәхәббәт күгендә,
Син – анда, мин – монда
Бер чатнап, бер шартлап яшьнибез.

Мәхәббәт күгендә,
Син – анда, мин – монда –
Очабыз Сак белән Сок булып.
Очабыз елашып,
Елашып, җырлашып,
Син – миңа, мин – сиңа омтылып.

Очабыз елашып,
Үзебез таплаган,
Таптаган мәхәббәт каралган.
Сөюнең сарае –
Кадерен белмәүдән,
Кыйммәтен күрмәүдән таралган.

Мәхәббәт күгендә,
Син – анда, мин – монда,
Моң баскан күзләрне – яшьлибез.
Сак белән Сок булып,
Ымсынып, юксынып,
Талпынып, талкынып яшибез.

## *Пеште*

Җиләк кебек пештек,
Пештек алсуланып.
Килмәде соң кемнең
Карыйсы бер кабып?!

Җиләк кебек пештек,
Пешеп кулга төштек.
Ярсу мәхәббәткә
Алсу йөзне чиштек.

Чиштек серебезне,
Бирдек сүзебезне.
Яши-яши дөнья
Ачты күзебезне.

Җиләк кебек гомер
Тамып җиргә төште.
Тормыш ачысыннан
Инде авыз пеште...

## *Кире китәрмен*

Өметемне сиңа багълап,
Көн көтәм, атна көтәм.
Гамәлем белән нибары
Инә буе җир китәм.

Таптанам синең тирәдә,
Алга, артыңа төшеп.
...Сизәм: кире борылырмын,
Җаным, бәгырем өшеп...

## *Кайсы чын – шул калыр*

Хыяллар юл тота кояшка,
Без хыял хисеннән үрелгән.
Күңелләр, һай, нечкә булганга
Муеннан кайгыга күмелгән.

Бәхетен югалткан йөрәкләр
Зилзилә эчендә эзләнә.
«Китмә син, сөюем, кал янда», –
Бер гашыйк ярына тезләнә.

Бәһасез сөюнең кадерен
Белмәгән ярларга тел әрәм.
Кайсы чын – шул калыр,
Чыгам да
Хисемне җилләрдә җилгәрәм...

## *Кысыр калды алмагачым*

Суык булды быел язгы төннәр,
Алма чәчәкләрен кырау сукты.
Торалмассың аның белән дигән –
Көндәшемнең сүзе чынга чыкты.

Сулган чәчәкләрне җил очыртты,
Кысыр калды агач – озын елга.
...Арынулар, ай-һай, авыр икән,
Явыз җаннар керсә куеныңа...

## *Терсәкнең вазифасы*

Бозлы яңгыр булып яудың
Йөрәктәге учакка.
Шул кадерсез кичтән соң да
Кермәкчесең кочакка.

Һәрчак күндәм хатын идем,
Бүген мин дә бер кире.
Горурлык дигән сыйфатым
Җирләнмәгән,
Ул – тере!

Терсәк – тешләр өчен түгел,
Эшләр өчен.
Үкенмәм.
Әмма сине ул терсәккә
Башка якын китермәм.

## *Уен*

Күңел уйный: уй-хисләрем
Умарта күче кебек.
Гөжләп тора, гөрләп тора
Нәкъ вокзал эче кебек.

Күңел уйный, урын тапмый,
Бәреләдә сугыла.
Бер күкләргә күтәреләә,
Бер упкынга егыла.

Күңел уйный. Булыр микән
Чик-чамасы уенның?
...Әй замана,
Язмышымда
Ут уйнатып туендың...

# Минем җиңү

Бер селтәнде дөнья,
Кайгы сазлыгына
Кереп баттым,
Баттым тубыктан.
Юандым ла андый газапларга
Мин генәме, диеп юлыккан?

Бер селтәнде дөнья,
Бер кизәнде,
Үчекләште,
Нидер янады.
Суырылып бил тиңентен чумдым,
Баш калкытсам, тагы ямады.

Елар диеп көтте,
Егылыр дип,
Шартлап сынар диеп уйлады.
Кайнарлыктан сазлык үзе янды,
Минем өчен яшен елады...

# *Бер хыянәт иткәч*

Кавыштырды кышлар,
Җәйләр аердылар,
Җәйләр аердылар озакка.
Тагын кышлар үтәр,
Тагын җәйләр җитәр,
Очрашырбыз, дидек, шул чакта.

Кышлар, язлар үтте,
Көткән көннәр җитте,
Син килмәдең әйткән урынга.
Вәгъдәләрне бозып,
Күңелеңнән сызып,
Сагыш керттең минем җырыма.

Җәй аерды безне,
Көннәр җылы иде,
Күңелеңә синең кыш килде.
Үкенсәң дә үткәч,
Бер хыянәт иткәч,
Очрашулар безгә юк инде.

## *Аваз килә*

Сары урманнар сагышын
Алып килде күзләрең.
Йөрәгемә хәнҗәр булып
Кадалдылар сүзләрең.

Кара болыт күләгәсе
Төшкәнме йөзләреңә.
Кипкән яфраклар түшәлде
Юлдагы эзләреңә.

Ул эзләрдән юллар түгел
Тапланып калды күңел.
Синең өчен Күк оялып
Дәште күк: «Гафу, сеңел!..»

## *Хурлык шаукымы*

Кешенең асылы санап
Табынган идем.
Йолдызың булып яныйм дип
Кабынган идем.

Артыграк яндым, ахры,
Артык балкыдым...
Кадеремне ким күрдем дә
Җанны талкыдым.

Өтеп ала икән җанны
Хурлык салкыны.
Йөрәктә калган авырту –
Шуның шаукымы.

## *Шулмы соң егет эше?*

Аш биргәнгә таш ыргытса,
Сүндермәк чак ут ургытса –
Шул да булдымы егет?

Ярына кайгы китерсә,
Дәртен, дәрманын бетерсә –
Шул да булдымы егет?

Сөйгәненнән шымчы эзләп,
Йөрсә һәрбер эшен сүзләп –
Шул да булдымы егет?

Кеше кайгысыннан көлсә,
«Яшем төште» дип сөенсә –
Шул да булдымы егет?

Әйткән сүзләреннән танса,
Җәллләтмәккә яше тамса –
Шул да булдымы егет?

«Мин-мин» диеп күкрәк какса,
Гаепсезгә яла якса –
Шул да булдымы егет?

«Вәгъдә – иман»ны белмәсә,
Картаеп акыл кермәсә –
Шул да булдымы егет?

## *Халәтем — күзләремдә*

Кадер күреп –
Күзләремнең көлгән чагы.

Хәтер күреп –
Күзләремнең күнгән чагы.

Кабер күреп –
Күзләремнең сүнгән чагы.

## *Сөя дип уйладым...*

Мин сине сөя дип уйладым,
Син икән мәхәббәт уйнагы.
Төшкәндәй бармактан уймагым,
Тәгәрәп киттең дә югалдың,
Мин сине сөя дип уйладым.

Мин сине сөя дип уйладым,
Ә синең булган үз уйларың:
Йөгәнсез хисләрең, кичләрең –
Бер көнлек сөешү туйларың...
Мин сине сөя дип уйладым.

Мин сине сөя дип уйладым,
Онытылып, мәдхия җырладым.
Ах иттем, тәмле сүз көченә,
Шатландым, мактадым, зурладым,
Мин сине сөя дип уйладым.

Мин сине сөя дип уйладым,
(Шигемне әйтергә кыймадым.)
Сөюем артык зур булганга,
Ахыры, уеңа сыймадым,
Мин сине сөя дип уйладым...

# Мәдхия

Дөнья тулы сер, илаһым,
Әйтик, гади бер комган.
Эчләренә госел кояр
Көмеш сыман су тулган.

Энҗе-мәрҗән салып кайчак
Җир астына күмгәннәр.
Ат менгән сугышчы ирнең
Иярենә элгәннәр.

Тәһарәтле җайдак юлны
Бермә-бер артык узган.
Хатын-кызның да пакьлеген
Саклап торган шул комган.

Чисталыкка чыганак ул
Вә серле көчкә ия.
Бу шигырем мөселманның
Комганына мәдхия!

# Сискәнү

Сүтелеп төшкән ике толымым,
Хастаханә – яткан урыным.
Шакыдылар:
– Түрдән узыгыз,
Ак биләүдә, апа, кызыгыз.

– Тулып кына пешкән бу алмам.
Үземә бир, газиз бер Аллам,
Бөтен чирен,– диеп,– баламның, –
Өзелүен күрдем анамның.

– Чәчкәйләрең төсле биләвем,
Башкаемның бетми гүләве,
Аяк астындагы бәладән,
Хастаханә менә янәдән, –
Дип, әнкәмә хәлем сөйләдем,
Күз яшьләре белән түләдем.

– Син сыеңда әле, сыеңда,
Кайгы килде әмма быел да...
Ничә бала – борчу шулкадәр.
Җил сызгыра,
Чү, дип, ни хәбәр?
Сискәнәдер ана йөрәге,
Ваемсыздыр ай-һай сирәге...

# Сөендермәк булдым

Сөендермәк булдым тәрбияләп,
Сөендермәк булдым яратып.
Син үзең дә бик канәгать идең,
Яннарыма килдең җан атып.

Сөендермәк булдым җырлар язып,
Җырларымны сиңа багышлап.
Син үзең дә назга сусау идең,
Чөмереп эчтең җәйләп, кыш кышлап.

Сөендермәк булдым бүләк ясап,
Ак кульяулык чиктем – истәлек.
Син үзең дә кул эшенә оста,
Син үзең дә чумган хискә бик.

Сөендермәк булдым сыендырып,
Сыем биреп, төреп ләззәткә...
Шуны белдем:
Сөю-мәхәббәтне
Алып булмый икән әҗәткә...

# Кулларымны сузган гына идем...

Яктылыкка, таңга тартылгандай
Сиңа суздым ачык учымны.
Күзләреңдә кояш нуры күреп,
И күңелем үсте, очынды.

И дәртләнеп эшкә тотынганмын,
Эш дигәнем – язу, шигырьләр.
Давыллардан саклар, яклар, бәлки,
Кайгыларым артка чигерләр...
Дип уйладым.
Өметләндем мин дә
Хыялыма керде яктылык.
Яктылыклар ләкин ерак булган,
Караңгыга чумды яхшылык.

Кочакларын җәйгән иде хыял,
Ут ялмады сузган учымны.
Күзләремдә кояш нуры сүнде,
Күңелкәем сынды, ачынды.

# Үз максаты

Яңгыр булып явыйм микән,
Су булып агыйм микән?
Ярларыңа кагыйм микән,
Бер чоңгыл табыйм микән?

Утларда янган җанымны
Нишләтим, кая куйыйм?
Чаптардай чапкан хисләрем
Йөгәнлим ничек, тыйыйм?

Җаһил җаннар җәберләде,
Ялган белән сыйлады.
Кыйналганны кыйнады, тик
Күзе һаман туймады.

Күңел күзе мәхәббәтнең
Чынлап, дөм сукыр икән.
Шул күрә карау сукырлык
Күпләр башына җиткән.

Чумырып алдым да уйларым
Суларга илтеп салдым.
Шашыплар яраткан өчен,
Казалы булып калдым.

Тупырдап торган тәнемнең
Төкәнде егәр, яме...
Башларның да, ашларның да
Үз максаты, үз җәбе...

# *Шул җил...*

Анда китсәң – миңа ашкынасың,
Миңа килсәң – белмим каядыр?
Сине сагынып көтеп яшәүләрем
Тиккә генә, бәлки, заядыр?

Син китәсең.
Тагын хатлар ява,
Сибелеп-сибелеп очкан каурый күк.
Ышанмыйча һич булдыра алмыйм,
Мин дип сыза җаның, сыктый күк.

Бөтен уем хәзер синең хакта,
Синең юллар миңа юнәлгән.
Сихерче җил әллә гайбәт ташый,
Әйтә кебек: «Ул бит өйләнгән.

Якын ешындырма, кабул итмә,
Алгысытма канлы йөрәгең.
Кире китәр, сөеп-сөелер дә,
Алып бетерер дә кирәген».

...Әллә каян җанга салкын өрә,
Эссе ләса, үзе туңдыра.
Сөю тулы җаным җилкәнендә
Әче итеп шул җил сызгыра...

## Җете төсләр тиз уңа

Син тез чүктең алларыма, сүзең бер үк:
– Тәкъдимемне кире какма, какма берүк.

Җавапладым:
– Синең буе улым үсә...

Сүзләреңнең җетелеге юлны кисә...

## Үпкәләмим

Томалап алган буранга
Кердең, югалдың кинәт.
Буйладым бөтен дөньясын
Уйларым белән иңләп.

Адаштың дисәм,– ялгышам,
Син адашырлык түгел.
Очар кош булып калыкты
Сине югалткан күңел.

Үпкәләмим оныттың дип,
(Мин еларга килмәдем.)
Дөрләп китәрлек сөюне
Күрә генә белмәдең...

## *Котлау язам*

Мин һич чакырмадым сине,
Син үзең чабып килдең.
Юк, кирәкми, дигәндә дә
Кайнар кочакка кердең.

Көчләп сөйдермәдем сине,
Үзең: «Яратам! – дидең.–
Бәхетле итәм, елмайтам,
Кайгың таратам»,– дидең.

Буйсындым буй-сыннарыңа,
Буйсындым уйларыңа.
...Инде менә котлау язам
Никахсыз туйларыңа.

# Без биш бала

Сугыштан соң туган биш бала без,
Туплар тынгач туган биш бала.
Әйтәсең син, әткәй:
– Балаларга
Кабат килмәс сугыш, иншалла!..

Туплар тынгач туган биш бала без,
Тыныч көндә безгә җан иңгән.
Тыныч көндә үстек,
Тыныч төндә,
Тик кан белән кучкән сез күргән.

Сугыштан соң туган биш бала без,
(Афәт таныш безгә, һәрхәлдә.)
Әгәр кирәк булса, бер урынына
Биш вулкан без бүген – биш тәндә.
Кирәк булса, туган илкәй өчен,
Биш ташкын без, бишебез биш җирдән.
Күрмәсәк тә күзләребез белән,
Аңга, җанга кучкән сез күргән.

Сугыштан соң туган биш бала без,
Туплар тынгач туган биш бала.
Һәрчак әзер торган биш ядрә без,
Чакыра калса, әгәр Җир-ана!

# Ялкын иттек

Без бер ата балалары,
Бер карында ятканбыз.
Таңнар туган.
Газиз илдә
Чишмә булып акканбыз.

Насыйп наз булып тигәнбез
Иреннәргә, йөзләргә.
Шифа булып түгелгәнбез
Коңгырт, зәңгәр күзләргә.

Без бер ата балалары,
Төскә-биткә охшашлар.
Төрлебез төрле төбәктә –
Җаннарыбыз тоташкан.

Сөйгән, сөелгән ярлар без
Һәм бала аналары.
Һай, тырышып буядылар,
Әмма җан каралмады.

Баш бирмәдек гайбәтләргә,
Без – ата балалары.
Эшкә җиктек, ялкын иттек
Хәтта сүз яраларын!

## *Мәңгегә килмәгән кеше*

Тоташ гөнаһ түгел ләса
Кылган, эшләгәннәрем.
Языкларым языла бара,
Яза фәрештәләрем.

Сөю далалары – дәрья,
Сөю дулкыны – кыя.
Чиксез зур бу биләмәгә
Бары изгелек сыя.

Хушлану алам әйбәттән,
Хушлану алам актан.
Сүзләрең белән иркәлә,
Сөюем белән пакьлән.

Мәңгегә килмәгән син дә,
Дөньяга сыймый йөрмә.
Елаганчы көлсәң дә бит –
Йөзне каралта сөрмә...

## Дөньясы бозга әйләнсә...

Сандугач булып кунган ир
Чукыды козгын булып.
Мәхәббәт көткән йөрәгем
Ярылды канга тузып.

Төс ташлаган яшьлегемне
Дуслар бик тиз күрделәр.
Хан кызы кебек идең, дип,
Каһкаһәләп көлделәр.

Минме сүнгән, минме сулган –
Йөгәнләдем атымны.
Алачакмын өлешемә
Язылган үз хакымны.

Дөньясы бозга әйләнсә,
Эретер өчен тудым.
Ирексезләп кереп тулган
Яман уйларны кудым.

## Сары коелган

Әле җәйнең башы гына –
Сары коелган талга.
Сөйгән яры су буйлатып
Агып киткәнме салда?

Нинди сагыш, кайгы дисәм,
Күкрәп үскән шул талда, –
Сабышмассың сарыларга,
Җәйләрдә ялгыз кал да...

## Аңладым

Үзем көләм,
Күңел елый,
Үксеп, үчегеп елый.
Үзем сабыр,
Үзем түзем,
Җанымда давыл дулый.

Яратырга туган идем,
Яраттырып яшәргә.
Сукмагымны үзем салдым,
Ут кабыздым яшьнәргә.

Бәхеттәнме баш әйләнде,
Хисләрдәнме исердем?!
Синең белән иркәләндем,
Татлы ләззәт кичердем.

Тормыш серле,
Яшьлегеңдә
Уңга, сулга дәшәләр.
Ялгышларыңнан кинәнеп,
Мәкерле сүз чәчәләр.

Үзем көләм, күңел елый,
Үксеп, үчегеп елый.
Үзем сабыр, үзем түзем,
Җанымда давыл дулый.

Өзелде җанның бер кылы,
Сынды җирнең күчәре.
Ризыкның тәме китте,
Тозсыз тәгам-эчәрем...

Аңладым югалтуларның
Бер-бер артлы килгәнен.
Хыялның, якты өметнең
Әкренләп сүнгәнен.

## Нишләп әле?

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм? –
Томрап торган ике кызым бар.
Туганнарым килә,
Өстәлемдә
Чәй-шикәрем, ипи-тозым бар.

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм? –
Әткәм-әнкәм исән чагында.
Дөньяның бер кадерлесе ич мин
Кайткан чакта туган ягымда.

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм? –
Моңлана һәм уйлый белгәндә.
Өлешемә тигән хезмәтемдә
Йөгерә-йөгерә эшләп йөргәндә.

## Умырзая

– Син ландыштай хуш исле дә түгел,
Миләүшәләр кебек гүзәл дә.
Умырзая, нигә җырланасың?
Тибрәнәсең нигә телләрдә?

– Хуш исле һәм чибәр булмасам да,
Гомерем минем узмый заяга:
Боз өстендә чәчәк атам бит мин, –
Яз калдырып китәм дөньяга.

## *Кышка соклану...*

Мамык кебек карга басып
Атлыйм ап-ак дөньядан.
Күпереп тула баскан эзем,
Күпереп тула яңадан.

Барам да барам.
Аклыктан
Сихерләнгәнмен бугай.
Ул гүзәлдер бу агачлар,
Ул гүзәлдер бу тугай.

Тирә-юньгә соклanудан
Шашып китмәсәм кана...
Хисләремнең ялкыныннан
Битләрем дөрләп яна.

Салкын аклык күңелләрне
Шулай алдый алганын
Аңладым да, салмакладым
Үтәр юлның калганын...

## Йөрәгемдә сакладым да...

Йөрәгемә төреп кенә
Саклаган сөю иде.
Кадерсезгә калмасын, дип
Кайгырту, көю иде.

Арткан саен акылларым,
Кимеде кыюлыгым.
Көрмәкләнгән телем гүя
Хисләрем тыюлыгы.

Тыя, тыела торгачтын,
Сөйгәнемне югалттым.
Йөрәгем белән бикләдем,
Күзем белән урлаттым.

## Таякның ике башы

Чәчләреңә чәчәк булып кундым,
Җиләс җилләр барыр юлыңда.
Бер әйтүең җитте:
Ир кадере,
Мәгънәле тормыш турында.

Иртә таңда яңгыр булып яудым,
Тузаннарын җирнең алыйм дип.
Таләбеңне һичбер киметмәдең,
Мин тырыштым сиңа ярыйм дип.

Ярар өчен мең сурәткә кердем:
Сайрап кундым таңда – таңыңа,
Моңнар булып йөрәгеңә сеңдем,
Сихәт булып актым каныңда.

Үз дигәнең иттең.
Үҗәтләнеп,
Дөньябызны алга этәрдем.
Кадерләдем сине.
Шул ук кадер
Үземне дә данга күтәрде.

## *Белә торып*

Кара болыт, кара болыт,
Күк гөмбәзен томала.
Коргаксыган җиребезгә
Яңгыр яудыр, юмала.

Кара болыт кирәк чакта
Килә калса кунакка,
Бәхет кенә.
Кайнар җил, син
Кума аны еракка.

...Кайчак күңел болытларын
Шулай көтеп аласың.
Белә торып, утлы яше
Йөрәгеңә тамасын.

Кайгыларның кара була,
Канлы була җирлеге.
Шул кайгының барсын йола
Шатлыкның бер мизгеле.

## *Мичче хәйләсе*

– Уңмадым ла,– дип зарлана әби,–
Өр-яңа мич – төтен кайтара.
Көлеп куя күрше ахирәте:
– «Акбаш»[1] шундый эшләр майтара.

– Нинди «акбаш»?
Гомер бакый аны
Кертмәдем мин динле өемә.
– Соң, кертмәсәң,
Мичең белән, күрше,
Интегерсең шушы көенә.

Аларның бит закон үзе белән,
Тоттырмасаң «акбаш» кулына,
Күп сөйләшеп тормый,
Бер кирпечне
Куя китә төтен юлына...

[1] *Акбаш* – аракы.

## *Сынау вакыты*

Балам унны тәмамлады,
Җитте сынау вакыты.
Кайсы да булса бер вузга
Илтеп «сылау» вакыты.

И мин чабам, ирем чаба,
Чаба әби-бабасы.
Ду купты бар таныш-белеш,
Эзлиләр мең чарасын...

Имтихан вакыты, имеш,
Әгәр уйлап карасаң –
Дус-ишләрнең кем икәнен
Сынау чагы лабаса!

## *Чегәннәрнең чаялыгы*

Кемдә юк соң югалтулар,
Кемдә юк соң табышлар?
Уч төбендәге сызыклар –
Үземә дә танышлар.

Чаялансаң, наянлансаң,
Кемне дә алдап була.
Текәп карасаң күзләргә,
Кемне дә аңлап була.

Яшьлек назың янган, имеш,
Җылы тоймас кочакта –
Киләчәгеңне әйтәм, ди,
Әйтәлмиләр пычак та.

Тик чегәннәр чаялыгы
Уйландыра кайчакта...

## *Абынабыз, сөртенәбез*

Берәүләргә фәкать сынау бирә язмыш:
Йөгерәләр, йөгенәләр – һаман ялгыш...
Заман чире –
Ир дигәнең көн дә салмыш,
Ничек кенә каһәрләми усал язмыш.

Мәхәббәт дип, җир читеннән килеп табыш,
Нәселләрне белешмичә күреш, кавыш,
Яратам, дип, чабуына барып ябыш –
Күзләреңнән гомергә дә китмәс сагыш.

Исерек ата, исерек бала – чүкеш, кагыш:
Китә хурлау,
Китә сүгү, яла ягыш.
Абынабыз, сөртенәбез – кая бармыш?
Сөю тәмен тоя алмас ошбу байгыш...

## *Сиңа әйтмим...*

Күпне күрдең,
Синең өчен
Бу тәнкыйтьмени, диләр.
Үзем һәм башкалар өчен,
«Җайлап» кына тиргиләр.

Сиңа әйтмим, дия-дия,
Әйтәләр, кызарталар.
Ник үзеңә аласың? – дип,
Ахырдан юаталар.

## Әләк-чәләк йөртүчегә

Имзасыз әләк яза да
Дустың булып серләшә.
Кунакка чакыра хәтта
Теләк тели: мең яшә!

Әле йомыш кушкан була,
Сырхау булып сөйләшә:
Ялгыз хатын, ди ул: явыз –
Ирле белән теләшә!..

Тотып ашар иде дә бу
Ялгызларны, толларны.
Ярый әле «светофор»
Ябып тора юлларны...

Исемсез хат язучының
Холкын өйрәндем әле.
Ишек ачылып киттеме,
Сискәнеп куйган мәле.

...Тырнак төбеннән кер җыеп,
Дер калтырап торганчы.
Тыныч кына яшә идең,
Йокла идең туйганчы...

## Һәркемнең үз юлы

И елмайды, күлдә кояш
Болытның ертыгыннан.
Яңасы, күкне томалап,
Чыкты күл култыгыннан.

Болытның да үз холкы бар,
Тотты «типте» тәртәгә.
Күзен ачалмады кояш
Көн буе бер мәртәбә...

## Син елама

Эчәр суы, җыяр ризыгы
Йөртә, диләр, адәм баласын.
Кайчан да бер уйладыммы икән
Кавказ суын учка аласым?

Теш сынарлык салкын суы һәм дә
Кыя ташы уйга салганда –
Җырладым бер моңлы татар көе,
Тау кызлары буйга калганда.

Таш бәгырьле таулар телгә килде,
Кем уйлаган, таш та елар дип.
«Ирләр яше» ага кыялардан,
Шул мизгелләр җанны кыя ник?

Уем белән очтым дәрьяларга,
Тау-ташларга барып бәрелдем.
...Күз яшьләрең булып үзем агам,
Син елама берүк, кадерлем...

## Ә йөрәкнең үз эше...

«Кызыл кояш», «Кызыл таш»лар,
«Кызыл гөл»[1] арасында.
Дәваланып йөрим, имеш,
Әчесу[2] каласында.

Дәваланып йөрим менә
«Иярле тау»га[3] менеп.
Җир читеннән килгәннәр бар,
Килгәннәр акча түгеп.

Һәркем сау-таза булмакчы
Бер ай үтәр-үтмәстә.
...Ә йөрәкнең үз эше эш –
Тота да ала, көтмәстән...

## Борылып та карамам

Башка мәңге килмәс булып
Кайтам бу диңгезләрдән.
Кыш җылырак иде бугай
Быелгы җәй-көзләрдән.

Чыгып йөгерергә җиттем
Туган-үскән чакларга.
Борылып та бер карамам
Син булмаганякларга.

---

[1] Кисловодск шәһәренең ял бакчасындагы тукталышлар.
[2] Кисловодск шәһәре.
[3] Тау исеме.

## Гаҗизлек киңәше

Балам ятим булмасын, дип,
Кияүгә чыккан хатын,
Буразнага кертә алмас,
Ирен – баш бирмәс атын.

Гомер буе бәргәләнеп
Ике ут арасында,
Бер җылы караш тоялмый
Ни ир, ни баласында.

Үтәр гомеркәе, үтәр
Язмышына үртәлеп.
Тол калсаң, бала ияртеп
Иргә чыкма, үскәнем!..

## Гайбәт сөйли

Ир-егетләр гайбәт сөйли,
Сагызларын чәйнәп сөйли,
Күңеле пакь – әйбәт сөйли,
Әйбәтләрне гайбәт сөйми.

Тәмәкесе көйри-көйри
Авызларын сасытканчы
Ир-егетләр гайбәт сөйли,
Күңеленә гөнаһ төйни.

Теле телгә йокмый сөйли,
Колакларда гайбәт гули,
Яулык бәйлисе һич килми,
Ә үзләре гайбәт сөйли.

## Балыкчы шатлыгы

Селәүчәнле кармагыма
Балык чиртә дә чиртә.
Хәерле булып тудыңмы,
Кояшлы җәйге иртә?

Балыкчыга хәерледер,
Бәлки, бу көн, бу иртә.
Ә минә җәен балыгын
Кыздырган таба көтә...

## Берәүдән бары сөел

Сөясең дә кебек үзе,
Сөенәсең дә сымак.
Кайчакта ярсып чыгасың,
Кайчакта артык тыйнак.

Әле минем кочагымда,
Әле әллә кайларда.
Урталыкта тотынасың
Ике якны җайларга.

Кыен микән үзеңә дә?
Миңа күңелле түгел.
Дөрлә син назлы кочакта,
Берәүдән бары сөел.

Бердән берәгәйле сөел,
Ни җиттеләрдән түгел.
Шул минутны искә алып,
Тулып ташысын күңел.

## Сәбәп

Бүрек кадәр генә иде,
Ялмады алды кинәт.
Үтәр-үтмәс бер сәгатьтә
Янды да бетте дөрләп.

Кузгатты бөтен авылны,
Шау итте тагын халык.
Һәркем авызында шул сүз:
Миркәйләр бетте янып.

Дөм исерек булган, үзе
Ничек янып үлмәгән?
Авызыннан тәмәкесе
Төшкәнен дә сизмәгән.

Балалары өелешеп
Урамда калды әнә.
Эчәргә тагын бер сәбәп –
Миркәй ләх булган янә...

## Ир булса, шундый булсын

Тәрәзәмнән җил өрә,
Ишегемнән кар керә.
Балаларым йөткерә,
Ирем көя үтерә.

Мич башына ут каба,
Кыегымнан су тама.
Ир барсына «ут йота»,
Түшәмнән чебен тота...

## Югалды шатлыклар

Гомерләр буена
Утлы куз – учымда.
Әйтмәгән сүзләрем
Йөри тел очымда.

Могҗиза ясар дип,
Бу бөек табигать.
Ярдәмчем булыр ла
Хак динем – шәригать,

Дип, өмет көттерде...
Күңел бит сабый күк.
...Шартлады шатлыклар,
Югалды күбек күк.

## Ә ул...

Һәрбер ялтыраган алтын түгел икән,
Һәр сайраган – түгел сандугач.
Кайчагында ышанасың шулай
Тәмле сүзкәйләргә зар булгач.

Мин дә ышандым.
Таптым, таптым, дидем,
Мәхәббәттә тугры егетне.
Ул нишләде?
Кочагымнан торып,
Сылап куйды йөзгә дегетне...

# *Коры закон*

Закон – коры.
Күп сөйләшеп булмый,
Кибеттә, ни кибет артында...
Дус-ишләрне, их, сыйлыйсы килә,
Чәкүшкәм дә, юк бер яртым да.

Әле чәчү,
Әле урак өсте,
Закон коры, ахир, сатмыйлар...
Булыр иде коньяк ишеләре,
Шаккатарсың хәзер, кайтмыйлар.

Сирәк-мирәк була одеколон,
Чит илнеке, кызыл путалы.
Бәясеннән торып булмый инде,
Күпләп алыйм барда, тукта әле.

Алып кайттым,
Шешәдәшне дәштем:
– Одеколон,– ди бу,– агулы...
Кире киттем,
Әмма сатучы кыз
Уйламый да кире алуны.

– Соң, нишләтим бу кадәрне? – мәйтәм, –
Кыйбатлы бит үзе, җитмәсә?
– Нишләтергә алдыгыз соң? – ди кыз,
Исе китмәс икән, китмәсә.

Ярый инде бәйрәм-сәйрәмнәрдә
Бүләк итеп бирдем дусларга.
Дөнья шулай өйрәтте дә куйды
Законлы итеп дусны котларга...

# Күңел күзе

Әй, син, дөнья, серле дөнья,
Мең төскә бизәлгәнсең.
Бозың эреп,
Суың сеңеп,
Яшәргән... төзәлгәнсең.

Таңнарың җылы, сихәтле,
Кичләрең назлы, дымык.
Без генә моңлы-сагышлы,
Толларның – күңел сынык.

Җилләрнең дә үз җыры бар,
Үз моңы бар буранның.
Җирнең серен тоя белсен
Күңел күзе угланның.

Барыр юлы бүленмәсен
Сәфәр чыккан берәүнең.
Язмасын корбаны булу –
Үзе сынык терәүнең...

Ясин чыгып, елап озаттылар,
Хушлаштылар соңгы мәртәбә.
Мордар китте тагын бер мәхлугы,
Тагын берәү типте тәртәгә.

Һәм җәсәден туфрак белән күмеп,
Кырык адым киткәч тере җан,
Гөрзи тотып, Нәнкир үзе килде:
– Син ник бауга мендең, Галимҗан?
Аяксыздан-күтсез биш баланны
Калдырдыңмы Ходай иркенә?
Койма җепсәләрең череп беткән,
Кәҗә кереп йөри милкеңә.

Урын өстендәге карт әнкәңә
Шундый бүләк, димәк, эшләдең?!
Терсәгеңне тешләр идең хәзер,
Җансыз инде терсәк-тешләрең.

Әниеңне әйтәм, тыныч кына
Үлем көтте, улым җирләр, дип.
Күрше-күлән мактап сөйли иде:
Җәмәгате бигрәк чибәр, дип.

Төкердең син алар намусына,
Тап төшердең нәсел-нәсәпкә.
Хәзер әнә бер кадерсез алар –
Санга керә, юктыр исәпкә...

Имгәнделәр бала-чагаларың,
Ямьсез сүзләр белән тукмалып.
Җаен таба шакал, мәсхәрәли,
Нахак гаеп тага, «шукланып».

Әзмәвердәй таза, көчле килеш
Ясадың син нинди тамаша?
Кемдер берәү исәнлеккә туймый,
Яшим, диеп әмма тырмаша.

Их син, егет,
Кире кайта алсаң,
Кадерен белер идең тормышның.
Иманыңны сындыралмас иде
Хәмер дигән явыз ул мыштым.

Әмма юк шул,
Кабер илләреннән
Кире кайта торган юллар юк!..
...Җир астында үзгә тормыш, имеш:
Гөрзи тавышлары тук та тук...

## *Андыйга да Ходай гомер биргән*

Үлемнән оят көчле дә,
Әмма бәндәләр үчле.
Үч алырга яратучы
Буладыр кара эчле.

Кара эчле кара эшкә
Этәрә, өнди даим.
...Андыйны да кирәксенгән,
Гомер биргән Ходаем.

# *Сәер сөю*

Үзең әйттең: күңелемне
Юаттың, дип.
Онытылган җырларымны
Кузгаттың, дип.

Үзең әйттең: кырыс идем
Йомшаттың, дип.
Сиңа килеп бар кайгымны
Бушаттым, дип.

Үзең әйттең: һәлакәттән
Коткардың, дип.
Үлгәнче дә онытылмаслык
Эз салдың, дип.

Кат-кат әйттең: үлепләр дә
Яратам, дип.
Яратам да үзкәемә
Каратам, дип.

Әйттең дә бит: бергенәм, дип,
Асылым, дип.
Хәзер менә бау сузасың
Асылын, дип...

## *Чынга ошатып сөйлисең*

Сине генә сөям, дисең,
Мине генә сөй әйдә.
Үлепләр дә юксынамын,
Көям, дисең,
Көй әйдә.

Сәрмәп, капшап карыйм, дисең,
Ярты төндә уянып.
Сүзләрең чынын чындыр да,
Ә мин куям уйланып:

Сөю серен аңлатканда
Шәп белгеч син, оратор.
...Кирәксә, куып җитәрмен,
Бар җаныем, бара тор...

## *Ирнең җиллесе*

Аерылганга күп түгел дә,
Ерак аралар.
Ераклашкан күңелләрдә
Сыза яралар.

Сагынуларга олы дәва
Кавышу җыры.
Мәхәббәтле күккә чөйде
Йолдыз яңгыры.

Каш астыннан зур күзләрең
Тутырып карый.
Бер карасам, аңлый алар,
Соңыннан алдый.

Әллә инде бу бәхетне
Күп булыр диде?
Чатнады сөю дигән хис,
Әллә күз тиде?

Чатнады. Үтәли кереп
Ыжгырды буран:
«Син дип яшим,– дия үзе,–
Син дип котырам.

Сугып егып суырып үбә
Ирнең җиллесе...»
...Бураннарда буран холкы –
Өермәлесе.

## Сөю гөлләмәндә агу

Мысыр күгәрчене кебек
Гөрлисең дә гөрлисең.
Әллә дөрес, әллә ялган –
Үткәнеңне сөйлисең.

Серләрең бик серле, дускай,
Сине гел алдаганнар.
Миңгә бирәү булыр микән
Җаныңны аңлаганнар.

Ышанычлы дигәннәр дә
Таптап үткәннәр икән.
Мәртәбәле мәхәббәтең
Тегеп-сүткәннәр икән.

«Йөрәккәем» диеп, хәзер
Кемнәргә күчкәнсеңдер.
Сөю гөлләмәндә агу –
Ничекләр эчәсеңдер?

# Яңгыр шакый

Тәрәзәмә яңгыр шакый,
Яңгыр кемнәрнең җаны?
Табигатьтә бар да тере,
Нур чәчеп ата таңы.

Тәрәзәмә яңгыр шакый,
Яңгыр ява гөлемә.
Җаныңның нинди хәбәре
Коела күңел күлемә.

Тәрәзәмә яңгыр шакый,
Димәк, көч-дәрманы бар.
Өй әйләнәсендә йөри
Мине юксынучы яр.

Тәрәзәмә яңгыр шакый,
Шакылдата, пышылдый.
Серле-серле авазларны
Күңел сөюгә сылтый.

Тәрәзәмә яңгыр шакый,
Шакый да туктап кала.
Мәхәббәтләр татлы да соң –
Югалып шөбһә сала.

## *Бер хатын фәлсәфәсе*

Кайгың бармы бу дөньяда?
Минем юк.
Нигә, димсең?
Чөнки минем ирем юк.

Шат яшимсең бу дөньяда?
Ә мин юк.
Нигә, димсең?
Чөнки минем ирем юк.

## *Бер ир фәлсәфәсе*

Янымда юлың бар синең,
Җанымда җылың яши.
Ул сөйдең, ул иркәләдең,
Һәм сөйдердең бит тәки.

Газиз җанны кыл урталай
Бүлмәк хәлгә китердең.
Йоклыйм хатын кочагында,
Төшкә тагын син кердең...

# *Аш төрләндерү*

Төн пәрдәсен ачкан ишекнең
Хәсрәтләре кемнәр башына?
Бераз салмыш, бераз ачулы
Мәхәббәте тора каршында.

– Син уйлама, карчык, кара ыштыр
Япкандыр, дип, бу ир битенә.
Рәхәттән йөрмим ләбаса
Кара төндә, абына-сөртенә.

Ышан, карчык, күңел түрендә,
Кояш әгәр, бары син генә!
Ресторанда якын дус белән
Аш төрләндергәник әз генә...

## *Никтер*

Көлсәң – көл, еласаң – ела
Бу ирләр кыланмышы.
Исе китми, асты өскә
Әйләнсә дә тормышы.

Авыз суларын агызып
Елмайган, көлгән була.
Яше алтмышка җитсә дә,
Кызлар, дип йөргән була.

Командировкага китсә,
Алар буйдак, һичсүзсез.
Елмайганда оялмый да
Теле күренә, юньсез.
(Теле күренмәс иде дә
Аңкаулары гел тешсез.)

Май урлаган мәче кебек
Ялтырыйлар күзләре.
Син асыл да гүзәл, имеш,
Балдан татлы сүзләре...

Бу егетләр солтаныдыр –
Андый «солтан»нар сирәк.
Тик мәхәббәт илләрендә
Тугры җаннар кирәк.

## *Акылдан кибән куйсак та...*

Сабыйлыктан, гадилектән
Кибән куйган балачак.
Аяз күктән, якты күктән
Көмеш ләйсән яуган чак.

Туган йортсыз яшәүләрне
Уйлый да алмаган чак.
Күктә түгел, күңелләрдә
Аҗаган уйнаган чак.

Үтә күренмәле күңел –
Тамчы кер тормаган чак.
Сөю турындагы җырны.
Йөрәкләр җырлаган чак.

Белмәгәнбез кадереңне,
Кичерсәнә, балачак!
Акылдан кибән куйсак та,
Сафлык синдә калачак!

## *Оныттыкмы?*

Сагынып кына сөйлибез
Ефәктәй балачакны.
Оныттыкмы чишмә булып
Челтерәп аккан чакны.

Пакь хисләрнең яңгыр булып
Һавадан сибелгәнен.
Ул хисләрнең гөлләргә һәм...
Тик безгә бирелгәнен.

Җылы йомшак җилләр булып
Кочакка сарылганны...
Олыгайдык, оныттыкмы –
Үзебез табынганны?

Әллә артык сабырландык,
Тыйнакланып киттекме?
Әллә инде балачакның
Ялгыш күңелен киттекме?

# *Суга барам*

Иртүк торып суга барам,
Чайкала чиләкләрем.
Комлы юлда шыгырт-шыгырт
Сөйләшә чүәкләрем.

Әнкәемә су кайтарам,
Чишмә сулары – чәйгә.
Тәпи йөреп китәр инде
Нәни кызым да җәйгә.

Кызым үсеп буйга җитәр,
Чишмә юлыннан китәр.
Тәүфыйгы артсын иде лә
Буе-сыныннан битәр.

Уйга чумып суга барам,
Чайкала чиләкләрем.
Кабул булсын су алганда
Теләгән теләкләрем.

## *Аяк астындагы болыт*

Баш очыннан җилләр акты,
Кичләрдә таңым атты...
Күк гөмбәзен төргән болыт
Ак юрган булып ятты.

Ак юрган булып ятты да
Кыш булып җирне төрде.
Җәйләрдә чуп-чуар дөнья
Актан ак төскә керде.

Ак юрган булып ятты ул,
Кара болыт иде бит...
...Аяк asларымда калдың –
Бәхетемне күреп кит.

## *Чама белми сөйгәннәрнең*

Төн буена аңа хатлар яздың,
Язып бетермичә ятмадың.
Ә җаваплар шундый матур иде,
Һәрбер сүзен хәтта ятладың.

Хыялландың, төшләремдә һаман
Күрәм, диеп, көлеп торганын.
Тик белмәдең ялган сөюләрнең
Үзәк өзгеч әче булганын.

Җете кызыл бик тиз уңа, диләр,
Чама була һәрбер нәрсәдә.
Чама белми сөйгәннәрнең шулай,
«Чәчәге» икән – корган кәүсәдә.

## *Көлүнең төрлесе була*

Көлүләрнең, һай, төрлесе була:
Көләрмен бер
Шаян караш белән –
Сизмәссең.
Сихри елмаюым артындагы
Үҗәтлекне хәтта күрмәссең.
Ә кайчакта булыр шундый минут,
Ирексездән үзең көләрсең.
Якын дустың тоеп, онытылып,
Барлык серләреңне сөйләрсең.
Мин көлүнең төрле юлын беләм –
Елмаермын
Эчке сафлык белән,
Күзләреңә тутырып карармын.
Син дә елмай,
Көлгән күзләреңнең
Ниндилеген барыбер аңлармын.

# Күзем каты микән әллә?

Күзем каты микән әллә,
Тагын авырый балам.
Ул сырхаган саен, үзем
Янып, көлләргә калам.

Күзем каты микән әллә,
Шиңде, сулды гөлләрем.
Әле генә шау чәчәккә
Чумган иде үзләре.

Күзем каты микән әллә,
Ватылды бәллүр касәм.
Төшеп калган алтын тәңкәм –
Тишек булган ич кесәм...

Күзем каты микән әллә,
Шикләнә күңелләрем.
Яңгыр сулары сибүгә,
Терелделәр гөлләрем.

Күзем каты микән әллә,
Тагын авырый балам,
Дип, үземне битәрләдем,
Ә ул... авырга калган.

## Гаделлек юлында йөреп...

Кизәнүең булдымы бу,
Шаяруың идеме?
Син юл күрсәттеңме аңа,
Мәкер үзе белдеме?

Эзләп тапты.
Кара канга
Батырды йөрәгемне.
Гаделлек юлында йөреп,
Алдым «үз кирәгемне!..»

## Насыйп булсын

Насыйп булсын очрашулар тагын безгә –
Уздык күңел түрегезгә.
Күңелегезнең түре иркен, якты икән,
Чын яз икән күңелегездә.

Насыйп булсын ул язларны бергә күрү,
Бәйрәмнәрдә бергә йөрү.
Сөенечтән бергәләшеп уйнау-көлү,
Күңелләрне җырга төрү.

Насыйп булсын нигъмәт тулы табыннарда
Тагын шулай җыйналырга.
Яхшылыктан, якынлыктан, җырдан-моңнан
Җирдә мәңге сыйланырга.

# Чын йөрәктән

Юлларымда сулган чәчәк күреп,
Кайгы-хәсрәтләргә төшсәм дә;
Йөрәккәем ярсып кайнаганда,
Кар суларын ятып эчсәм дә;
Ак күлмәкле каен кызларыңны
Сердәшләрем итеп кочсам да;
Тургай моңнарыннан сихерләнеп,
Болытларга кадәр очсам да;
Китеп барсам да, син, туган авыл,
Чит итмәдең, һаман яраттың.
Үстердең дә шулай назлап, сөеп,
Хәерле юл теләп озаттың.
Аерылдык без...
Ләкин сагышланмыйм,
Чын йөрәктән сөйлим мин менә:
Сиңа булган кайнар мәхәббәтем
Ак канатлар куйды иңемә.
Сиңа булган мәхәббәтем әйди,
Алга барам, алга, туктамыйм.
Кыя-таулар, дәрья-сулар кичәм,
Янмый чыгам, керсәм, уттан мин.

# *Ник чыкмыйсың?*

Сызыла да гармун сызыла,
Айдан суга ак юл сузыла.
Җансыз көймәләрнең берсенә
Дулкын бәрә,
Дулкын бәрә,
Дулкын бәрә, ишкәк көрсенә.

Кайда икән аның хуҗасы,
Баскан мәллә дөнья нужасы?
Нигә җырлый егет,
Нигә җырлый,
Нигә җырлый өзелеп бу көйгә?

«Көймәләрдә парлап йөрергә
Ник чыкмыйсың хәзер син бер дә?
Моңаям мин менә бүген дә.
Кара болыт,
Авыр кара болыт,
Кара болыт күңел күгемдә...»

Ай күмелә болытларына,
Күкне телеп, яшен кабына.
Суга кызгылт сукмак сузыла.
Йөрәк-бәгырьләрне сыкрандырып,
Үзәкләрне өзеп,
Өзеп-өзеп
Сызыла да гармун сызыла...

# Шулай юанам

Мәрхәмәтсез чагың, дөнья,
Алҗыта, хәлне ала.
Туганнарым арасында
Булдым кайгылы бала.

Өзми-куймый, ычкындырмый,
Тотып алып якамнан.
Мәсхәрәләттең иремнән –
Тәм таптырып хатамнан.

Кышлар язга көч биргәндәй,
Ял бирсәнә беразга.
Кайгыларда кайнаткачтын
Ник эретмисең назда?

Ходайның сөйгән бәндәсе
Газапка, ди, тарыга.
Гөнаһым бетеп кермәмме
Изгеләр китабына?..

Әнә шулай юанам мин,
Ирем кагып-сукканда.
Газапларга дучар булып,
Дөрләгән ут йотканда.

## Тукта, җыруым

Әллә инде хыялланып барам,
Син чыкмыйсың көн-төн уемнан.
Кичектерми дәва табу кирәк,
Узды, ахры, бу эш уеннан.

Исәр атым чыгып, таралганчы,
Каралганчы нәсел-ыруым,
Эчке дөньям серен фаш итүдән
Тукта, зинһар, тукта, җыруым!

## Җирне ямьләндерик

Сиңа да җитә бу дөнья,
Миңа да җитә, иркен.
Ямьсез сүзләр белән кайчак
Югалтмыйбызмы күркен?

Синнән дә үтә бу дөнья,
Миннән дә үтә, кала.
Кып-кыска гына гомердә –
Тәмсез сүз, нахак яла.

Синсез дә яшәр бу дөнья,
Минсез дә яшәр, шөкер.
...Җир ямьләп агач утыртыйк,
Әйтсеннәр безгә зекер!*

---

* *Зекер* – утырткан агачыңның һәр яфрагы дога укып, җәннәткә керүеңне теләп торыр, ди.

## Сабыр төбе

Сабыр төбе – сары алтын,
Сабыр төбе – салкын боз –
Сулык-сулык килеп елый
Сабыр итеп йөргән кыз.

Сабыр итте алтын көздән
Салкын кышларга кадәр,
Белəлмәде бер җылы сүз,
Алалмады бер хәбәр.

Сабыр бит ул, түзәр әле,
Дип санга сукмадымы?
Артык сабыр, дип, гаепне
Үзенә сылтадымы?

Сабыр төбе – сары алтын,
Сандыгы тула инде.
Шул «алтын»ны көтә-көтә,
Җаны боз була инде.

## *Дәва җыям*

Аланда балан өлгергән,
Баланның дәвасы бар.
Кайтам баланлы аланга,
Күңелнең ярасы бар.

Күңелемнең ярасы бар,
Их, дәваласы иде.
Дөрләп янасы иде дә,
Исән каласы иде.

Һаман әрнетә күңелне,
Шул яра бирми тынгы.
Киләләр ятлар яныма
Тартып карарга кылны.

Чиртәләр күңел кылларын,
Төрлечә, төрле яктан.
...Күңелемә дәва эзлим
Туган җир, туган яктан.

Туган җирдә, туган илдә
Үскән әче баланнан.
Тәлгәш-тәлгәш балан җыям
Шул баланлы аланнан,
Шул баланлы аланнан.

## *Хыялымда кайтып килдем*

Озын-озак көн булды бу –
Иртәдән төнгә кадәр.
Хыялымда кайтып килдем
Иделдән Сөнгә кадәр.

Сөн буйларына кайттым да
Утырып уйлар уйладым.
Үзәкне өзгән моңымны
Җырга салдым, җырладым.

Кушылды куш каеннарым
Сагышлы хисләремә.
Күзләремә яшь тәелде,
Төштең дә исләремә...

Озын-озак көн булды бу –
Иртәдән төнгә кадәр.
Хыялда җәяүләп кайттым
Иделдән Сөнгә кадәр.

# *Ник күңелсез икән син болай?*

Көл генә син, тик бер көл генә,
Зәңгәр күлдә дулкын аллансын.
Зәңгәр күлдәй зәңгәр күзләрең
Зәңгәр очкын чәчсен, җанлансын.
Зәңгәр күлдә, зәңгәр төннәрдә
Өзелеп калган җырым ялгансын.

Көл генә син, тик бер көл генә,
Уйларымда зәңгәр төн генә.
Ачык зәңгәр ефәк күлмәгең
Шул төннән соң бүтән күрмәдем.
Дулкын-дулкын кара чәчемне
Зәңгәр тасма белән үрмәдем.

Зәңгәр күлдә елый бер камыш,
Әйтче, нигә килде бу сагыш?..
(Аерым көннәр артта калган ич,
Менә күптән зарыгып көткән кич...)
Алдыбызда зәңгәр төн генә,
Кил инде, көл, иркәм, бер генә.
...Алдыбызда зәңгәр төн генә...

## *Моңлы бала түгел идем*

«Моңлы бала түгел идем,
Моңнар төште башыма».
Кара кайгы сөрмә тартты
Күзләремә, кашыма,
Күзләремә, кашыма.

Туган җиргә сыгылып төшеп,
Бер ятып елаганда,
Күңелләрдә әрнү хисе
Сызлаган, уйнаганда,

Ничекләр моңланмыйсың да
Ятыплар еламыйсың?
Кайтып нәни кызың белән
Курчаклы уйнамыйсың?

Сабыемның саф күңеле
Күчсен диеп җаныма,
Җиркәемнән яшәү дәрте
Сеңсен диеп каныма,

Алар иркенә ташладым
Моңнар баскан башымны.
Сабыем җаны нурлады
Күзләремне, кашымны,
Күзләремне, кашымны!

## Таңнар атканда

Канатларым талган иде инде,
Сине эзләп җаным арган иде.
Гомер үтте диеп уйлаганда,
Таңга кадәр чырам янган иде.

Таңга кадәр чырам янган иде,
Мин сүрелеп, сулып калган идем.
Бимазалап йөргән уйларымны
Күңелемнән куып арган идем.

Гөлт итте дә чырам янып китте,
Күзләремә очкын-ут капты.
Җан үтәли кереп синең рухың,
Баш имә, дип, кинәт сүз катты.

## Күпме дулкын дәште

Хисләремне түкми-чәчми йөрдем,
Мөлдерәмә килеш сакладым.
Илаһи зат,
Мин табындым сиңа,
Күпме дулкын дәште – акмадым.

...Яр башында икеләнеп калдык:
Ярты гомер үткән, куркыта...
Уртак ярлар тоташ газап икән,
Искә төшсә, күңел ут йота...

## *Ярый, ярамый*

Ярамый, ярамый
Китапны ертырга.
Гаебең булмаса,
Юк-бардан куркырга.

Ярамый турсаеп,
Үпкәләп йөрергә.
Кечкенә сәбәпне
Зур итеп күрергә.

Ярамый алдалау
Ышанган кешене.
Күпсенү, сүз итү
Эшләгән эшеңне.

Ярамый тавышың
Күтәреп сөйләшү.
Кемнеңдер уңышлы
Эшеннән көнләшү.

Ярамый төкерү
Утка да, суга да.
Бу таләп миңа да,
Бу таләп сиңа да.

Ярамый санламау,
Санлашмау дус белән.
Дөньябыз күңелле
Намуслы эш белән.

Ярый тик яхшы эш,
Гаделе, тигезе.
Шул ярый, ярамый –
Тормышның нигезе.

# Аптырый эзтабарлар

Кызыл шәфәкъ нуры сеңгән
Кызыл эзтабарларга.
Чыга алар ел да бер кат
Исемлекне барларга.

Ватан сугышы кырында
Кемнәр һәлак булганнар,
Кемнәр исән, кире кайткан,
Хәбәрсез югалганнар, –
Өйдән өйгә йөриләр дә
Аптырый эзтабарлар.
Төгәл чыга бит бары тик
Кайтканнар, ветераннар...

Мәрфуга әби, мәсәлән:
«Миралимым көтәм,– ди.–
Үлмәс минем пәһлеваным,
Үлсә, үләр бүтән,– ди.–
Ак күгәрчендәй пакь иде,
Төпчегем, туган каным.
Рәхәт күрмәсләр барыбер
Кыйсалар изге җанын»...

«Инә күзеннән үтәрлек
Үткенлеге бар иде.
Булгандыр ялгышу. Бәндә
Хатадан халимени?..
Көтәм мин газиз баламны,
Билгесез югалмас ул.
Әсирлеккә алсалар да
Сатлык булмас, булмас кол». –
Өметләнә Сания әби,
Өметләнә аналар.
Аналарга ярдәм кулы

Сузалар эзтабарлар.
Күңелләрне кимсетмәгез,
Күңел кыллары нечкә.
Барлый алар – кем билгесез,
Кайтмаган үкенечкә.
Авыл буйлап йөриләр дә
Аптырый эзтабарлар.
Төгәл чыга бит бары тик
Кайтканнар – ветераннар!

## *Кар яка*

Иңебездә ап-ак яка,
Җиңнәрдә – ак беләзек.
Ак кар белән кибет салдык,
Ак алмалар сатып алдык,
Ак кар белән түләдек.

Ак кар белән койма тоттык,
Капка куйдык ак кардан.
Бозлы, тайгак юллар үттек,
Юл-сукмакка ком-таш сиптек,
Ташып чишмәле ярдан.

Без уйныйбыз.
Ак кар төшә,
Төшә дә иңгә ята.
Оеп кына ява-ява,
Болыттан җеп сава-сава,
Туннарга «тегә» яка.

## Чынга ашкан хыял

Күрше авылда бит һәйкәл,
Карт ана итсен нихәл,
Шактый ерак арасы,
Көндә ничек барасы,
Әрнүләрен эчкә йотып
Елый солдат анасы...

* * *

Шәкертҗан инде пионер
Булышчы өйләрендә.
Колхозда да атлар җигеп
Эшли җәй көннәрендә.
Ялга туктаган арада,
Тарантасның түренә
Дәү әнисен утырта да
Күрше авылга китә.
Бормалы басу юллары
Һәйкәл янына илтә.
Ә ана, капшап таш сынның
Кулларын, аякларын,
Карап тора, тора озак:
«Нәкъ минем Гадельярым!..»

* * *

Кышлар җитсә, җепшек карлар
Ява да, ява гына.
Төрле-төрле бизәк ясый
Каралты яңагына.
Өеп куя сырындысын
Нәкъ кешегә охшатып.
Кылыч тоткан солдат шунда
Басып тора күк кайтып.
Сырындылар, таш солдатлар

Чуалттылар уйларны,
Сихри манзарага карап,
Матур хыял уянды.
Солдат басып тора сыман
Туган авыл түрендә.
Энҗе карлар арасыннан
Гүя сыны күренә.
Әйтерсең карлар авылга
Куаныч алып кайтты.
Буран гына сарган икән,
Малай абыйсын тапты...
Классташларын җыйды да
Серен чиште Шәкертҗан.
Шау да гөр килде малайлар
Ризалык – бертавыштан!

* * *

Бүген менә яңа хәбәр
Җанландырган мәктәпне.
Бүген чөнки бар да белгән
Төнлә булган хикмәтне.
Килеп җиткәннәр барысы,
Авыл аксакаллары.
Әниләр дә, әтиләр дә,
Сугыш ветераннары.
– Торып чыксам,– ди бер бабай, –
Карыймын ушым китеп.
Ап-ак кардан – солдат сыны,
Сөйлә могҗиза итеп.
Коеп куйган һәйкәл бит бу
Күрсәгез менә әгәр.
Алтын икән куллары, һай,
Хак алтын икән мәгәр.
Ләкин шунысы кызганыч,
Солдат кыш өчен генә.

Корылсын иде мәңгелек
Һәйкәлнең нигезенә.

* * *

...Нәни күңелләрдә туган
Хыяллар чынга ашты.
Авыл түрендәге кар сын
Чын һәйкәл булып басты.
Һәлак булган ирләр белән
Якынайды аралар.
Авылга сын булып кайтты
Күптән киткән балалар...

Чәчәкләр, үләннәр әнә
Яңа яфрак яралар.
Ә һәйкәл янында күптән
Уттай кызыл яраннар
Гүя алар шиңмәс өчен
Мәңгегә яралганнар!

## *Табигатьнең бер бөртеге*

Үлән белән уяныгыз,
Үлән белән ятыгыз,
Ди әбием,
Яренгә дә
Минем янга кайтыгыз.

Авыл кызларыннан эшкә
Өйрәнеп китмәссезме?
Алар кебек җитез, уңган
Кыз булып җитмәссезме?

Шәһәр тәмам бозган сезне,
Атлар-атламас иткән.
Табигать белән сөйләшү,
Киңәш, элемтә беткән.

Без бит, балам, табигатьнең
Бер бөртеге, бер гөле.
Туып гомер итәбез дә
Җиргә китәбез кире.

### V

*Акыл белән гамәл кыла белгән*
***Халыкта тик — Шәхес табыла.***
***Халык белән Шәхес даны үсә,***
***Шәхес белән Халык таныла!***



## *Шәхес белән халык таныла*

Кыя-таудай горур талантлар бар,
Сыгылмас һәм сынмас кебекләр.
Сындырмый да, сулдырмый да аны
Саклый белү кирәк, егетләр.

Саклау кирәк.
Халык бәхетенә
Туып-үсеп, күзгә күренгәч.
Үсендереп яшәтергә кирәк,
Буй җитмәсен хәтта үрелгәч.

Мәртәбәгә, дәрәҗәгә куеп,
Күрә белсәң әгәр күңелен –
Яшәтәлсәң, ул да яшәтәчәк,
Данга күмеп, халык гомерен.

Акыл белән гамәл кыла белгән
Халыкта тик – шәхес табыла.
Халык белән шәхес даны үсә,
Шәхес белән – халык таныла!

# *Галиҗәнап әнкәй*

*Кадерле әнкәем Закирә Шәйхетдин*
*кызы Сабировага багышлыйм.*

Алиһә дә, ханбикә дә түгел,
Син гап-гади татар килене.
Гомер иткән йорт-җиреңә әллә
Күңелеңнән нурлар иңдеме?

...Бала булып яшәгәнсең башта
Тапкан, баккан газиз әнкәңә.
Сабый булып барып сарылгансың
Җиңү яулап кайткан әткәңә.

Зифа булып үсеп җиткәнсең дә,
Килен булып килеп иңгәнсең.
Ярсу җанлы, дәртле, мәхәббәтле
Иргә хатын була белгәнсең.

Таңнан торып казан аскансың син,
Иген чәчеп уракургансың.
Әмма җирнең һәрчак уртасында
Син булгансың һәм нык торгансың.

Итәк тулы уллар, кызлар әнә –
Ничә җанга Ана син хәзер.
Син – алиһә безнең дөньябызда,
Тезләнергә әзер, бир әмер.

Син патшасы безнең яшәешнең,
Күпме йөрәк сиңа тоташа.
Синең сөю көчле иткән илне,
Алып чыккан янган ут аша.

Син – гап-гади татар килене бер,
Син – гап-гади татар хатыны.
Син – иң бөек яшәү чыганагы,
Галиҗәнап әнкәй, алтыным!..

# Әфсенлисең Шагыйрь җанлы итеп

*Резеда Ганиевага*

Хисси касә – Шәрык илләреннән,
Сәгадәтле Сөю күлләреннән,
Гомәр Хәйям, Фирдәүсиле дөнья –
Гарәп, фарсы, төрки телләреннән.

Думавилар, Исхакыйлар белән
Әле үлеп, әле терелгәндә,
Әнкәйләрең белән намазлыкка басып,
Вөҗүд-җаның акка төренгәндә –

Өлге итте Сине күңелебез,
И мөкатдәс галим, мөгаллимә!
Чыда бүген барлык мактауларга,
Туктатыгыз, тукталыгыз, димә!

Чәчне йолкып оран салыр чакта,
«Гөрзиле»ләр көткән чакта чатта,
Галәм белән Җирне багланышка кертеп,
Әфсенлисең Шагыйрь җанлы итеп.

Шигъри сүзнең тәмен, кыскалыгын,
Акыл белән сөйләү осталыгын,
Фәнни телнең могҗизалы көчен,
Рәхмәт Сиңа, күрсәткәнең өчен!

# *Тыңлагыз!*

*Сүз остасы Айрат Арсланга*

Тугансыңдыр син, бүз бала,
Шагыйрьләр бәхетенә.
Кемне генә утыртмадың
Тукайлар тәхетенә?!

Агыла Сүз...
Тыңлар өченгә дип,
Сүз сөярләр бире җыелган.
Ә Арслан мәгърур –
Һәрбер күзәнәге
Бөек Шигырь белән туенган!

Тынлык!..
Тынлык бүген үзе өнсез калган,
Аның тавышына бүлелеп.
Әҗәл кагылганнар, түзә алмый,
Чыгар сыман бүген терелеп.

Иманлысаң,
гамле,
гайрәтлесең
Өләшә ул,
Илтә халыкка.–
Йотасың Сүз,
Йә кабынып китеп,
Әсәренеп,
Телсез калып та.

Әйтә белеп әйтелгән Сүз – назлы,
Бит очыңнан үбеп аладыр.
Ялкынлысы – үзәгеңне өзә,
Каны саркып торган ярадыр.
Ә кайчакта?..
Чиртә маңгаена –
Аяк астын

Убылмаса шунда бик ярый...
Әнә шулай, агын акка куеп,
Сизгер Арсланнар Суз сайлый.
Арсланнар кирәк булган икән
Йөгәнләргә шигырь атларын.
Тукайгача хәтта күтәрергә
Талантларның гозер-хатларын!

...Тагын кемнәр туып,
Гади сүздән
Нәкыш чигеп, сурәт төшерер?
Галиҗәнап Шигырь!
Мең бизәкле
Кыйммәтеңне кемнәр төшенер?

Агын акка,
Күген күккә куеп,
Фатихасын биреп дәвамга –
Шагыйренә тугел,
Шигыренә карап,
Агыла Сүз
Гамьле гавамда!

## Мөгаллимә-галимә

*Флера Сафиуллинага*

Мөгаллимә, Сез – галимә,
Сез – минем укытучым.
Белемле кеше булсын, дип,
Кайгырып ут йотучым.

Һәр шәкерт, һәр талибәгә
Мәгърифәт, нур бирүче.
Туган телне өйрәтим, дип,
Йөрүче, йөгерүче.

Ут йотучы укытучым,
Мөгаллимә-галимә,
Мактау сүзе әйтәлмәдем
Моңарчы бер кәлимә.

Сез укыткан егет-кызлар
Бүген шагыйрь, шагыйрә –
Гыйлемне Сездән алсын дип,
Кызын «Татфак»ка бирә.

Сез – иң мәртәбәле Кеше,
Сез – иң чын укытучы.
Шәкертем кеше булсын, дип,
Утлы күмер йотучы!

# *Моңның йөрәге — Синдә*

*Сара Садыйковага*

Туган Җиргә табынгансың,
Давыл булып кабынгансың,
Кар-бураннар ябынгансың
Көйләреңдә – Сара апа!

Күңелләрдән саркыгансың,
Ефәк нурлар талкыгансың,
Йолдыз булып балкыгансың
Көйләреңдә – Сара апа!

Гөлчәчәк булып шыткансың,
Утлы күмерләр йоткансың,
Туфан-су булып купкансың
Көйләреңдә – Сара апа!

Шул моңнарың – кышта, көздә,
Шул моңнарың – йөздә, күздә,
Яши илдә, яши бездә,
Моңның йөрәге – Синдә!

# *Балет аккошы*

*Әлфия Айдарскаяга*

Яшел Үзән якларыннан
Чыккан пар былбыл алар:
Газиз Айдарский һәм дә
Сара Садыйковалар.

Халкыбызның менә шушы
Ике бөек затыннан
Дәвам булып кала бер кыз –
Үзе шәхес – асылда!

Үзе дә талант иясе,
Үзе дә сәнгать колы.
Үзе дә олы җанлы ул,
Балет аккошы моңы!

## *Балкып торсын йөзең*

*Энҗе Закировага*

Синең хакта, Энҗекәем,
Язу бик тә ләззәтле.
Чөнки синең гомер юлың
Мәрхәмәтле, гыйззәтле.

Бик күркәм сабыр гадәтең,
Шигырьле нечкә җаның,
Лаек һәртөрле мактауга,
Сөекле Энҗе ханым!

Бәхет бирсен!
Муллык күрсен
Фатихалы нигезең.
Улларың гел сөендерсен,
Гел балкып торсын йөзең!

Ярдәмләшеп, киңәшләшеп,
Уфтанмый, уйлап кына
Гөрләп яшик,
Бергә яшик,
Без – Җирдә кунак кына!

# Җырла, җырла, дип әйтәсез

*Хәмдүнә Тимергалиевага*

Бөреләр шартлап ярыла,
Гөлт итеп утлар кабына,
Син җырлап җибәрсәң бер.
Дөньяларны оныттырып,
Йөрәкләрне умырттырып
Утларга саласың, бел!

Җырла, җырла, дип әйттеләр,
Өйрәттеләр, көйләттеләр –
Җырлап «Гали»гә киттең.
«Җомга»ларны суздың кичен,
«Картуф»лардан алдың үчең,
«Торна Зариф»ка җиттең.

Гөнаһларың санадылар,
Чәйнәп-чәйнәп карадылар,
Йоталмадылар, туган.
Тотып ашарлар иде бик,
Тешләп ташларлар иде бик,
Гәүдәң олырак булган.

Холкың кәттә, уең шашкын,
Җыр-моңнарың гүя ташкын,
Татар кызы Хәмдүнә.
Тыеп торып булмый кызсаң –
Шыңгырдатып җырлар сузсаң,
Һәр тарафны моң күмә.

Адым саен «даһи» бүген,
Йолдыз басты сәхнә күген,
Күренми дә үзәге.
Ходай үзе ярдәм иткән,
Казаннарга килеп җиткән
Котлыярның гүзәле!

Бөреләр шартлап ярыла,
Гөлт итеп утлар кабына,
Син җырлап җибәрсәң бер.
Дөньяларны оныттырып,
Йөрәкләрне умырттырып
Утларга саласың, бел!

## Кәүсәрия

*Кәүсәрия Сираҗетдиновага*

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Үзе җитез, сылу, сөйкемле.
Кешелегең – йөрәккә май кебек,
Әйткән сүзең тапкыр, үтемле.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Тыпырдатып биеп җибәрсә –
Җансызлар да сикереп торыр кебек,
Итәгеннән искән җил бәрсә.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы –
Тормышның ул үзе, чып-чыны!
Сәхнәләргә биеп килеп чыкса,
Сокландыра нәфис буй-сыны.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы –
Сыгылмалы, сылу гәүдәсе.
Гүзәллеккә матур өлге булып
Тугандыр бу Алла бәндәсе!

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Кәүсәр күлендәме коенган?
Сәхнәләрдә биеп торган чагы
Күз алдыңнан китмәс, уеңнан...

Фаҗигале төстә вафат булдың,
Күзләр тидеме соң үзеңә?
Ике улың үсеп килә иде,
Карап кына торып күзеңә.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Уңган идең, өлгер, ягымлы.
Ашкынып лар дөнья көтүеңнең
Үлем булдымы әллә калымы?

Сагынабыз, шундый сагынабыз,
Якын идең гүя багалма.
Шәһитләрнең урыны җәннәттә, ди,
Шулай булсын, газиз бер Аллам!

## *Ак әниләр*

*Ләйлә Хәмитовага*

Йөзегездән гүя ак нур агып тора,
Күзегездән гүя йолдыз багып тора.
Сүзләрегез йомшак кына, назлы гына
Саф чишмәдәй челтер-челтер тамып тора.

Дөньям өчен үрнәк итеп алдым сезне,
Күңелемнең иң түренә салдым сезне.
Үзкәемә калсын әле дип тормыйча.
Яктыртасыз, балкытасыз безнең йөзне.

Йөзегездән гүя ак нур агып тора,
Күзегездән гүя йолдыз багып тора.
Сүзләрегез йомшак кына, салмак кына
Саф чишмәдәй челтер-челтер агып тора.

# Беренче мөгаллимәм

*Беренче укытучым*
*Гөлсем апа Салиховага*

Күзләреңдә очкын, ялкын,
Йөрәкләргә учак яктың,
Беренче мөгаллимәм.
Күңел тәрәзләрен кактың,
Саф чишмәләр булып актың,
Беренче мөгаллимәм.

Син галим дә, син җырчы да,
Син рәссам, тылсымчы да,
Беренче мөгаллимәм.
Сәяхәтче, син сынчы да,
Син үзең үк укучы да,
Беренче мөгаллимәм.

Белем дигән дәрья кичтек,
Бергә үстек, бергә күчтек,
Беренче мөгаллимәм.
Якты көннең кояшы син,
Гомерләрнең юл башы син,
Беренче мөгаллимәм.

Балачакның күзе бит син,
Сабыйлыкның үзе бит син,
Беренче мөгаллимәм.
Гадиләрнең гадие син,
Мәктәптәге әнием син,
Беренче мөгаллимәм!

# *Кара төн яктысы*

*Табиб Иркен Галиевкә*

Бәлки, күрәчәгем җилкеткәндер,
Карамыйча көчле явымга,
Җыендым да, эш сәгатем беткәч,
Кайтырга дип чыктым авылга.

Кул күтәргәч, ялгыз кыз баланы
Кызгангандыр шофер, күрәсең.
Утыртты да тау юлыннан китте...
Ни буласын каян беләсең?

...Таеп китте кинәт тәгәрмәчләр,
Төн, яр, яңгыр – барысы буталды...
Ул сузмаган булса ярдәм кулын,
Күрер идеммени бу таңны?!

Кыл өстендә торган минем гомер,
Кыл өстендә калган бит җаным.
Кара төндә күңел нурын түгеп,
Биргән икән табиб... үз канын!

## *Солдат әнисе монологы*

*Әфганстанда һәлак булган авылдашым
Рәшит Фәрдиевның әнисе – Мәдия Фәрдиевага*

Мин монда бала тудырам,
Мин монда бала карыйм.
Ач булмасын, туңмасын, дип
Пешерәм, тегәм, ямыйм.

Мин монда бала үстерәм,
Кадерләп, көйләп, өфләп.
Ә анда...
Шул газизләрне
Карчыга кебек чүпләп
Тора сугыш чукмарлары –
Серле уклар сызгыра.
Илкәемдә юкса еллар
Имин генә, тын гына.

Бар шул әле күрше хакы
Дигән изге йолабыз –
Тик урынлы булса гына
Ул «хак»ны без йолабыз.

Вазифа санала микән
Тар-мар итү чит йортны?
...Эш уза – без сөйләнәбез
Чәйнәмәк булып уртны.

Кешеләрнең җанын кыю
Акланмады һичкайчан.
Тапкан балам, зинһар өчен,
Кан чөмерүдән тайчан![1]
Җан җимерүдән саклан!

---

[1] Сак бул, ерак йөр мәгънәсендә.

# *Көллиятем*

*Казан педагогика көллиятенең 125 еллыгына*

Тормыш үзе тудырган мәктәп бу,
Иң өлкән мәгърифәт учагы.
Белемгә омтылган егет-кызны
Сыйдырган аның киң кочагы.

Көллиятем, син Казанда
Абруйлы белем йорты.
Синдә сакланды халкымның
Акылы, затлы рухы.

Мөгаллимнәр мәктәп-мәркәзе син,
Татар зыялысы үзәге.
Син үстергән талант ияләре
Милләтемнең йөзе-бизәге.

Көллиятем, син Казанда
Абруйлы, изге урын.
Синең шәкертләр тарата
Гыйлем-мәгърифәт нурын.

Гөрли ул, бүген дә гөрләп яши,
Бүген дә тәрбия учагы.
Белемгә омтылган егет-кызны
Чакыра аның киң кочагы.

Көллиятем, син Казанда
Шөһрәтле, изге урын.
Киләчәккә илтәчәкбез
Безнең көллият җырын!

# Үз исемең белән тудың

*«Азат хатын» журналының кабат*
*«Сөембикә» исеменә кайтуы уңаеннан*

Үз исемең белән тудың,
Миһербан бирсен Ходай.
Иң күркәм чагыңа килеп
Җиткән көннәрең бугай.

Сөембикә гакыллары
Туплансын үзкәеңдә.
Сөембикә сылулыгы
Чагылсын йөзкәеңдә.

Ханбикәдәй зыялы бул,
Зыянлы булма ләкин.
Акыл бирер киңәшче бул,
Назыңнан итмә ятим.

Эчке бер нур балкып торсын,
Дәрт-дәрман ташып торсын.
Егет-җилән бер кырыйда
Башларын кашып торсын.

Яңарып тор, җанланып тор,
Сердәшче бул,
Бул серле.
Горурлык бир хатын-кызга,
Мәкерле булма, керле.

Исемкәең җисеменә
Ят булмасын, мач булсын!
Һәр сәхифәңдә укучы
Нур иленә хаҗ кылсын!

# Сөембикә сүзе

Чибәрлегем булды бер фаҗига,
Илгә-көнгә афәт чакырды.
Сөя белми сөйгән дуамаллар
Мәхәббәтне канга батырды.

Явыз патша гашыйк булган, имеш,
Сурәтемне минем күрүгә.
Мәхәббәтен кире каккан өчен
Әмер биргән корал-чирүгә.

Сугыш белән яулап алам, дигән,
Мөселманның Сөембикәсен.
Тик белмәгән канга сусау хиснең
Нәфрәткә бары күчәсен.

Мәхәббәтне корал җиңә алмый,
Көчкә карап тумый саф тойгы.
Явыз затлар хәтта сөя белми,
Явыз затлар белми хак уйны.

Корбан булдым кырыс сәясәтнең
Мәкерле һәм баткак юлында.
Гап-гади бер хатын булыр идем,
Сөя белгән чын ир кулында...

# *Шагыйрь чишмәсе*

(Поэма)

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

*(«Пар ат»)*

Тукай аһәңнәрен саклый
Кушлавычта куш тирәк.
Тарихта – син, телләрдә – син,
И изге, нурлы төбәк!

Кушлавычның сукмаклары
Каен белән каелган.
Моңнарым, күңел җырларым
Тукай белән баеган.

Кул биреп күрешә кебек
Кушлавыч каеннары.
Аны тормыш талкыса да,
Юлыннан аермады.

Каермады, аермады
Иленнән, төбәгеннән.
Берьюлы мең чишмә бәреп
Чыккан күк йөрәгеннән.

Дәртлесе дә, моңлысы да,
Акыллы, зәһәрләре.
Шүрәлесе, Кисекбашы,
Җәннәте, мәхшәрләре

Сыйган Тукай йөрәгенә,
Язган Тукай каләме.
Тукай белән җылына күк
Җире, Җиһан-галәме!

Монда аның балалары,
Төрләре, табыннары.
Монда буялыр тузаны,
Һәм юар сабыннары...

* * *

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән.

*(«Туган авыл»)*

Якын чишмә шактый ерак калган,
Авыл гүя артка чигенгән.
Тик китмәгән халык күңеленнән,
Гореф-гадәт, йола, диненнән.

Тау битендә тезелеп киткән урам –
Хуҗалары күчкән Казанга.
Чирәм үскән күптән буш нигезгә,
Ихатага, сукмак, ызанга.

Тешкә берле[1] бүген бала-чага,
Бәбкә саклый чишмә ярында.
Синдә алган тәэсир-хисләремнең
Сөйләү мөмкин түгел барын да.

Үз күзләрем белән карап тордым
Тукай күңеле төшкән чишмәгә.
Изге булгандыр бу салкын чишмә –
Тукай күңеле төшмәс тикмәгә.

Никрут булып авылына кайткач,
Киңәшне диң аңа кем биргән?
Чистарткан ул шушы тау чишмәсен,
Яңа бура бурап иңдергән.

---

[1] *Тешкә берле* – диал. бик аз, берән-сәрән.

Мәгънә белгән, димәк, мәнле булган,
Изгелеккә тарткан күңеле.
Юл-сәфәргә чыгар алдыннан, дип,
Савaплы эш кылган иң элек.

...Кемдер берәү чирләп китсә бүген,
Шул чишмәне искә төшерә.
Адарына чиләк, чүмеч куя –
Әзер булсын юлчы кешегә.

Тукай кулы тигән чишмә яры,
Тукай эзе калган үзәннәр.
Хәсрәтеннән телгәләнгән тауның
Җәрәхәте инде төзәлгән.

Тукай чишмәсенең суын эчтем,
Уйга чумдым, йөреп шул тауда.
Ятим нигезләргә чирәм үскән,
Көтү кергән, төшкән туплауга...

* * *

Алкаларың якты бриллиант ич...
(«Ни кирәк тагы?»)

Бер утырдым әле
Кушлавычта,
Кушкаенга терәп аркамны.
Әкиятләрнең кайсысына китеп,
Кайда югалттым соң алкамны?

Кайда шулай балалыкка кайтып,
Тау битеннән түбән атылдым?
Ак каенга ак бишекләр элеп,
Хыялымда микән – атындым?

Искә алып, тыңлап, колак салып,
Терелтергә теләп тырыштым.
Фараз итеп булмас кырык ягы
Бар икән бу явыз тормышның.

Чәчәкләрен койган, шиңгән гөлгә
Су сибүнең юктыр файдасы –
Ай урынына Кояш балкыса да
Алсуланмас Сөю алмасы!..

Җылы җиле белән җитәкләшеп
Очтым әле,
Күрде күзләрем:
Ак нур гүя яшел күлмәк кигән
Каен кызларының тезләре...

Ай-ураклы алтын алка кигән
Кушлавычның сылу кызлары
Сискәндерде.
Күзләрендә –
Тукай яккан
Учак күзлары!..

* * *

Бик юашлатты мине яшерен сөюдән җан көю,
Бар иде булган чагым хәтта арысланнан кыю!

*(«Актык тамчы яшь»)*

Сөюеңә җыр яз, диләр,
Җитәр микән соң сүзем?!
Яшен кебек ялтырап алды,
Чагылып калды күзем.

Яктылык зур булган саен,
Каравы аңа кыен.
Дәште дә бит Мәхәббәтем:
Кил миңа, ярат, сыен.

Мин үзем качтым шикелле
Мәхәббәт кочагыннан.
Шырпы сызмый ут алырлык
Сөюем учагыннан.

Зәйтүнәм, сине сөям, дип,
Әйт тә сал инде шунда.
Әллә ни булды телемә,
Бар эшем төште кулдан.

Бар иде булган чагым
Хәтта арысланнан кыю.
Бик юашлатты шул мине
Яшерен сөюдән җан көю.

Сакланам, имеш, якланам,
Ямьсез, көфер сүзләрдән.
Актык тамчы яшем тамды,
Тамды минем күзләрдән.

Бодай башагы бизәге
Зәйтүнәм чәчләрендә.
Бары ул гына уемда,
Хыялый кичләремдә.

Салкын көннәрдә кызышам,
Эссе көннәрдә туңам.
Бәхет эзлим. Бәхетсезлек
Өстенә барып чыгам.

Табигатьтә төрле фасыл,
Суыкны көтә балан.
Ул янымда булса әгәр,
Ялт итәр иде алан.

Гомер юлым маңгаема
Язылганмы соң ялгыш?
Күрсенәме соң бу күңел,
Күпсенәме соң язмыш?

Бу көннәрем гомеремнең
Кай сәгать, кай минуты?
Эч-бавырымны көйдерә
Әллә аерылу уты?

Әллә хушлашыр көннәрем
Җиттеме аның белән?
Эчәр суларым беттеме
Минем өлешкә тигән?

Йөз шигырь язудан авыр
Бер «Яратам!» диюе.
Менә шулай кайвакытта
Шагыйрьләрнең сөюе...

* * *

Бар егетләр: бик тәкәбберләрчә тоткан позасын,
Чөнки дөнья бакчасының күргән ул тик розасын.
*(«Егетләр»)*

Өйдә бик тиз боектыгыз,
Бакчада бер дә харап.
Нигә алай? дип сорагач,
Әйттеләр туры карап:

Без, Роза чәчәкләре,
Зыялылар, затлылар.
Бар шундыйлар: мәхәббәттә
Намуслары таплылар.

Вәгъдәсендә, әйтик, менә
Тормады синең ирең.
Назлады тагын берәүне
Үткәрде шунда төнен.

«Яратам» дип, йөз мәртәбә
Пышылдады аңа да.
Шаһит булу хурлыгыннан
Битем-тажым яна ла.

Безнең алда хыянәт итте,
Җырлады шул ук «көйгә»...
Аннан чәчәк белән кайтты,
Без – менә синең өйдә...

Син тагын сорау бирәсең:
Нигә тиз боектыгыз?
Оятыгызга көч килер
Эшкәме юлыктыгыз?

Сөю офыкларын ертып,
Мәкер баскач җиһанны,
Балкып янарга түреңдә
Каян алыйм илһамны?

Шул хурлыкка чыдый алмый,
Инәле булып калдым.
Мәхәббәттә ялган вәгъдә
Безне шөбһәгә салды.

Бу дөньяның бакчасыннан
Бары матурны эзләп,
Тәкәббер тотып гәүдәсен
Һаман «асыл»ны күзләп,

Белмичә әдәп-канунның
Оят дигән камчысын,
Курыкмыйм мин бер нәрсәдән,
Күрмәм хурлык ачысын,

Дип йөргән егетләр бардыр,
Үзен тәкәббер тотып.
Матурлыкның – «мат»ы аңа,
Яшәсен шуны йотып!

* * *

Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.
*(«Кыйтга»)*

Әллә иске, әллә инде яңа фикер,
Әллә каргый, әллә әйтә дога-зекер,
Сөйләшәме, серләшәме шулай җаннар –
Агачларның яфраклары лепер-лепер.

Акты җырлар, акты моңнар, тидиясе –
Юатмакка үксез җанны ни диясе?
Габдулланың үз әтисе Мөхәммәтгариф
Кушлавычның зиратында гүр иясе.

Авылының мөхтәрәм бер заты иде,
Һәм атасы мулла булмак гыйлем бирде.
Өйләнешеп, даһи булыр углы тугач,
Ни сәбәптин?
Бик тә яшьли әҗәл килде.

Мулла нәселе, мулла углы – һәр булмышы,
Каннан килә Габдулланың укымышы.
Тирән акыл, якты зиһен, үткен уе
Белән байый татарымның сүз тормышы.

Тугры Тукай туры итеп һәммә сүзне –
Әйтсә әйтте, чыгарырлык итеп күзне.
Кызартмады, каралтмады милли йөзне,
Агартты тик,
Пакьләде ул, әйе, безне!

Әллә иске, әллә инде яңа фикер,
Әллә каргый, әллә әйтә дога-зекер,
Сөйләшәме, серләшәме шулай җаннар –
Агачларның яфраклары лепер-лепер...

* * *

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
*(«Дошманнар»)*

Исләремдә калганнары,
Каныма тоз салганнары,
Каргышлары, ялгышлары,
Язмышымның сагышлары...

Истә Шәрифә карчыкның
Килмешәк син, дигәннәре.
Артык тамак, артык җан, дип,
Намусыма тигәннәре.

Мин бер «чәүкә».
Яннарымда
Гел «күгәрчен» балалары.
Кем иркәли, кемнәр бәйли
Ятимнәрнең яраларын?

Истә әнкәмнең Саснага
Үз янына алдырганы.
Иң авыр көнем булгандыр
Тома ятим калдырганы.

Әнкәемне бир, дип сорап,
Сасна авылы картларыннан
Йөгердем яшькә буылып,
Җитәлмәдем артларыннан.

Чит-ят итеп каршы алган
Бу җиһанның киңлегенә
«Никләр тудырдың», әнкәем,
Кертеп тәмуг читлегенә?..

Исемдә юк үз әткәем,
Исемдә гел бүтәннәре.
Салам түбә, җимерек өйләр –
Коймалары, читәннәре.

«Асрамага бала бирәм,
Бала бирәм, асрамага»:
Кушлавычка, Өчилегә,
Бер авылга, бер калага...

Азмы каккан вә сукканны
Күтәрдем мин ятим бала?
Сыйпаган тик маңгаемнан
Халкым кулы – Милләт-Ана!

* * *

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереңташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

*(«Өзелгән өмит»)*

Кабереңә киләм изге Ана,
Күземнән кан, җаннан яшь тама.
Чарасызлык кыскан ул заманда
Кем гаепли Сине, сүз яга?

Бәетләрең бер кырыйда торсын,
Сезнең язмыш мәгълүм чагында.
Җир упмаса, горурлану хисе
Һич туктамас халкың җанында.

Сигез оҗмах насыйп булсын Сиңа,
Насыйп булсын барлык хөрмәтләү.
Гөнаһ булыр шигырь яза торып,
Табына торып, дәһи сүз әйтмәү.

Кешелеккә син Тукайны бирдең,
Җир башында чишмә булдырдың.
Нинди теләк теләп йөрдең икән,
Нинди дога укып тудырдың?

Син дөньяга илаһи зат бирдең,
Кеше бирдең, Бибимәмдүдә.
Син дөньяга бөек Шәхес бирдең,
Шагыйрь бирдең, рәхмәт, Мәмдүдә!

* * *

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын,
Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калмасын.

*(«Сөй гомерне...»)*

Арча кыры – алтын бишек –
Дулкынлана җилләрдә.
Онытылган исем-атлар
Кайта туган илләргә.

Газиз Гобәйдуллин, Галәү,
Шиһап Мәрҗани бәге –
Синдә тамыр җибәргәннәр,
Шанлы Тукай төбәге!

Арча кыры отып алган
«Җидегән чишмә» көен.
Тукайлы, Гомәрле төбәк
Булуың белән сөен.

Сөен, синең җирдә туган
Мөхәммәт, Гарифлары...
Шәхесләр белән бизәлә
Туган як тарихлары.

Тукайның якын дуслары,
Якташ-каләмдәшләре.
Алар аша сурәтләнә
Шагыйрьнең кан-яшьләре...

* * *

Кирәк булса, әйтеп бирим: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһап хәзрәт.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне
Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм.

*(«Шиһап хәзрәт»)*

Язган Тукай. Яза хәзер безнең каләм,
Фикердәше Әмирханга биреп сәлам.

Тамырлары кемнәр, диеп, сорау бирсәң,
Кызыксынып нәсел бакчасына керсәң –

Милләтемнең дан-шөһрәткә лаек заты –
Булыр берсе Тукай әйткән Шиһап атлы.

Акчурасы, Бигиевы, Түнтәрие,
Үзе генә ни тора бит Исхакые!

Шушы затларга тоташа бер иптәше,
Фатих Әмирхан исемле чын хистәше.

Тирән милли фәлсәфәсе Әмирханның
Әсир иткән, көчле иткән шагыйрь җанны.

Рухташым, остазым, дип бәя биргән,
Шатлыкта да, кайгыда да аңа килгән.

Фатих, Тукай – милләтемнең хис остасы,
Әйдәүчесе, озын сүзнең шул кыскасы.

Берсе өчен икенчесе булган әләм,
Күп сөйләргә хәбәрем аз – шулдыр бәлам...

* * *

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй...
*(«Милли моңнар»)*

Милли көйнең тәмен,
Сүзнең ямен
Танытучы кемнәр, дисәләр,
Якташларның якты зиһене, дип,
Арча яклап, җилләр исәләр.

Исемлеккә тагын теркәр идек,
Мөхәммәтне –
Сәнгат малаен.
Мөгаллимнәр мөгаллиме булды,
Укытты ул кызын, малаен.

Танытты ул чын әдәби сүзнең
Егәр көчен – башы сауларга.
Тауга карап,
Таулар булып булмый,
Сокланырга кирәк Тауларга!

Шигырь түгел,
Кыйсса язу тиеш,
Багышлап һәм башлап бүгеннән.
Нинди генә йолдыз калыкмады
Туган ягы – күңел күгеннән.

Тарих чокырының төпкеленннән
Табып чыгармады кемнәрне?
Фәкать аның акылы бәян итте
Мәңге сер булачак серләрне.

Торналары төшкән ул җирләргә
Кырык бердән килгән малайлар,
Фронтовиклар: Рушад, Хәкимҗаннар,
Исәнме, дип, Кәшфи агайлар.

Пәйгамбәрлек йөген тартучыга
Фәрештәсе фикер өрдеме?
Кеше китә, җыры кала, егет,
Бәхилләшү кирәк, дидеме?

Бәхилләшү, әйе, авыр булды,
Ачылып калды ачы тәҗрибә.
Ут чәчәге ушны үткерләсә,
Каз канаты җанга моң сибә.

Кесмәс үзәненә язлар кайтыр,
Гөберчәктә гөрләр сабантуй.
Тальян тартып, ничә Гата җырлар,
Аны сагынып өзелер ничә уй.

Үзәкләргә үтеп, үкендерер,
Табындырыр зиһен-акылы. –
Татарымның олуг Мөхәммәте,
Милләтемнең горур акыны!

Ихлас белән биргән гыйлемнәрен
Саклый шәкерт күңел түрендә...
Гөберчәктә чыккан Ай-Кояшның
Нуры балкый Тукай күгендә!

* * *

Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар,
Сирәк ләкин, дөрес әйтсәм, кешелекле хәялылар[1].

*(«Бәгъзе зыялыларыбыз»)*

Зыялылар бик әдәпле халык,
Зыяннары тими тукмакка.
Юләр белән нигә юләр булсын,
Нәрсә бүлсен алар ахмакка?

Зыялылар зур әдәпле халык,
Гафу сорый, әгәр төчкерсә.
Шәфкать көтмә, аракыдан түгел,
Шөһрәтеннән беркөн исерсә.

Зыялылар хисапсыз ул бездә,
Милләт, диеп «яна» күбесе.
«Яна-яна» намуслары көя,
Вөҗданында көек-көл исе.

* * *

Һәр минут миннән тели дөнья күңел җимешләрен,
Нәрсә пешсен, булса ялкынсыз күңел, сүнгән күңел?

*(«Күңел»)*

Мәрхәмәтсез чагың дөнья,
Алҗыта, хәлне ала.
Белгәннәрем арасында
Булдым бәхетсез бала.

---

[1] *Хәялылар* – ояты, вөҗданы булган кешеләр.

Өзми-куймый, ычкындырмый,
Тотып алып якамнан,
Мәсхәрәләттең җаһилдән,
Тәм таптырдың хатамнан.

Телидер кеше, көтәдер
Көн дә алтын яуганны.
Ничек языйм?
Сизеп торам,
Көтә күпләр ауганны.

Кышларны яз җылыткандай
Ял кирәк, газиз җанга.
Кайгыларда кайнаткачтын
Ник эретмисез назда?

Назлы күңел, язлы күңел
Язалмас, дисезмени?
Күңел җимешләрем пешеп,
Тамалмас, дисезмени?

Чама хисен югалттыгыз,
Җанымны кимердегез.
Килеп, усал ният белән,
Чәемне чөмердегез.

Иҗат чишмәмне агулый
Танышым, белгәннәрем.
Агулый «кадерлем» диеп,
Куенга кергәннәрем.

Яклый алмыйм үз-үземне
Бетте көчем, дәрманым.
Ходаем!
Сыгынам сиңа,
Туктат, биреп фәрманың.

Алланың сөйгән бәндәсе
Газапка, ди, тарыга.
Гөнаһы бетеп, керер, ди,
Изгеләр китабына –

Оҗмах әзерлиләр, диеп
Юаныйммы – сукканда?
Җан газабы белән янып,
Дөрләгән ут йотканда?

* * *

Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт шөһрәткә син...
*(«Шөһрәт»)*

Язу яздым, ләкин һичбер вакыт
Кызыкмадым данга, мөлкәткә.
Сәүдәгәрләр көлде: «Китабыңны
Сатып була иде кыйммәткә...»

Гаҗәпләндем,
Кеше көче белән
Мал тупларга йөргән ач күзгә.
Шагыйрь өчен бары мәйдан кирәк
Шигырь сорап торган хак сүзгә.

Кимсетелеп,
Салкын номерларда
Узындырдым тагын ютәлне.
Җан ачысын салдым шигырьләргә,
Кайгымны тик кәгазь күтәрде.

Сугыш аты кебек түзә-түзә,
Үлеп китсәм беркөн, газаптан –
Тынгы бирмәделәр, дип, Шагыйрьгә,
Сару кайнатырсыз әле азактан.

* * *

Аз кеби баскан бу зольмәт тормышым йортын минем,
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.

*(«Дошманнар»)*

Сырындыга сыенып йоклый
Абыемның[1] өй-иле.
Туктат, туган, килеп җиттек,
Алдыбызда Өчиле.

Монда мәрхәмәт, илтифат,
Монда хөрмәт, монда наз.
Сабыйлыкта-балалыкта
Күрдем аны мин бик аз.

Эчке яктылык сирпелеп
Чыккан җиңгәм[2] йөзенә.
Яшәү дәрте кайтты җанга,
Нуры сүнгән күңелгә.

Караңгылык баскан иде
Хыял дигән өемне.
Танырга теләми яхшым,
Яман өскә чөелде.

Гүя аз минем күргәннәр,
Гүя кан йөткермимен?..
Тапладылар, таладылар
Эт кебек куймый кимен...

Яз кояшына күмелеп,
Калды бу ел Өчиле.
Хәлләндем синдә. Аяктан
Еккачтын тормыш җиле.

---

[1] Кәбир абыйсы.
[2] Рабига җиңгәсе.

* * *

Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.
*(«Ваксынмыйм»)*

Кояш – ерак, Ай – биектә, бәнем,
Ә син – безнең белән.
Йөрәкләрдә, җанда, табигатьтә,
Күңелләрдә гелән.

Кояш – ерак,
Ай – биектә булсын,
Булсын буй җитмәслек.
Җирдә кояш булмак син бар –
Безне хур итмәслек.

Хур итмәссең,
Һич кипмәссең,
Чишмәң исеме – Тукай.
Безнең күңел түребездә
Син ул – Кояш,
Син – Ай!

* * *

Вактыны йөртер кешеләр ул заман миннән күреп,
Файдалансын шунда миннән сәгатен һәркем борып.
*(«Ваксынмыйм»)*

Мәңгелектән килеп, мәңгелектә калды,
Ул җырларда калды, аңнарда.
Тугры булып тарихларга керде,
Байрак булып янды таңнарда.

Әткәм теле булып иркәләде,
Әнкәм теле булып назлады.
Үткәннәрдән киләчәккә китеп,
Җир әйләнә моңлы сазлары.

Чын безнеңчә итеп, милли итеп,
Йөрәкләргә үтеп, бәгырьгә.
«Зиләйлүк»ләр килә, «Тәфтиләү»ләр,
«Әллүки»ләр кайта хәтергә.

Гамәлләре, гамь-гарьләре кайта,
Рухы торып баса шул чорның.
Үлеләрне хәтта терелтерлек
Көчен тоясызмы сез җырның?

Якты исем килә дастаннардан,
Милли моңнар килә үткәннән.
Без тумыштан «Туган тел»гә гашыйк,
Туган җиргә гашыйк күптәннән.

Чишмәләрен эзләп: Кушлавычка,
Өчилегә бардык, Кырлайга.
Арабызда берәү бармы икән
Табынмаган бөек Тукайга?

Гаскәр кебек төз наратлар әнә
Саклап тора Былтыр урманын.
Санап тора Тукай якташының
Ничә чәчеп, ничә урганын.

Тукай яшендә ул ни эшләгән?
Син ни кылдың Тукай яшендә?
Җавап көтә кебек бездән Шагыйрь
Сорау биреп, әйт дип, яшермә.

Шигырь генә түгел кылган гамәл,
Һәр шөгыльнең илдә тәме бар.
Үзеңнән соң гасыр яшәр эшең
Калса гына җирдә – ямең бар.

Тукай гомере ачык мисал безгә,
Тукай сүзе карар, кагыйдә.
Никадәрле гакыл, мәгънә, киңәш,
Сагышлы моң – шигъри ул көйдә.

Бер карасаң, сабый бала кебек,
Сафлык белән тулган Габдулла.
Бер карасаң, аксакалдай өлкән,
Акыл, киңәш бирә Габдулла.

Бер карасаң, ата назы белән
Һәммәбезне көйләп яшәтә.
Бер карасаң, сабак-дәрес бирә,
Хыяллары белән яшәртә.

Бер карасаң, яралы кош кебек,
Канатлары каерып ташланган.
Бер карасаң, арысланнан кыю –
Кайнар гарасатка ташланган...

Канап-канап, яраларын ялап,
Ил өстенә шифа яудырды.
Чирек гасыр гомер яшәп җирдә
Мең ел сүнмәс ялкын калдырды!

Бәйрәм ясап күңел түрләрендә
Пар атлары чаба заманның.
Тукайлары туганчыга кадәр
Нуры булды микән Казанның?

Нуры булды микән авылларның,
Якты җыры җиту кызларның?
(...Очкыныннан Тукай туар кебек,
Күзләрендә янган кузларның...)

Язы барның җирдә җыры булыр,
Язлар бирде Аны бу җиргә.
Зур җаннарга гына насыйптыр шул
Гасырларга үтеп керергә.

Җыры барның җирдә даны булыр,
Бәйрәмнәре булыр мәңгегә.
Без бәхетле, без шагыйрьле халык,
Без – Тукайлы халык мәңгегә!

(Эпиграфлар Г.Тукайның 1955 елда чыккан дүрт томлыгыннан алынды.)

# Каюм коесы

(Поэма)

## I

«...Шөкер, туган нигезендә бүгенге көнгә кадәр Каюм Насыйриның коесы сакланган...»

*Якташы, мөгаллимә Гөлсинә Гайфуллина*

«Моннан соңгылар, әлбәттә, *(хезмәтләремне – Э.Ш.)* файдаланырлар».

*Каюм Насыйри*

### 1

Гасырларны кичеп исән калган,
Исән калган Каюм коесы.
Күпме чишмә юлын югалтканда,
Адашканда – иң мул сулысы,
Насыйрилар нәсел агачының
Бер тылсымы булып,
Ядкаре,
Нуры булып изге гамәлләрнең,
Бер әдәбе булып,
Әхлагы –
Исән калган кое.
Һәм бүген дә
Тибеп тора көчле чишмәсе.
Ничә килеп,
Күпме мәртәбәләр
Сындырганнар булыр
Сиртмәсен...

Кискән саен үсеп чыккан кебек,
Тылсым көче белән кабаттан,
Изгелеккә тугры якташлары

Сиртмә-чыгырларын яңарткан.
Яңарткан да сипләп,
Иплəп кенә
Су алырга йөргән коедан.
Терек суы,
Гүя гыйлем суы
Агып чыга Шырдан[1] буеннан!

2

Белем алу –
Кое казу, диләр,
Инә белән казу – коены...
Гыйлем сөйгән Каюм бабабызның
Таза булган нәсел-буыны!

Ничә гасыр яшәр гомер биреп,
Казыган ул үзенең коесын:
Якташлары, авыл кешеләре
Шифалы су белән туенсын!
Коены да казый белеп казу,
Урынын табып казу кирәктер.
Гыйлем коесына
Корал – инә,
Су коесы өчен – көрәктер.

Урынын белеп, әйе, казу кирәк,
Кадере булсын дисәң, коеңның.
Сүз сөйләсәң,
Белеп сөйләү кирәк,
Дөреслеген тоеп уеңның.
Ләгънәт укып искә алмасыннар,

---

1 *К.Насыйриның туган авылы* – Югары Шырдан күз алдында тотыла.

Коесының суы тәмсез, дип.
Иҗатында, әйткән фикерендә
Сүзе – тозсыз,
Үзе гамьсез, дип.

Рухи кое!
Һәм гамәли кое!
Зиһене дә җиткән,
Көче дә.
Шуңа күрә Шырдан төбәгенең
Якты булгандыр, дим, киче дә!

## II

«Татарларга урыс телен белү кырык беренче фарыз».

*Габдерәхим Утыз Имәни*

«Балалар укыта башлап, капка өстенә вывеска куйгач, частька барып әйткәннәр... Хәтта бәгъзе[1] адәмнәр Казан шәһәреннән кудырырга йөрделәр».

*Каюм Насыйри*

### 1

Әкияттә әйтелмәгән сүзләр
Аның йөрәгенә туплангандыр.
Шуның өчен дә ул кое казу
Ниятенә, бәлки, тукталгандыр.

Килер көнгә тоташтырыр өчен
Бүгенгесен,
Үткән заманнарны.
Яхшылыкны өстен итү өчен,

[1] Кайбер.

Фаш кылырга теләп яманнарны
Язган Каюм.
Каршы чыгар аңа
Бәндәләрнең фәкать абынганы...
Балаларны тәрәккыйга[1] илтү –
Йөрәгендә дөрләп кабынганы.
Әмма шушы изге башлангычның
Тәмамланган ахыры шактый моңсу.
Мөгаллимлек эшен ташлатканнар,
Татарга, дип, урыс теле ничу[2]...

Укытырга урын таба алмый
Бәргәләнеп йөргәч Казанында,
«Куарга» дип, бәгъзе адәмнәре
Хөкем чыгаргачтын азагында,
Тулысынча фәнгә кереп чумган,
Язучылык булган бер шөгыле.
Татарымны аңлы, тәрбияле
Итү һаман
Барлык уй-фигыле.

Зарурлыгын телләр өйрәнүнең
Аңлатмакчы булып
Кылып ният[3] –
Әкиятләр хәтта әйтмәгәнне
Сүз башлаган –
Әйтергә дип, теләп.

## 2

Коега төкермәгез!
Ризыктан олы булып,
Туенып сикермәгез.

---

[1] Үсешкә.
[2] Кирәкми мәгънәсендә.
[3] Уйлап кую.

Туенып сикермәгез.
Ширбәт сораган чагында
Ачуташ эчермәгез.

Ачуташ эчермәгез.
Уеннан уймак чыгарып,
Кайгылар китермәгез.

Кайгылар китермәгез.
Һәр милләтнең үз тамыры –
Телемне үтермәгез!

Телемне үтермәгез.
Минутлык хискә алданып,
Шатлыктан исермәгез...

Шатлыктан исермәгез.
Соңыннан суын эчәрсез –
Коега төкермәгез!
Коега төкермәгез!

## III

«...Гарәпчәдән татарга әйләнүдә – Насыйри бездә беренче кискен революционер булды».

*Галимҗан Ибраһимов*

«...Без – татарлар. Телебез – татар теле!..»

*Каюм Насыйри*

### 1

«...Без – татарлар,
Телебез – татар теле,
Бүтән телдән бер дә ким түгел!» –
Кискен булган галим.
Кайчакларда
Күзледә дә сукыр ул, күңел.

«Яратмыйлар мине,
Милләтемне –
Татар милләте, дип атасам...»
(Мыскыл итеп
Сүгеп җибәргәннәр
Бер-бер җирдә чыгыш ясаса.)

«Урам теле, имеш,
Ломовойлар[1] –
Әдәбият, фәнгә сәләтсез...» –
Шундыйларга каршы чыккан өчен
Насыйрига ярлык[2] –
«Әдәпсез».

Әдәп саклап, ай-һай, күп яшәдек,
Телдән чак-чак колак какмадык.
Беркемнән дә гаеп эзләмәдек,
Беркемгә дә яла якмадык.

Хәтер калдырудан курыктыкмы,
Куштанлану булды микән соң?
Миңгерәтер өчен татар башын
Акыл саттылармы төштән соң?..

Ни булса да булган,
Телгә каршы
Әшәке бер көрәш барганда,
Исән калган телем –
Каюм кебек
Фидаилар[3] сөрән салганга.
Исән калган.
«Телебез – татар теле,

---

[1] Авыр йөк ташучы.
[2] Бәя.
[3] Үзен аямаучылар.

Мөстәкыйль һәм төзек, камил тел!»
И без, татар,
Үзебез утырганга,
Утыртканга балта чаптык гел...

2

Туган тел бер генә була,
Ул – минем татар телем.
Ул – минем газиз Әнкәем,
Газиз Әткәем теле!

Туган тел бер генә була,
Ул – чишмә суы кебек.
Ул – якты Кояш сыман бит,
Нурларын тора сибеп.

Туган тел бер генә була,
Ул – минем тәмле телем.
Ул – минем баллы, ширбәтле,
Ул – минем назлы телем.

Туган тел бер генә була,
Ул – Туган җир шикелле.
Туган тел кадерле була,
Балаң кебек сөйкемле.

Туган тел бер генә була –
Ул минем горурлыгым.
Ул минем күңел сазымда
Чирттереп җырлар кылым.

Туган тел бер генә була,
Ул – минем бөек телем!
Үзем белән бергә шыткан
Иң асыл, шиңмәс гөлем.

Минем өчен шиңдермичә
Саклаган Каюмнары.
Махсус кое казыгандыр
Сугарырга ул аны!..

## IV

«Берәүнең дә ... бу хәтле күп җырлар һәм мәкальләр тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тарафыннан тапшырылган бу материаллар аның халкының искиткеч акыллы икәнен исбат итәләр...»

*Николай Катанов*

«Татар теленә хезмәтче булыйм дип, утыз биш ел уздырдым... Никадәр тырышсам, шулкадәр җәфа чиктем...»

*Каюм Насыйри*

### 1

Тамырлары – Болгар дәверендә,
Укымышлы Ата баласы...
Габделкаюм Әл Болгари, диеп
Санап киткән җиде бабасын.

Нәселен дә,
Тарихын да белгән,
Мирас җыйган эзләп, бөртекләп.
Туган ягы Зөя өязенең
Шәҗәрәсен сызган җентекләп.

«Сөннәт»,
«Туйлау»,
«Соңгы юлга озату...» –
Әманәтен алып халкымның,
Китап иткән

Әкият-мәзәкләрен –
Авыз иҗатының «алтыны»н.

Гореф-гадәт,
Йола-кануннарның
Туган төбәктәге төрләрен
Теркәп калдырган ул,
Туар буын
Төшенерлек итеп серләрен.

«Кырык вәзир»,
«Әбугалисина», –
Зур кыйммәткә ия эшләрне
Тәрҗемәләп милләтенә биргән,
Шәрехләгән[1] кирәк төшләрен.

Иҗатының нинди тармагы юк:
Җәгърафия[2] дисәң,
Тәрбия[3].
Татарның ул – Ломоносовы, дип,
Чит милләтләр хәтта баш ия!

Матбугаты,
Һич хәбәре булмый
Яшәгән һәм торган заманда,
Чирек гасыр өстәл календаре
Чыгаручы – Каюм
Һаман да!

Туган телем –
«Татар телебезнең

---

[1] Аңлаткан.
[2] География.
[3] «Китап эт-тәрбия» күздә тотыла.

Аңлатмалы сүзлек» китабын,
Иң беренче булып кем төзегән?
Таудай хезмәт ләса ул тагын.

...Хәтта санап бетерерлек түгел
Каюм бабабызның хезмәтен.
Без белгәне – диңгездән бер тамчы,
Бер тамчының меңдер хикмәте!

## 2

Әй, минем газиз халкым син,
Әй, минем моңлы илем!
Сине зурлыйм, олылыйм, дип,
Яшәлде һәрбер көнем.

Әй, минем газиз милләтем,
Әй, минем шанлы җирем.
Батырлыгыңны сөйлим, дип,
Шул җиргә тамды тирем.

Әй, минем газиз якларым,
Сыйлы, сагышлы түрем.
Даһилыгыңны дауладым,
Мәһәргә – ләхет-гүрем.

Әй, минем газиз кавемем[1] –
Югары Шырдан буе.
Һәйкәл булсын эшләремә, –
Калдырам сезгә кое!

[1] Нәселем.

## V

«...Аллаһы Тәгалә бик күп кешеләрне пәйгамбәр кылмышдыр... Ул пәйгамбәрләр һәркаюсы адәмиләрдер... ул пәйгамбәрләр... кешеләрне Хак дингә вә изге гамәлләргә өндәмешләрдер».

*Гыйбадәт Исламия*

«Ят хәбәр юк. Ләкин халык бик ябык, зарланмаган кеше юк».

*Каюм Насыйри*

### 1

Сабыйларны сөендермәк эштән
Сәгадәтле[1], садә[2] җанына
Ләззәт илә
Ял, ямь алгандыр ул,
Дәрман йөгергәндер канына.

Авылына кайтып,
Сабан туе
Ясаган бит бала-чагага.
Көч сынаткан,
Аркан тартыштырган,
Алып чыгып иркен далага.

Тезеп бастырган да яшь буенча
Аннан йөгерергә боерган.
Юмарт бабалары тирәсенә
Бала-чага ел да җыелган.

Алдан килгәннәргә бүләк биргән,
Арттагы да нәүмиз калмаган.

---

[1] Бәхетле.
[2] Эчкерсез.

Кызыл билле тәмле прәннекне
Бала калмагандыр алмаган.

Бәгъзеләргә сәер тоелгандыр,
Көлке тоелгандыр кылганы.
Сабан туе ясап балаларга,
Өләшкән ич бөтен булганын.

Кубыз чирткән,
Курай уйнаган ул,
Еллар ябык диеп тормаган.
Сабыйларның күңел кылларына
Йомгак-йомгак гыйлем чорнаган.

Балаларның шат авазы сеңгән
Шырдан буендагы аланга.
Тибрәткән ул барча кыз-угылны
«Эт-тәрбия» дигән таганда.

2

Һөнәрле бул, углан,
Һөнәр үзе –
Чикләнмәгән дәүләт, дигәндер.
Нәфесеңне тыю,
Сабыр итү,
Шөкер кылу кыйммәт, дигәндер.

Тән пакьлеге, җан сафлыгы өчен
Хәрәкәт һәм гакыл кирәктер.
Башы – уйсыз,
Җаны – сыйсыз бәндә
Кеше түгел,
Шәүлә,
Өрәктер...

Олылардан узып,
Күкрәк сугып,
Бәхәсләшмә җиңмәк дәрт белән.
Кунак җыйсаң – ашлы табак китер,
Туйдырма сүз,
Коры гәп белән.

Үкенә бел ялгышларың өчен,
Усал белән тапма, бүлешмә.
Дус-туганны бик еш борчыма да,
Онытырлык сирәк күрешмә.

...Әй угланым,
Күп нәсыйхәт бирдем,
Әйткәнемне сеңдер буеңа.
Сәламәт уй,
Дөрес гамәл кылыр
Кеше булып өлгер туеңа!

3

Балаларның балалыгы йогып,
Сабыйлыгы йогып,
Сафлыгы –
Үз сыенда[1],
Үз көчендә үткән
Юмарт бабабызның картлыгы.

Телдән телгә йөргән хатирәләр
Халык күңелендә саклана.
Милләтеңә ихлас хезмәт итү –
Гасырларны үтеп хаклана.

---

[1] Егәрендә.

Хәер-фатихалы сүзкәйләрнең
Ел тузаны җуймый егәрен.
Дәверләрне кире кайтардык та
Үзебезгә алдык кирәген.

Ерагайган саен якыная
Насыйриның олуг кыйммәте.
Булгандыр ул, бәлки, бер варисы,
Соңгы пәйгамбәрнең өммәте.

Мәгърифәтче Каюм коесыннан
Тустаганлап алам уй-фикер.
Иманлы сүз кайтты тәрбиягә,
«Эт-тәрбия» кайтты,
Мең шөкер!

## VI

«Әллә ниләр күрер иде халык
Чорлар шундый кара чагында,
Кулларыннан алып яктылыкка
Сөйрәмәсә «сукыр» Каюмнар».

*Зөлфәт*

«Урыс укучысын татар хикәяләре, ...шуларга бәйләнештә туган ырымнары, ...гореф-гадәтләре белән таныштырырга телим...»

*Каюм Насыйри*

### 1

Кое, кое,
Серле, сихри кое,
Чишмәсенә бер күз салыгыз.
Кое төпләренә җиткәч, Каюм
Хәбәр биргән:
«Тартып алыгыз!»

Сиртмә бавын төшерегез, әйдә,
Байлыгымны сезгә озатам.
Якты дөнья күрсен хезмәтләрем –
Кылган эшем белән мин кайтам...

...Ишетмәгән гүя адәми зат
Кое эченнән килгән аһәңне.
Сиртмә бавын кисеп ыргытканнар –
Күтәрмичә тор, дип, бәһаңне...

Киссәләр дә, какса-типсәләр дә,
Чигенмәгән Каюм, нык торган.
Туган телем яшәп калсын өчен
Яратылган гали зат булган!

2

Тормыш серле...
Галим-гали затлар
Күз нурларын түгә, тир түгә,
Зыялыга күп чак зиндан тия,
Талантлыга бик тиз көн сүнә...

Чын талантлар никтер сәер була,
Артык нечкә була күңеле.
Гайбәт өчен һәрчак җирлек туа,
Эше, сүзе кала күмелеп.

Бүген белән бетми әмма тормыш,
Җир әйләнә, дөнья – куласа.
Күп нәрсәне аңлый алмас идек,
Көчле җаннар җиргә тумаса.

Нәкъ шундыйлар милләт дәрәҗәсен,
Милләт данын өскә күтәргән.
Татар халкы эшчән, мәгърифәтле,
Зур халык! дип фикер үткәргән.
Талантлар күп

Татар милләтендә
Данга төреп өскә чөярлек.
Тик бер нәрсә юлны яба безнең
Җитми кайчак дуслык, бердәмлек...

Кара еллар
Аркылыга сөргән,
Буйга ярган халык хәтерен.
Югалтканнар,
Махсус югалтканнар
Бөекләрнең эзен,
Каберен.

Югалтканнар,
Шулай кирәк булган,
Кулай булган шулай кемгәдер.
Татардагы газап – тоташ сыктау
Милләт «базары»нда кимгәдер...

3

Түбәнсетер өчен «гаеп»ләр күп:
Сукыр әнә Насыйр Каюмы.
Нинди гыйлем, имеш, бирә алсын,
Безнең кебек туны каюлы...

Каян килеп даһи шәхес бирсен
Кеп-кечкенә Шырдан авылы?
Һәрчак шулай,
Каз кадәрле булып
Күренә тик күрше тавыгы.

...Пәйгамбәрдәй даһи шәхесләре
Туа торган татар халкының.
Кадер күрми яшәп,
Үлә торган –
«Төштән соң ич татар акылы»...

Үтертелгән
Әҗәл-киллер белән,
Үз милләте башын ашаган...
Бушбугазга дөнья иркенәйгән,
Талантсызга урын бушаган...

Шулай булган элек,
Хәзер шулай.
Тагын нинди газап татырмын?..
Тик кабаттан гомер бирсә Ходай,
Татар булып Җиргә кайтырмын!

## VII

«К.Насыйриның тормыш авырлыгын гәүдәләндергән, акыл һәм әхлак темасына багышланган кайбер хикәяләре генә укучыга тәкъдим ителде әле. Бу исә диңгездән бер тамчы...»

*Авылдашы, галимә Резеда Ганиева*

«Ни өчен башка йорт халкына ялынабыз? Ни өчен башка йорттан килгән даруларга мохтаҗ булабыз? Кайчан ки, үз җиребездә дәвага яраклы үсемлекләрнең һәммәсе бардыр».

*Каюм Насыйри*

### 1

Әллә инде Рәсәй кечерәйгән,
Әллә биегәйгән Шырдан тавы?
Колакларда изге дастан кебек,
Кое чишмәсенең сулкылдавы.

Кайтавазлар сеңгән тирәнлекнең
Саф суына серләр манчылган күк.
Чирткән Каюм кое ниргәсенә –
Хакыйкатькә юллар ачылган күк.

Әкиятләр хәтта әйтмәгәнне
Әйткән галим туар баласына.
Кое төпләреннән күтәрелеп,
Чыгып баскан белем даласына.

Җиде юл чатында җитмеш һөнәр –
Әле уңга, әле сулга илтер.
Каюм бабабызның салган эзе
Мәгърифәткә –
Фәкать нурга илтер:
Иң якты юл гыйлем тарафына –
Су эчкәндәй белем эчәрсең, ди.
Мәгънәсен тойсаң хак фикернең,
Тәрбияле булып үсәрсең, ди.

Бер юл китәр урман арасына:
Балта тотсаң, оста итәрмен, ди.
Кубыз-курай ясау серләренә
Өйрәтмәккә сине көтәрмен, ди.

Бер юл китәр тугай-болыннарга
Үләннәрнең серен чишәрмен, ди.
Мине җыеп, төгәл куллансагыз,
Шифа булып сезгә күчәрмен, ди.

Тик йөрмәгез кеше тупсасында,
Хәер эстәү – матур шөгыль түгел.
Туган Җирен сөеп сихәтләнсен,
Һәм хушлану алсын һәрбер күңел!

2

Алдап булмый икән Табигатьне,
Үзенекен итә Җир-Җиһан.
Без генә ул, ялган белән бизәп,
Кызыл сүздән көттек
Җыр-илһам.

Ә Табигать гадел!
Юк кодасы,
Кодагые,
Килен-кияве...
Даһиларны үзе сайлап ала,
Һәм бәяли, биреп тиярен:
Гыйбрәт алсын,
Гыйбадәтен кылсын,
Шифалы су белән туенсын, –
Диеп, гүя ике гасыр буе
Яшәтә ул Каюм коесын.

Яшәтә ул, җыры үлмәсен, дип,
Җире иңмәсен, дип, татарның.
Исбатлый күк Каюмнары белән
Бөеклеген илнең, Ватанның!

Урау юллар,
Гасырга тиң еллар
Кайтавазлар булып эндәшә.
Инә белән казылса тик, кое –
Каюм коесына тиңләшә.

...Су бирегез,
Кирәк бер йотым су...
Кайчагында җитә бер тамчы.
И Туган Җир!
Каюм коесында
Шул бер тамчы
Саф су булсамчы!

# Эчтәлек

I

Туган җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Татарстан шуннан башлана . . . . . . . . . . . . . . . 7
Саклармын исемеңне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Икмәгегез уңсын, мул булсын! . . . . . . . . . . . . . 8
Йокысыз төн санынча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Авыл язы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Нурчишмәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Кыйблам бер генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Туган ягым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Мәгънә белә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Симәгем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Ел да кайтам яныңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Җырларымда – туган ягым . . . . . . . . . . . . . . . 15
Тагын бер кат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Туган җирнең җылысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Зурмы дисәң... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Кайтыр юлым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Тормыш гамьле булсын өчен . . . . . . . . . . . . . . 19
Зөбәерем – Зөбәер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Нинди исем кушыйм икән? . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Карга боткасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Каз өмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Йорт җиһазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Әни төсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Бәби мунчасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Гомер бишегем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Актаныш төбәгендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Әрәмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Аккошлар кайткан иде... . . . . . . . . . . . . . . . . . 27

Ташка язып китәм . . . . . . . . . . . . . . 28
Әнкәем кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Читтә яшәүче татарлар җыры . . . . . . . . 30
Ай-кояшлы таш кала . . . . . . . . . . . . . 31
Казаным . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Тыңлыйм моңлы азаның . . . . . . . . . . 33
Җанның олысы . . . . . . . . . . . . . . . 34
Тарихи калам . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Башка чарам юк . . . . . . . . . . . . . . . 35
Йөземне ак иткән кешем . . . . . . . . . . 36
Рәнҗетмик әнкәйләрне . . . . . . . . . . . 36
Бергә яшик . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Әтием, әткәй генәм . . . . . . . . . . . . 38
Әнкәй миләше . . . . . . . . . . . . . . . 39
Күзкәйләрең нурлы чәчәк булып... . . . . . 40
Гөнаһсызга... . . . . . . . . . . . . . . . 41
Кайчан гына . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Алтын алмам, оныгым . . . . . . . . . . . 42
Сабый көлгәндә . . . . . . . . . . . . . . 43
Без дә шулаймы икән? . . . . . . . . . . . 43
Улым – уң кулым . . . . . . . . . . . . . 44
Уйлый күңелем . . . . . . . . . . . . . . 45
Мәхәббәт иле . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кояш үпкән . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Боз сарган каен кебек . . . . . . . . . . . 48

II

Елмайган иреннәр үпсеннәр . . . . . . . . 50
Якын яр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Күзгә чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Таптык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Яшә назга күмелеп . . . . . . . . . . . . . 52
Ачуланма, әнием! . . . . . . . . . . . . . 53
Тудым сине яратырга . . . . . . . . . . . 54
Гашыйк итте . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Былбыл булыр өчен . . . . . . . . . . . . 56
Ай сукмагы буйлап... . . . . . . . . . . . 56
Сөю – сәгадәт . . . . . . . . . . . . . . . 57
Сүзсез буйсынган . . . . . . . . . . . . . 58
Көтелгән мәхәббәтем . . . . . . . . . . . 59

Җырлап йөрик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Кайда син? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Атылма, йолдызым . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Әл дә син бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Соңгы табышың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Күзләремә карама . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Син барда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Балкыт тормыш күген . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Сары яфрактай өзелеп . . . . . . . . . . . . . . . 65
Яңадан туу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Син минем белән серле . . . . . . . . . . . . . . 66
Әллә төн матур?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Сәламеңне алдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Бердәнберем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Сөю таңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Нурга мана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Дөньямны ямьләндерден . . . . . . . . . . . . . . 70
Йөрәгемдә ялкын бар . . . . . . . . . . . . . . . 70
Язгы ярсу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Мәхәббәтем чәчәк атты . . . . . . . . . . . . . . 72
Җылы кулдан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Гөлнең җаны үлә микән? . . . . . . . . . . . . . . 73
Суга сусатмас өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Өлгергән миләш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Көтеп яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Кайтачакмын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Бәхетле бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Хис көче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Моң калдырып киттең . . . . . . . . . . . . . . . 78
Сагынамын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Яшерә дә алмыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Сыеныйм дисәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Ләззәтләргә төрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Табигатьнең җырлы чоры . . . . . . . . . . . . . . 82
Серле көзге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Кабат терелдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Синең бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Үз иткәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Бардыр инде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Күгәрченнәр иңгә куна . . . . . . . . . . . . . . . 86

Тагын кабынам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Ни хикмәт бу? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Җайсыз сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Хәрәкәтсез калды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Куркам ярам яңарудан . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Үземне алдап яшим . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Саксыз кыландың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Очалар җилләр иркенә . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Сузган кулын кире алмаячак . . . . . . . . . . . . . 92
Күз көеге булып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Җиләкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Кемдер әйтте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Казан белән бер кыз сөйләшә . . . . . . . . . . . . 94
Чынлап әйттеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Читкә сипмә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Җан теләгән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Гомер көзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Ярат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Мәхәббәтнең җиде төсе – гомернең җиде киче . . . . . 100

III

Без Җирдә кунак кына . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Гаиләм минем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Өеңдә көтсә ярату . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Шатландырып яшәгез . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Гөлләр, гөлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Эзләдем, табалмадым . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Күршеләрем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Йолдызымны калдыр . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Мандолинам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Имгәнгәннең име . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Пар-пар булып очкан торналар . . . . . . . . . . . . 114
Изге нәрсә бармы бу дөньяда? . . . . . . . . . . . . 116
Кыен түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Хак әйтсә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Йолдыз сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Илһам көче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Шагыйрь буласың килсә . . . . . . . . . . . . . . . 120
Нурлы бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121

Вәгъдә – иман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Үксез итмәгез! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Бәет һәм гаеп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Бурыч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Кичә һәм бүген . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Юлга чыккач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Изгелек кыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Ялгыз каен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Явыз күз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Ялгышканмын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Безнең караш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Килми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Сүнде минем Кояш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Бизәү өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Исәнлеккә, саулыкка... . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Нәтиҗә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Давыл алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Исеме нинди булса да . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Татар теле мөгаллиме . . . . . . . . . . . . . . . . 142

IV

Матурлыкның бер өлгесе булып... . . . . . . . . . . 144
Яңгыр җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Ят кулына бирмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Төрле якка сибелдең . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Сак белән Сок кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Пеште . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Кире китәрмен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Кайсы чын – шул калыр . . . . . . . . . . . . . . . 150
Кысыр калды алмагачым . . . . . . . . . . . . . . . 150
Терсәкнең вазифасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Уен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Минем җиңү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Бер хыянәт иткәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Аваз килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Хурлык шаукымы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Шулмы соң егет эше? . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Халәтем – күзләремдә . . . . . . . . . . . . . . . . 156

Сөя дип уйладым... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Сискәнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Сөендермәк булдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Кулларымны сузган гына идем... . . . . . . . . . . . . 160
Үз максаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Шул җил... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Җете төсләр тиз уңа . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Үпкәләмим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Котлау язам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Без биш бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Ялкын иттек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Мәңгегә килмәгән кеше . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Дөньясы бозга әйләнсә... . . . . . . . . . . . . . . . 168
Сары коелган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Аңладым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Нишләп әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Умырзая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Кышка соклану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Йөрәгемдә сакладым да... . . . . . . . . . . . . . . . 172
Таякның ике башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Белә торып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Мичче хәйләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Сынау вакыты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Чегәннәрнең чаялыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Абынабыз, сөртенәбез . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Сиңа әйтмим... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Әләк-чәләк йөртүчегә . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Һәркемнең үз юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Син елама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Ә йөрәкнең үз эше... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Борылып та карамам . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Гаҗизлек киңәше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Гайбәт сөйли . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Балыкчы шатлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Берәүдән бары сөел . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Сәбәп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Ир булса, шундый булсын . . . . . . . . . . . . . . . 182
Югалды шатлыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Ә ул... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

Коры закон . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Күңел күзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Кайберәүләр исәнлеккә туймый... . . . . . . . . . . . . 186
Андыйга да Ходай гомер биргән . . . . . . . . . . . . . 187
Сәер сөю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Чынга ошатып сөйлисең . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Ирнең җиллесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Сөю гөлләмәндә агу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Яңгыр шакый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Бер хатын фәлсәфәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Бер ир фәлсәфәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Аш төрләндерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Никтер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Акылдан кибән куйсак та... . . . . . . . . . . . . . . . 196
Оныттыкмы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Суга барам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Аяк астындагы болыт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Чама белми сөйгәннәрнең . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Көлүнең төрлесе була . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Күзем каты микән әллә? . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Гаделлек юлында йөреп... . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Насыйп булсын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Чын йөрәктән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Ник чыкмыйсың? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Шулай юанам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Тукта, җыруым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Җирне ямьләндерик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Сабыр төбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Дәва җыям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Хыялымда кайтып килдем . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Ник күңелсез икән син болай? . . . . . . . . . . . . . 211
Моңлы бала түгел идем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Таңнар атканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Күпме дулкын дәште . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Ярый, ярамый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Аптырый эзтабарлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Кар яка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Чынга ашкан хыял . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Табигатьнең бер бөртеге . . . . . . . . . . . . . . . . . 220

V

Шәхес белән халык таныла . . . . . . . . . . . . 222
Галиҗәнап әнкәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
Әфсенлисең шагыйрь җанлы итеп . . . . . . . . . 224
Тыңлагыз! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Мөгаллимә-галимә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Моңның йөрәге – Синдә . . . . . . . . . . . . . . . 228
Балет аккошы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
Балкып торсын йөзең . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Җырла, җырла, дип әйтәсез . . . . . . . . . . . . 230
Кәүсәрия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Ак әниләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Беренче мөгаллимәм . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Кара төн яктысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Солдат әнисе монологы . . . . . . . . . . . . . . . 235
Көллиятем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Үз исемең белән тудың . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Сөембикә сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Шагыйрь чишмәсе (*поэма*) . . . . . . . . . . . . 239
Каюм коесы (*поэма*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261

Литературно-художественное издание

**Шарифуллина** Эльмира Мухаметовна

***Годы в раздумьях***

Стихи, поэмы

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *М.Я.Разногорская*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.Ш.Шафыйкова, Г.Г.Гарифуллина, Ф.М.Нәгыймова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.10.2003. Форматы $70\times90^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. Гарнитурасы «Футурис». Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,53 + форз. 0,15. Шартлы буяу-оттиск 11,35 . Нәшер-хисап табагы 10,89 + форз. 0,26. Тиражы 2000. Заказ Я-644.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.